**Казан (Идел буе) федераль университеты**
**Алабуга институты**
**Татар филологиясе кафедрасы**

**Г.Ф.ДАУТОВ**
**Ә.С.ХӘЙРУЛЛИНА**

# ХХ ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ

**уку әсбабы**

**КАЗАН**
**2020**

**УДК 811.512.145(075). 8**
**ББК 83.3.(2 Р–6Т) я73**
**Т 23**

Казан федераль университетының Алабуга институты гыйльми советы карары белән басыла (беркетмә № 2 , 26.02.2020 ел)

**Рецензентлар**:
филология фәннәре кандидаты, КФУның
Алабуга институты доценты ***Габидуллина Ф.И.***
филология фәннәре кандидаты
Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты доценты ***Галиуллин Р.Р***

***Даутов Г.Ф., Хәйруллина Ә.С,*** XX йөз башы татар әдәбияты тарихы /, Г.Ф. Даутов, Ә.С.Хәйруллина – Казан: Казан федер. ун–ы нәшр., 2020. –125б.

**ISBN**

Әлеге уку әсбабы студентларга XX гасыр башы татар әдәбияты тарихыннан төпле белемнәр бирү, аларга әлеге чордагы әдәби үсеш үзенчәлекләрен төшендерү, классик татар әдәбиятының төп вәкилләре булган күренекле татар язучылары иҗатын тирәнтен өйрәтү; XX гасыр башы татар әдәби хәрәкәтенә гомуми характеристика бирү һәм язучылар иҗатын монографик планда өйрәнү, теге яки бу язучының әдәби хәрәкәттәге урынын билгеләү; язучының дөньяга карашын һәм эстетик идеалын ачыклау; язучы иҗатының төп этапларын билгеләү, әлеге чор әдәбиятында жанр, метод, стиль үсеше закончалыкларын һәм этапларын ачыклау; XX гасыр башы татар әдәбиятының Шәрыкъ, Көнбатыш Европа, рус әдәбиятлары белән бәйләнешен аңлату – әлеге уку әсбабының төп бурычы булып тора.

ISBN

© Даутов Г.Ф.
Хәйруллина Ә.С.

© Казан федераль университеты нәшрияте

# КЕРЕШ

XX гасыр башы татар әдәбияты – рухи, мәдәни мирасыбызның иң бай һәм кызыклы дәвере. Татар халкының гасырлар буена тупланып килгән акыл егәрлеге, иҗат көче, сәнгатьчә фикерләү традицияләре XX йөз башында кешенең рухи һәм матди яшәешен чагылдыруның яңа формалары барлыкка килүгә һәм аларның моңарчы күрелмәгән кызу темплар белән үсеп китүенә җирлек әзерли. Сүз сәнгате, үз тарихының алтын дәверенә аяк басып, яңа үсеш концепциясен булдыра. Аның нигезендә милли ихтыяҗ, милләткә хезмәт итү, матурлык, сәнгатьне милләт яшәешен уңай якка үзгәртүдә файдалану вазифасы, максат– бурычлары ята [Гыйләҗев, 2005].

Татар теле һәм әдәбияты; Татар теле һәм әдәбияты, инглиз теле белгечлегенең уку планы нигезендә студентлар XX гасыр башы татар әдәбиятыннан лекцияләр тыңлыйлар, аны конспектлыйлар. Әмма белем бирүнең бу формасы гына дәвер әдәби хәрәкәтен, язучыларның рухи мирасын тулысынча, бөтен байлыгы белән иңләп бетерә алмый, һәм андый максат куелмый да. Төп максат булып студентларга XX гасыр башы татар әдәбияты тарихыннан төпле белемнәр бирү, аларга әлеге чордагы әдәби үсеш үзенчәлекләрен төшендерү, классик татар әдәбиятының төп вәкилләре булган күренекле татар язучылары иҗатын тирәнтен өйрәнү тора.

XX гасыр башы татар әдәби хәрәкәтенә гомуми характеристика бирү һәм язучылар иҗатын монографик планда өйрәнү, теге яки бу язучының әдәби хәрәкәттәге урынын билгеләү, әлеге чор әдәбиятында жанр, метод, стиль үсеше закончалыкларын һәм этапларын ачыклау, XX гасыр башы татар әдәбиятының Шәрыкъ, Көнбатыш Ауропа, рус әдәбиятлары белән бәйләнешен аңлату һ.б. төп бурычлардан санала.

Уку әсбабында XX йөз башы татар әдәбиятыннан гамәли дәресләрнең темалары да тәгъдим ителә. Анда яңа әдәбиятның гомум үсеш закончалыкларын, гыйльми-теоретик мәсьәләләрен өйрәнүгә

багышланган темалардан тыш, аерым вәкилләрнең рухи мирасын аңлау-үзләштерүне максат иткән темалар да урнаштырылган. Гамәли темалар төрле принципларга таянып төзелде: 1) әдипнең иҗат баскычлары; 2) әдәби төрләр һәм жанрларда эшчәнлеге; 3) үзәк тема һәм мотивлары һ.б. Шулай ук аерым очракларда бер гамәли дәрес өчен каралган сорауларны чикләү мәсьәләсен дә укытучы үзе хәл итә ала. Гамәли дәрес темасыннан соң әдәбият исемлеге тәгъдим ителә.

XX гасыр башы татар әдәбиятына караган әдәби-фактик, фәнни-тәнкыйть материалын белү, шул чордагы милли әдәби үсеш үзенчәлекләренә тирәнтен төшенү, әлеге чорда иҗат иткән күренекле татар язучыларының әдәби иҗат мирасын төпле өйрәнү-белү; классик әдәбиятның идея-эстетик кыйммәтен бәяләү, әһәмиятен аңлау, һ.б.

Булачак әдәбият укытучысы XX гасыр башы әдәбиятының татар милли рухи–эстетик мәдәнияте феномены булуын күз алдына китерә белергә; әдәби чыганакларны, матур әдәбият әсәрләре текстларын нигезле өйрәнгән булырга; әлеге чор әдәбиятын башка гуманитар фәннәр белән бәйләнештә карый, өйрәнә белергә тиеш.

Әлеге уку әсбабын төзегәндә М.Гайнуллин (1963), Ш.Садретдинов (1975), И.Нуруллин (1983), Р.Ганиева (1987; 1998; 2005), Т.Гыйләҗевларның (2007) методик китап-әсбаплары, мәктәп дәреслек-хрестоматияләр, программалар да игътибардан читтә калмады.

Ә.С.Хәйруллина

## ТЕМА 1. XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ҮСЕШ БАСКЫЧЛАРЫ. ПРОЗА.

### XX гасыр башы татар әдәбиятының үзенчәлекле яклары.

**Аннотация**:

XX гасыр башы әдәбияты 1905 елгы инкыйлаптан соң башлана. Аны өйрәнүдә Г.Ибраһимов, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Сәгъди, һ.б. тырышлык күрсәтәләр. 1926 елда Г.Сәгъди «Татар әдәбияты тарихы» дигән хезмәтен бастырып чыгара. Бу китапта XX гасыр башы татар әдәбиятына караган фактик материаллар да тупланган була. Шул ук авторның «Символизм турында» исемле хезмәте XX гасыр башы татар әдәбиятына караган мәсьәләләргә игътибар итә. Бөек Ватан сугышыннан соң бу чор татар әдәбиятын өйрәнү тагын да киңәя, күпләгән монографик хезмәтләр, дәреслекләр басылып чыга. 1954 елда «XX гасыр башы татар әдәбияты» дигән очерклар китабы басылып чыга. Моннан кала Ибраһим Нуруллин 1966 елда «XX гасыр башы татар әдәбияты» хезмәтен бастыра. Бу китапта XX гасыр башының әһәмиятле мәсьәләләре тикшерелә. Әлеге чорны һәрьяклап өйрәнү нәтиҗәсендә 1986 елда татар әдәбияты тарихының 3 нче томы, ә соңырак исә (2007) Таһир Гыйләҗевнең «Татар әдәбияты. XX гасыр башы: лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар» исемле китабы дөнья күрә.

**Мөһим сүзләр:**

Әдәби юнәлеш, агым, стиль, сатирик төр, реалистик иҗат методы, романтизм, модернистик агымнар, импрессианизм, экспрессионизм, экзистенциализм, символизм, натурализм.

**Теманы өйрәнүгә методик рекомендацияләр**. Тема лекция рәвешендә оештырыла. Анда өйрәнелгән гомуми мәгълүматны үзләштерергә һәм сорауларга җавап бирерлек итеп әзерләнергә кирәк.

**Глоссарий**. Лирик проза – авторның хис-кичерешләре һәм эмоциональлек белән сугарылган, теләсә нинди жанр законы буенча иҗат ителгән, ләкин художестволы прозага караган әсәрләре.

XX гасыр башы татар әдәбияты гаять бай һәм гаять катлаулы чор. Ул үз эченә дистәдән артык елны гына ала: 1905-1917 еллар. Әмма шул ук вакытта ул татар әдәбиятының алтын чорын барлыкка китерде , – дип әйтергә була. Бу чор – татар милли әдәбияты формалашу чоры. Аңа җәмгыятьтә барган кискен үзгәрешләр дә йогынты ясый. Кыска гына вакыт эчендә булган гүзәл әсәрләр туа: Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) һәм башка әдипләрнең әсәрләре. Бу елларда шулай ук драматурглардан Мирхәйдәр Фәйзи, Галиәсгар Камал, хикәяче Шәриф Камал иҗат итә. Идея-эстетик югарылыгы, сәнгатьчә камиллеге белән бу әсәрләр милли әдәбият тарихында күренекле урын алып торалар.

Бу чорны гаять катлаулы, – дип атадык. XX гасыр башында төрле иҗтимагый агымнар, фикер юнәлешләре мәйданга чыга. Берьюлы диярлек мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм һәм романтизм методы белән язылган әсәрләр туа башлый. Барлык бу юнәлешләр дә бер-берсе белән аралашып үсә. Үзләренең әсәрләрендә язучылар милләтнең алга омтылышын сурәтлиләр. Халкыбыз язмышының драматик якларын тасвирлыйлар. Әсәрләрендә милләтнең алга китүен тоткарлаган сәбәпләрне күрсәтәләр.

XX гасыр башында мәгърифәтчелек җәмгыятьләре, оешмалар, милли китапханәләр төзелә. Уку-укыту системасына да зур үзгәрешләр кертелә.

Бу елларда матур әдәбият әсәрләрен бастырып чыгару киң колач ала. Мәсәлән: 1907-1916 еллар арасында Г.Тукай әсәрләре 55 тапкыр, Г.Ибраһимов әсәрләре 20 тапкыр, М.Гафури әсәрләре 30 тапкыр аерым китап булып басылып чыга.

Рус әдәбияты әсәрләре дә, Европа әдәбияты үрнәкләре дә татар телендә дөнья күрә. Мәсәлән: Жан-Жак Руссо, Артур, Конн Дойль әсәрләре, Шекспир, М.Твен, Г.Х.Андерсен әкиятләре басыла.

Әлеге чорда XX гасыр башына караган үзенчәлекле яклар – театр үсеше, вакытлы матбугат үсешенә, XX гасыр башында татар шигъриятенә, 1905-1907 еллар поэзиясенә күзәтү ясала.

## XX гасыр башында проза үсеше

Яңа татар прозасы мәгърифәтче әдипләр иҗатында – М.Акъегет, З.Һади, Р.Фәхретдин, Ш.Мөхәммәдов һ.б. иҗатында формалаша башлый.

Татар милли прозасының икенче баскычы итеп әдәбият галимнәре 1910 нчы еллар прозасын атыйлар. Әгәрдә беренче этапта әйдәүче көч булып мәгърифәтчелек реализмының рационалистик һәм әхлакый принциплары булса, икенче баскычта чынбарлыкны һәм кеше психологиясен сәнгатьле тасвирлау зур урын алды.

Икенче этапның беренче үрнәкләрен Фатих Әмирхан бирде. «Гарәфә кич төшендә», «1907 ел», «Бәйрәмнәр», «Картайдым» һ.б. хикәяләрендә проза борылышының беренче билгеләре сизелә.

Мәҗит Гафури иҗатында («Ярлылар яки өйдәш хатын», «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» һ.б. хикәяләрендә халык темасы, гади кеше образы ныклы урын алды.

Мәгърифәтчелек реализмы әдәбиятында геройлар кискен рәвештә уңай һәм тискәрегә бүленәләр иде. Хәзерге авторлар исә ак һәм карага гына түгел, төрле буяуларга мөрәҗәгать иттеләр. Геройларның психологиясен тасвирлаганда яңа нюанслар барлыкка килде.

Язучылар бары тик мәгърифәтчелек һәм наданлыкны гына каршы куеп тасвирламадылар, ә тормышның төрле катлаулы якларына игътибар иттеләр. Әсәр геройлары да бертөрле мулла яисә рухани образына барып төртелмәгән, әдәби әсәрләрендә төрле катлау кешеләре урын алып тора. Мәсәлән, Ф.Әмирхан әсәрләрендә шәһәрдә яшәүче милли интеллигенция вәкилләре үзәктә торды. Ш.Камал әсәрләрендә Россиянең төрле төбәкләрендә бәхет эзләп йөрүче гади кеше образы үзәккә куелды. М.Гафури шәһәр һәм авыл ярлыларының

аянычлы тормышын тасвирлады. Әлбәттә, әдипләр башка тема һәм образларга да мөрәҗәгать итте.

1910 нчы еллар прозасы татар тормышын үзгәртеп кору идеясе, иске гореф гадәтләрне, кадимче дин әһелләрен, сәүдәгәрләрне, төрле ямьсез күренешләрне фаш итүче сатира барлыкка килүгә дә этәргеч ясады.

Реакция елларында сатирик прозаның күренекле үрнәкләре туа. Сатира тәнкыйди реализмның аерылмас юлдашына әверелә.

Г.Камалның Кәрим бае («Бәхетсез егет»), Хәмзә бае («Беренче театр»), Ф.Әмирханның Фәтхулла хәзрәте – болар барысы да традицион сатирик, комик яки трагикомик образларга керәләр. Әмма бу еллар прозасында аеруча катлаулы, аеруча каршылыклы тагын бер традицион тип бар. Бу – милли интеллигенция.

Мәсәлән, Ф.Әмирхан әсәрләрендә тормышта үзенең ныклы урынын тапмаган, тотрыксыз уй-хисләр белән яшәгән Хәсән Арсланов кебек урталыкта калган милли интеллегент образы сурәтләнә.

Г.Ибраһимов геройларында исә рухи азатлык кискен драматик кичерешләр гәүдәләнә («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Яшь йөрәкләр», «Көтүчеләр» һ.б.).

Бу еллар әдәбиятының үзәгендә тагын бер зур тема тора, бу – изелгән, ләкин азатлыкка омтылган хатын-кыз язмышы темасы. Күп очракта әлеге образ тормышның шәригатьнең һәм башка төрле явызлыкның корбаны итеп күрсәтелә, ягъни бу очракта әдәбият мәгърифәтчелек тенденцияләрен дәвам итә. Мәсәлән, Ф.Әмирханның «Татар кызы» нәсерендә Каракөч кыз баланы туганнан бирле күзәтеп тора һәм аннан җанлы курчак ясау өчен барлык чараларны да күрә. Нәтиҗәдә татар кызы ихтыярсыз җан иясенә әверелә. Ш.Камал татар кызын сулган гөл рәвешендә күз алдына китерә. Бу темага мөрәҗәгать итеп ул «Сулган гөл», «Уяну», «Буранда» хикәяләрен яза.

Г.Исхакыйның «Өч хатын берлә тормыш», «Теләнче кызы» әсәрләре дә бу темага язылган.

Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми?» әсәре шулай ук хатын-кызның аянычлы язмышын сурәтли.

1910 нчы еллар прозасында психологизм һәм лиризм көчәя, бу исә пейзаж сурәтләренең әһәмиятен арттыра.

Пейзажның мәгънәви эчтәлеге бай. Бу яктан Г.Ибраһимовның «Яз башы» хикәясе кызыклы. Табигать дәһшәте белән балалар мөнәсәбәтендә кискен психологик контраст барлыкка килә. «Уты сүнгән җәһәннәм» әсәрендә дә кеше белән табигать дәһшәте арасындагы контраст бирелә.

Поэзиядә генә түгел, прозада да диңгез образы зур урын ала. Гафур Коләхмәтовның русчадан тәрҗемә ителгән «Уалган мол» әсәрендә, Г.Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясендә диңгез образы кешенең хәвефле язмышын сынландыра, романтик төс ала. Ш.Камалның «Акчарлаклар» повестенда исә диңгез образы реалистик төсмер ала. Бу әсәрдәге диңгез образы геройларның көндәлек тормышына, психологиясенә нык бәйләнгән чынбарлык буларак шәрехләнә.

10 нчы еллар прозасындагы пейзаж татар халкы яшәгән төрле төбәкләрнең табигатен үз эченә алды. Ф.Әмирхан әсәрләрендә күбесенчә Казан тирәсе, Идел буйлары…

Г.Ибраһимов белән М.Гафури Башкортостан табигатен, Агыйдел буйларын тасвирладылар, Ш.Камал әсәрләрендә Россиянең Көньяк төбәкләре, кояшлы, таулы диңгезле төбәкләр сурәтләнә.

10 нчы еллар прозасының тагын бер үзенчәлекле ягы бар – яңа агымнар барлыкка килә. Бу рус һәм Европа мәдәнияте тәэсире, психологизмга игтибар арту белән аңлатыла. Бер үк авторның иҗатында төрле әдәби агымнар очравы да мөмкин. Мәсәлән, Ф.Әмирханның «Гәрәфә кич төшемдә» хикәясе мәгърифәтчелек реализмы методы белән язылган, «Фәтхулла хәзрәт» повесте тәнкыйди реализмга карый, «Хәят» әсәрендә романтизм синтезы күзәтелә. Әдипнең башка әсәрләрендә импрессионизм,

экспрессионизм, символизм, экзистенциализм һәм башка агымнар очрый.

Югарыда телгә алынган Ф,Әмирхан, Г.Ибраһимов, Ш.Камал кебек XX гасыр башы татар прозасын формалаштыруда шагыйрьләрдән М.Гафури, Н.Думави, С.Рәмиев хикәяләре дә зур роль уйнады.

## ТЕМА 2. ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ИҖАТЫ (1878–1954)

1878 елны Чистай өязе Яуширмә авылында мулла гаиләсендә туа. Үз авылында укый гарәп-фарсы телләрен өйрәнә. 1890 елда Чистай мәдрәсәсенә килә 3 ел үткәч Казанга «Күл буе» мәдрәсәсенә күчеп килә. Анда ул үзен зирәк шәкерт буларак таныта. Ләкин монда озак тормый, 1897 елда тагын бер мәдрәсәгә күчә. «Күл буе» мәдрәсәсендә аны Һади Максуди укыта, һәм аның белән бергә Әмирхановлар мәдрәсәсенә күчә.

Г.Исхакый татар халкының күренекле әдибе. Әдәбиятта ул проза өлкәсендә, драматургия өлкәсендә дә актив эшли. Яңа реалистик татар әдәбиятына нигез салучы булып исәпләнә. Бүгенге көндә классик язучы булып саналса да, үзе исән вакытта патша хакимияте тарафыннан бертуктаусыз эзәрлекләнә. Советлар Союзы оешкач аңа халык дошманы дигән исем тагалар. 35 ел гомеререн мөһәҗирлектә үткәрә. Туган илендә аның исеме бары тик тискәре яктан гына искә алына. Үзгәртеп кору елларыннан соң гына иҗаты туган якларына кире кайтарыла. Бу эштә профессор Ибраһим Нуруллин зур тырышлык куя.

1991 елда әдипнең сайланма әсәрләреннән торган «Зиндан» китабы дөнья күрә. Әдипнең иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге әсәрләренең идея–тематик эшләнеше, сәнгати үзенчәлекләре күп кенә хезмәтләрдә һәм монографияләрдә яктыртыла: Ибраһим Нуруллин, Флүн Мусин, Азат Әхмәдуллан, Фоат Галимуллин, Миркасыйм Госманов, Әбрар Кәримуллин, Әхмәт Сәхәпов, Резеда Ганиева, Лена

Гайнанова, Рәмилә Яруллина, Илсур Мансуров, Фәридә Габидуллина, Светлана Никишина һ.б.

Г.Исхакыйның җәдитчелек хәрәкәте зур көч алган чорда туа. Башта Яуширмә мәдрәсәсендә белем ала (1890); 1893 елда Казанга китә һәм анда җәдитчә укыткан Күл буе мәдрәсәсендә укый. Биредә «Тәрҗеман» газетасы белән таныша. Остасы Һади Максуди китапханәсеннән төрек китапларын яратып укый.

1898-1902 елларда Казандагы «Татар укытучылар» мәктәбендә укый.

Мәгърифәтчелек идеяләре белән мавыга башлый.

Иҗатының 1 нче этабы (1897-1904) мәгърифәтчелек чоры иҗаты дип атала да. Шул карашларга җавап биргән беренче әсәре: «Тәгаллемдә сәгадәт, яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1897). Бу хикәя 1899 елда туган Мөхәммәтҗан һәм Шәрифҗан Кәримовларның матди ярдәме белән Казанда 24 битлек китап рәвешендә басыла. Хикәянең сюжеты бик гади. Төп герой Хәлимнең матур язмышы мисалында белем алуның өстенлеге дәлилләнә. Хәлимнең сүзләре артында авторның үз карашлары ята: «Мәдрәсәгә барып гыйлем өйрәнергә кирәк. Мәдрәсә ул гыйлем сакчысы»…

«Өч хатын берлә тормыш» 1900 елда иҗат ителгән. Драмада күп кенә хатыннарның ямьсез асылы ачыла. Бу әсәр Исхакый иҗат иткән беренче пьеса гына түгел, ә цензура рөхсәте белән сәхнәләштерелгән беренче драма әсәре (1906 елда Уфа шәһәрендә «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела). Драманың төп фикере «Һәр җинаятьнең җәзасы була». Кыйланчык, надан, өч хатыны булган өстенә фәхешханәләрдә йөрүче Кәрим бай әсәр азагында хәерчелеккә төшә һәм вафат була. Аның беренче хатыны акыллы, миһербанлы, иренә тугрылыклы Әсма лотереядә 25 мең акча ота. Икенче хатыны – явыз һәм бозык Мәрьям. Ул, урамда кала. Йомшак табигатьле, әтисенең бурычлары аркасында, Кәримгә хатынлыкка бирелгән Сорур ireккә чыга.

Бу чорда шулай ук «Бай углы», «Кәләпүшче кыз», «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Ике гыйшык» һ.б. әсәрләре иҗат ителә.

Икенче чор иҗаты – «Таңчылык (дәвере) чоры» исеме астында билгеле (1905-1911 еллар). Бу чорда Г.Исхакый революцион хәрәкәттә актив катнаша. Чистай өязенә барып митинглар оештырып йөри һәм шунда кулга алына, әмма тиздән аны азат итәләр.

1905 елда журналистика эшчәнлегенә кереп китә – «Казан мөхбире», «Таң мәҗмугасы», «Хөррият», «Таң йолдызы», «Тавыш» газеталарында эшли. Бу чорда ул 18 тапкыр кулга алына, һәм тоткынлыкта «Зиндан», «Бер тоткынның саташуы», «Зөләйха» кебек әсәрләрен иҗат итә. Таңчылык дәверендә тәнкыйди реализм методын үзләштерә («Теләнче кызы», «Тартышу», «Алдым–бирдем» һб.) әсәрләрендә геройның эчке дөньясына игътибарны арттыра. («Тормышмы бу?», «Сөннәтче бабай»).

Иҗатының III дәвере – милләтчелек чоры (1912-1918).

1912 елда Г.Исхакый Төркиядән кайта, әмма Петербургка килгәч аны төрмәгә ябалар. 1913 елда апрель аенда Романовлар династиясенең 300 еллык юбилее була һәм шул юбилей уңаеннан Г.Исхакый амнистиягә эләгә, сөргенлектән азат ителә. Казанда яшәргә рөхсәте булмый, Петербургка китә һәм «Ил» газетасында, аннары «Сүз» газетасында, ул ябылгач «Безнең ил» газетасында эшли. Бу елларда Г.Исхакыйның сәяси карашлары зур үзгәреш кичерә. Ул революцион көрәш идеясеннән баш тарта:

– татар халкын саклап калу,

– аның икътисади хәлен яхшырту,

– татар мәдрәсәсен үстерү кебек идеяләр белән яши.

1910 елда «Мулла бабай» романың язып бетерә. Бу романда татар халкының тормышы төрле яктан яктыртыла.

Татар халкының этнографиясенең яшәү рәвешенә зур урын бирелә.

XX гасыр башында Исхакыйның хаксыз гаепләнүгә сәбәп булган пьессасы «Зөләйха» трагедиясе, ул 1907 елда Чистай

төрмәсендә языла башлый, аннан Истанбулда дәвам иттерелә һәм 1912 елда Петербургта язып тәгәлләнә. Иҗатында тема идеясе реализмнан романтизмга таба борылыш ясый. Әсәрләрендәге романтик алымнар ислам дине мифологиясенә мөрәҗәгать итә. Пәйгамбәрләр тарихына, крестьян дине атрибутларына кагыла.

Иҗатының дүртенче чоры – Мөһәҗирлек чоры (1910-1954).

Бу елларда иҗтимагый эшчәнлек алып баруын дәвам итә. Кытай, Төркия, Япония, Көнбатыш Европа илләрендә яшәсә дә «Юл», «Милли юл», «Яңа милли юл», «Милли байрак» һәм башка газета-журналлар чыгара. 1933 елда аеруча әһәмияткә ия булган фәнни публицистик хезмәте «Идел-Урал» дөнья күрә. Ул Берлинда татар телендә басылып чыга, Парижда рус һәм француз телләрендә, Токиядә япон телендә, Варшавада поляк телендә басыла. Бу елларда язылган әсәрләре: «Дулкын эчендә», «Өйгә таба», «Олуг Мөхәммәд», «Көз» повесте, «Җан Баевич» комедиясе. Әсәрләренең кайберләрендә революциягә кадәрге уй-фикерләрен белдерә. Мәсәлән, катнаш никах темасы «Өйләнмәгән иде» әсәрендә урын ала, «Җан Баевич» комедиясе дә шул темага языла.

«Өйгә таба» повесте Г.Исхакыйның мөһаҗирлектә иҗат иткән әсәрләреннән санала. Россия тарихында рус-төрек сугышлары берничә мәртәбә кабатлана. Повестьта әнә шуларның берсе тасвирлана. Әсәрнең төп герое башта дәртләнеп генерал дәрәҗәсенә җитәчәкмен дип ышанып үзенең кан кардәшләренә каршы (ул татар кешесе була) сугыша. Ләкин тора-бара аның күзләре ачыла башлый, һәм ул үзе генә түгел, иптәшләрен дә каршы якка алып өйгә омтыла, ягъни өйгә таба алып бара...

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

Әдип иҗатында хатын-кыз образларының үсеш-үзгәреше.

Язучы иҗатында халыкчылык идеяләренең гәүдәләнеше.

Әдип мирасында әдәби юнәлешләр, иҗат ысуллары, алымнары.

Г.Исхакый тормышы һәм иҗаты үрнәгендә “Мәгънәле үткән гомер” дигән темага иҗади эш.

“Остазбикә” хикәясендә хатын-кыз бәхетенең яктыртылышы.

“Зиндан” повестенда тоткын мотивы.

“Олуг Мөхәммәд” драмасында тарихи мотивлар.

“Зөләйха” фаҗигәсендә Зөләйха образы.

“Мөгаллимә” драмасында халыкчылык идеяләренең гәүдәләнеше.

Әдипнең “Тормышмы бу?” романында мәхдүм образы.

**Гамәли биремнәр**

Әдипнең бу чордагы тормыш һәм иҗат юлы, дөньяга карашлары.

“Кәләпүшче кыз” повестенда сюжет сызыгы.

“Ике йөз елдан соң инкыйраз” әсәренең жанрын билгеләү.

Әдипнең гомер юлы баскычында тормыш һәм иҗат фактлары.

Драматургның “Алдым-бирдем” драмасында конфликт һәм характерлар.

“Тормышмы бу?” романында төп каһарман “Мин” нең фикри, рухи үсеш баскычлары.

“Тартышу” тарихи драмасында гәүдәләнгән иҗтимагый-социаль һәм сыйнфый көрәш мотивлары.

“Зөләйха” пьесасы, жанр һәм конфликт үзенчәлеге.

“Мөгаллимә” драмасының конфликты, күтәрелгән мәсьәләләре.

“Сөннәтче бабай”, “Остазбикә” хикәяләрендә милли хосусиятләрнең чагылышы.

“Ул икеләнә иде”, “Ул әле өйләнмәгән иде” повестьларында катнаш никах, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләре.

Әдипнең мөһәҗирлектәге сәяси, публицистик, журналистлык һәм әдәби эшчәнлеге.

Бу чор мирасында яктыртылган темалар һәм жанр төрлелеге.

Әдипнең “Күз” повестенда ике хатын-кыз язмышын сурәтләгән сюжет сызыклары.

“Жан Баевич” әсәренең жанр үзенчәлеге, иҗат ысуллары.

**Гаяз Исхакый иҗаты буенча тест**

Г. Исхакыйның туган елы.

а) 1870

б) 1878

в) 1887

г) 1886

2. Гали Путляков исеменә чыгарылган газета.

а) «Сүз»

б) «Ил»

в) «Таң йолдызы»

г) «Безнең ил»

д) «Маяк»

3. Г. Исхакый белем алган Казан мәдрәсәсе.

а) «Хөсәения»

б) Күл буе мәдрәсәсе

в) «Мөхәммәдия»

г) «Халидия»

4. Булачак язучының беренче тәҗрибәсе.

а) «Өч хатын белән тормыш»

б) «Тәгаллемдә - сәгадәт»

в) «Теләнче кыз»

г) «Бай углы»

5. Әдип иҗатында мәгърифәтчелек чоры.

а) 1900-1905

б) 1895-1905

в) 1897-1904

г) 1905-1910

6. «Әдәбият мәйданында хәзер иң шәүкәтле вә иң бөек урында карт реалист Гаяз әфәнде тора» юлларының авторы.

а) Җ.Вәлиди

б) Ф.Әмирхан

в) Г.Ибраһимов

7. «Кайт әле монда, Ватанга, кайт әле, саргайтмале!» юлларының авторы.

а) С.Сүнчәләй

б) С.Рәмиев

в) Г.Тукай

8. «Идел-Урал» тарихи-сәяси трактата әдипнең идеалы.

а) мили дәүләтчелек

б) социаль азатлык

в) төрки бергәлек

9. Г.Исхакый гомеренең соңгы көннәрен үткәргән дәүләт.

а) Германия

б) Төркия

в) Финляндия

г) Польша

10. «Зиндан» повестендагы тарихи вакытны билгеләгез.

а) беренче рус инкыйлабы еллары

б) реакция еллары

в) унынчы елларяф

11. «Теләнче кыз» романының иҗат агымы.

а) психологик реализм

б) тәнкыйди реализм

в) мәгърифәтчелек реализмы

12. «Остазбикә» повестеның пафосы.

а) героик

б) сентименталь

в) романтик

г) трагик

13. «Мөгаллим» драмасының сюжет нигезендә яткан конфликтның төре.

а) локаль

б) субстанциаль

14. «Зиндан» повестенда аталмаган герой.

а) С.Рәмиев

б) Г.Бадамшин

в) Ф.Туктаров

г) Х.Ямашев

д) Ш.Мйхәммәдьяров

е) Г.Терегулов

15. «Тартышу» тарихи-инкыйлаби драмасында образ төрләрен билгеләгез.

а) җыелма

б) ясалма

в) эпизодик

г) төп

д) аталучы

е) ярдәмче

**Әдәбият**

1. Исхакый Г. «Зиндан». Сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре. – Казан, 1991.

2. Исхакый Г. 15 томда, 1998 ел.

Т.1. Повестьлар һәм хикәяләр (1898-1908),

Т.2. Повестьлар һәм хикәяләр (1909-1917),

Т.3. «Теләнче кыз», «Мулла бабай», – 2001.

Т.8. «Г.Исхакыйның тормышы һәм иҗаты турында замандашлары» (1908-1917) – 2001..

3. Исмәгыйлева С.Г. Гаяз Исхакый драматургиясе // Мәгариф. – 2000.– №8-11. – 2002. –№ 6.

4. Исмәгыйлева С.Г. Мәктәптә әдәби әсәрләргә анализ ясау

алымнары. – Алабуга, 1998. – 81 б.

5. Исхакый Г. Дулкын эчендә// Мирас. – 1992. – № 4. – Б.52–72; – 1992. –№5. – Б.52–66.

6. Миңнегулов Х.Й. Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге әдәби–публицистик эшчәнлеге // Мәгариф. – 2005. – №10. – Б. 20-21.

7. Миңнегулов Х.Й. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 367 б.

8. Миңнегулов Х.Й. Татар театрының атасы һәм Г. Исхакый // Мәдәни җомга. – 2006. – №43. – Б.8-9.

9. Миңнегулов Х.Й. Язмышлар дулкынында: Г. Исхакыйның «Дулкын эчендә» драмасы // Мирас. – 1999. – №2. – Б.53-58.

10. Мусин Ф. Гаяз Исхакый һәм татар мәгарифе // Мәгърифәт. – 16 март. – Б.5.

11. Мусин Ф. Исхакый һәм татар мәгарифе. // Мәгариф. – 2008. – № 2. – Б. 6.

12. Нуруллин И. Гаяз Исхакый (Әдипнең тормыш юлы һәм иҗат эшчәнлегенә кыскача күзәтү). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.

13. Сәхапов М. Татар ренессансының алтын дәвере // Мирас. – № 8. – Б.88-149.

## Галимҗан Ибраһимов
## (1887-1938)

### Тормыш һәм иҗат юлы

Г.Ибраһимов күпкырлы каләм иясе. Ул – әдип, әдәбият галиме, тәнкыйтьче, публицист, журналист, тәңкыйтьче һәм тел белеме методисты һәм педагог, сәясәтче һәм дәүләт эшлеклесе. Әдәбиятка XX гасыр башында халыкларның азатлыгы өчен көрәш барганда килеп керә.

1887 елның 12 мартында Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе Солтанморат авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Гыйрфан үзе дә озак еллар буена мәдрәсәдә укый. Аннары Троицк шәһәрендә мөгаллимлек итә. Соңыннан Солтанморатка кайтып мулла була. Ләкин картлык көннәрендә, үләренә 3 ел кала муллалык эшен

ташлый. Заманның алдынгы карашлы, укымышлы кешеләреннән санала. Әнисе Бибихасәнә Троицк шәһәрендә туып үсә. Әйбәт белем һәм тәрбия алган ханым була. Мөгаллимә булырга әзерләнә. Башлангыч белемне Г.Ибраһимов әнисеннән ала. Балачак еллары авылда үтә һәм авыл табигатенә авыл мохитенә мәхәббәте Г.Ибраһимовта бик иртә уяна. Туган җир табигатенең тасвирлары хикәяләрендә дә зуррак күләмле әсәрләрендә дә күп тапкырлар кабатлана. Бераз үсә төшкәч Г.Ибраһимов үз авылыннан 5-6 чакрым ераклыктагы Кешәрле авылы мәдрәсәсенә йөри башлый. Шул ук вакытта рус теленә дә өйрәнә. 1898 елда аны Оренбургтагы иске тәртипле Вәли мулла мәдрәсәсенә бирәләр. Ләкин Г.Ибраһимов үзлегеннән бик күп укый һәм бу мәдрәсәнең асылын аңлап укуының икенче елында мәдрәсәне үзгәртеп кору өчен көрәш башлый. Әлбәттә җитәкчеләр шәкертләрнең бу хәрәкәтен бик тиз бастыралар һәм Г.Ибраһимовны мәдрәсәдән куалар. 1906 елның көзендә ул Уфадагы Галия мәдрәсәсенә укырга керә, ләкин мондагы укыту методлары белән дә риза булмый һәм Галия мәдрәсәсен ташлап китә. Шуннан соң Казакъ далаларында, Әстерхан нугайлары арасында укытучылык итә. Берара Уралда Миас заводы эшчеләре арасында яши. 1909 елны Казанга килә. Аны монда университетка керү теләге китерә. Ләкин университет ишекләре аның өчен ябык була. Г.Ибраһимов Киевка китә һәм анда университетка ирекле тыңлаучы булып керә. Шул ук вакытта мөселман студентларының яшерен оешмаларында катнаша һәм патша хакимияте белән беренче бәрелеше шушы елларга туры килә. 1913 елның 17 апрелендә кулга алына, июнь урталарында аны төрмәдән чыгаралар, ләкин шуңа да карамастан 1917 елгы революциягә кадәр даими рәвештә охранка күзәтүе астында яшәргә мәҗбүр була. Ләкин эшчәнлеген ташламый. 1913 елның көзеннән Казанда «Аң» журналының җаваплы сәркатибе булып эшли. 1914 елны яңадан Киевка китә, аннары Одессага, аннары Кара диңгез якларына барып чыга һәм яңадан Солтанморатка әйләнеп кайта. Аннан соң Галия мәдрәсәсендә укыта (1915). Монда эшләгәндә

шактый күп фәнни һәм педагогик хезмәтләр яза. 1917 ел урталарында «Ирек», «Солдат теләге», «Безнең Юл» газеталарында эшли. Гомере буена бик күп җыелышларда катнаша һәм үзен язучы гына түгел, тәнкыйтьче, сәясәтче, тел һәм әдәбият белгече итеп таныта.

**Иҗаты**

Г.Ибраһимовның Октябрь инкыйлабына кадәр иҗаты берничә чорга бүлеп карыйлар. Мәсәлән, Г.Ибраһимовның әсәрләренең I нче томында 2 этапны аерым күрсәтәләр:

1) 1907-1913 еллар,

2) 1913-1917 еллар.

1986 елда чыккан III томында –

1 нче этап – 1910-1912 елларны үз эченә ала. Бу чыганакта 1907-1909 еллар «мәгърифәтчелек чоры» дип бирелә. Соңгы елларда чыккан дәүләт университеты программасында 2 этапка:

1) 1907-1912 еллар,

2) 1913-1917 еллар бүлеп карыйлар.

Башлангыч чорында 1907-1909 елларда берничә әсәр яза. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907), «Гыйшык корбаннары» (1908), «Яшьләр тормышыннан бер ләүхә» (1909).

Башлангыч чорында шушы чорның актуаль проблемаларын күтәрә, «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясен Г.Ибраһимов Кавказ якларында мөгаллимлек иткән чакта яза. Әлеге әсәрдә мәгърифәтчелек карашлары чагыла. Әсәр автобиографик материалларга нигезләнгән. Әмма эчтәлеген автобиографик мәгълүматларга гына кайтарып калдырырга ярамый. Язучы әсәрендә мәдрәсәгә килү көненнән башлап, куылу көненә кадәр күргәннәрен сурәтләгән: мәдрәсә тәртипләре, рамазан аенда теләнеп йөрүләре, дедовщина һ.б. Бер елдан соң Зәки үзе дә тәҗрибәле шәкерткә әйләнә. «Гыйльмия» мәдрәсәсе шәкертләре белән аралаша. Дөньяга карашлары үзгәрә һәм реформа ясаучы шәкртләрнең башлыгы буларак мәдрәсәдән куыла.

Моны реалистик әсәр дип әйтеп булмый. Бу әсәр мәдрәсә тормышы, язучының мәгърифәтчелек карашларына иллюстрация хезмәтен үти.

1909 елны «Яшьләр хәятеннән бер ләүхә» хикәясе языла. Әсәрнең үзәгендә яшь язучының фәлсәфи, мәдәни, милли карашлары чагыла. Сәлим исемле геройның карашларының үзгәреш кичерүен тасвирлап бирә. Ул башта үзен милләтчелек тарафдары дип атый. Җәлил исемле алдынгырак карашлы егет белән сөйләшкәч Сәлим инсаниятчелекнең (кеше) карашларына хезмәт итә башлый. Бу карашлардан читкә, индивидуаль карашларына күчә, үзенең шәхси мәнфәгатьләрен уйлый башлый. Үзенең дусты белән бәхәстән соң, шәхси карашлардан яңадан инсаниятчелеккә кайтачагына ышаныч белдерә.

1909 елда «Татар хатыны ниләр күрми?» повестенең беренче редакциясен башлангыч чор иҗатында яза. Бу әсәр әдипнең иҗатында зур адым булып кабул ителә. Башкортстанның «Нур» типографиясендә басыла. Титул битендә «Ирләр сурәтендә йөргән хатын», «Эстәрлетамакта булган хәл»» дип язылган.

– Татар хатын кызының азатлыкка, белемгә омтылуларын, өйләрен ташлап китүләрен, ирләр киемендә йөргән кызлар турында ике хәл беләм, – ди автор.

Әсәрнең кереш өлешендә язучы татар хатынының хокуксызлыгын, ирләре тарафыннан изелеп яшәвен әйтә һәм бер кызны ирексезләп (көчләп) иргә бирәләр һәм ул кыйналуларга түзә алмыйча, кешеләр суда батып үлгән дип уйласыннар өчен ачык кисмәген бәке янында калдырып, икенче авылга чыгып кача. Г.Ибраһимов әсәренең героинясы Гөлбануда иренең, кайнанасының усаллыгына түзә алмыйча ире өеннән чыгып китә. Башкорт далаларында йөри, асрау булып тора, бер башкортның хатыны да булып ала, аннан да качып китә, чәчен кисә, һәм ирләр киеме киеп бервакыт этисенең йортында куна һәм аның кемлеге ачыла. Әсәр

нигездә мәгърифәтчелек реализмында язылган, хатын-кызның ачы язмышы гәүдәләндерелгән.

Революциядән соң бу әсәргә кире әйләнеп кайта, 1929 елда ул аны эшкәртә, ләкин кискен үзгәртми. Икенче варианта сюжетка үзгәрешләр кертелә, әсәрдә романтизмнан бигрәк реализм зур урын ала. Урта хәлле крестьян Нури кызларын матур, уңган, тырыш итеп үстерә. Ләкин байлыкка кызыгып авылның иң усал хатыны Сабираның улына кызларын бирәләр. Башта Гөлбануны яраткан, хөрмәт иткән ире әнисенең сүзләре тәэсирендә хатынына көннән–көн кырысрак карый башлый. Я моннан, я тегеннән гаеп табып Гөлбануны гел кыйный, хәтта балага узгач та бу эшеннән туктамый. Әсәр ахырында Гөлбану үле бала таба. Шуның аркасында әзерәк зыян килә. Бераз терелгәч, әзерәк хәл алгач, ул этисенә аерылырга рөхсәт бирүен үтенеп хат яза, ләкин этисе аның үтенечен кабул итмәгәч, суга батып һәлак була.

1910-1911 елны романтик рухта язылган «Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Сөю-Сәгадәт» кебек әсәрләрен бастырып чыгара. Бу әсәрләре башлангыч чор иҗатыннан нык аерылалар. Бигрәк тә «Диңгездә» хикәясендә романтизм чагыла. Төп герой «Яшисе, мең ел яшисе иде, ләкин бездәге кебек эчпошыргыч, газаплы көннәр белән түгел, ә матур мәгънәле тормыш белән яшисе килә» – ди. Хикәя барышында автор төп геройның юлдашлары белән таныштыра, диңгезне бәян итә һәм хикәя ахырында көймәдәге башка геройлар куркыныч штромнан котылып исән-сау коры җиргә басуларына сөенсәләр, романтик геройларның бу гадәти тормышка кире кайтасылары килми.

1912 елдан соң Г.Ибраһимов хикәяләрендә романтизм белән реализм бергә үрелеп бирелә башлый.

«Көтүчеләр» дә (1913) – түбән катлау кешеләре тормышы сурәтләнә. Көтүче Әптерәш карт һәм аның оныгы Вахит әнә шундыйлардан. Вахит романтик герой буларак бирелә. Әсәрдә аларның ярлы тормышлары, бабайның соңгы көннәре, йорттан-

йортка күчеп тәрбияләнүе реалистик планда сурәтләнсә, Вахитның авырып шифаханәгә эләгүе, анда Сара туташ белән танышуы, бергә яши башлаулары, төш күрү алымнары, бөек философлар, сәнгать турында уйланулар – барысы да романтизмга хас булу белән аңлатыла.

**«Табигать балалары»** (1914) хикәясе Хафиз 23 яшьлек егет исеменнән алып барыла һәм ул тулысы белән хезмәт һәм яшьлек романтикасы белән сугарылган. Хафиз авылның иң чибәр уңган кызын хатынлыкка алырга тели. Моның өчен аңа авылның иң атаклы печән чабучысы белән ярышырга кирәк һәм хикәядә яшьләрнең эссе, җәйге көндә, ураза вакытында иртәдән кичкә хәтле печән эшендә катнашканнары сурәтләнә. Ләкин бу хезмәт авыр һәм газаплы итеп сүрәтләнми, ә яшьлек һәм матурлыкның атрибуты итеп бирелә.

**«Яшь йөрәкләр»** беренче зур әсәре буларак әдәбиятка кереп калды. Әсәрдә иске карашлы, консерватив аталар белән яңача эшләргә, рухи азатлыкка омтылган балалар арасындагы көрәш сурәтләнә. Бу көрәш барыннан да бигрәк, Җәләш мулла белән аның уллары Зыя һәм Сабир образларында, аларның теләкләре, тормыш принциплары бәрелешендә гәүдәләнә.

Зыя үзенең хыял һәм омтылышлары белән чор тәртипләренә каршы чыга, шәхес иреген яклый. Ул музыкант булырга хыяллана, музыканың сихри көче белән халыкның язмышын җиңеләйтергә тели. Аның Мәрьямга булган мәхәббәте шулай ук иске тормышка, ислам дине, шәригать кануннарына каршы юнәлдерелгән. Ләкин Зыя үзенең идеаллары өчен көрәшерлек шәхес түгел. Ул – идеалист–романтик. Шулай итеп Г.Ибраһимов әсәрләренә романтизм тенденцияләре хас. Аның геройлары яшәмәктәге тәртипләрне кире кагалар, иске тормышның тар кысаларыннан ычкынырга, яңа дөньяга, ireккә чыгарга омтылалар.

### Г. Ибраһимов – хикәяче

Г. Ибраһимовның Октябрь борылышына кадәрге гомер юлында тормыш һәм иҗат фактлары, күпкырлы эшчәнлеге.

Әдипнең «каләм сынау дәвере»ндә иҗат ителгән әсәрләрендә сурәтләнгән темалар, күтәрелгән мәсьәләләр, аларның идея-эстетик үзенчәлекләре («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә, «Гыйшык корбаннары»).

Романтик дәвер хикәяләрендә («Сөю-сәгадәт», «Диңгездә», «Уты сүнгән җәһәннәм») яшәү матурлыгын, яшәү мәгънәсен эзләүче герой. Автор мөрәҗәгать иткән алымнар, чаралар.

Язучының гади халык тормышын, авыр яшәешен гәүдәләндергән «Карт ялчы», «Көтүчеләр» хикәясе. Г. Ибраһимовның иҗтимагый гаделсезлекләр, әдәбият-сәнгать һәм кешелек җәмгыяте сораулары тирәсендә фәлсәфи, әдәби-эстетик гамьнәре; әсәрләрнең иҗат ысулы мәсьәләсе.

«Табигать балалары» хикәясендә әдипнең фәлсәфи, руссочыл карашлары. Әдәбият-сәнгатьнең вазифасы, дин, фән, гыйлем, милләт турындагы уйлануларның «Мәрхүмнең дәфтәреннән» хикәясендә үстерелеше һәм яңача хәл ителеше.

### Галимҗан Ибраһимов – романчы

Әдипнең «Яшь йөрәкләр» романында сюжет сызыклары. Әсәрдә вакыйгалар хәрәкәтен барлыкка китерүче каршылыклар, күтәрелгән проблемалар.

«Яшь йөрәкләр» әсәрендә характерлар бирелеше: Зыя – Сабир, Җәләш мулла – Зөләйха, Фатыйма бикә – Мәрьям. Романда үткәрелгән иҗтимагый, милли, фәлсәфи фикерләр. Романда сурәтләнгән дөнья: психологизм, пейзаж, портрет һ. б.

Г. Ибраһимовның беренче рус инкыйлабы һәм реакция еллары вакыйгаларын, сәяси, иҗтимагый-милли тормышны колачлаган «Безнең көннәр» романы, аның ике варианты. Әсәрнең сюжет җепләре, аның идеологик катламында төрле иҗтимагый төркемнәр

яшәешенең сурәтләнеше, сәяси фирка-партияләрнең үзара тартышы, милли чынбарлыкны үзгәртеп кору юллары турында уйланулар.

Романның катлаулы образлар системасы, характерлар бәрелеше. «Безнең көннәр» романында тәнкыйди реализмның, бер яктан, романтик алымнар һәм чаралар белән баетылуы, икенче яктан, пролетариат әдәбиятының билгеләре, сыйфатлары белән үрелүе.

Г. Ибраһимовның, «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә күтәрелгән мәсьәләләр, авторның шагыйрьләр иҗатын бәяләү бизмәннәре, принциплары, гыйльмй-нәзари кагыйдәләре. Галим тарафыннан Г. Тукай, Дәрдемәнд, С. Рәмиев иҗатларының аерып чыгарылган сыйфатлары.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

Әдип иҗатындагы кеше образын тудыру алымнарын язучының иҗат методына, ысулына бәйләп аңлатыгыз. Ни өчен?

Г. Ибраһимов ижатындагы романтик дәвернең (1907-1912) төп сыйфатларын санагыз.

Әдип иҗатында «сәнгать – сәнгать өчен, әдәбият – мәсләк, хезмәт өчен» гыйльми-нәзари карашының тартышын күрсәтегез.

Г.Ибраһимовның «Уты сүнгән җәһәннәм», Ф. Әмирханның «Картайдым» хикәяләрен нинди сыйфатлар берләштерә?

«Яшь йөрәкләр» романында төп һәм ярдәмче сюжет сызыкларын, аларда вакыйгалар үстерелешен тәэмин иткән каршылыкларны билгеләгез.

Г.Ибраһимовны замандаш әдипләреннән аерып куя торган үзенчәлекләрне әйтегез.

«Язучының Октябрь борылышына кадәр иҗатында шәхес концепциясе» дигән темага иҗади эш башкарыгыз.

**Гамәли биремнәр**

Г. Ибраһимовның «Карт ялчы» хикәясендә Шаһибәк образы һәм бәхет мәсьәләсе.

«Диңгездә» хикәясендә хикәяләүче образы.

«Диңгездә» әсәрендә романтизм билгеләре.

Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә күтәрелгән мәсьәләләр.

«Татар шагыйрьләре» китабында Г.Тукай, Дәрдемәнд әсәрләренең тел- өслүбенә бөя.

«Яшь йөрәкләр» романында музыка һәм авторның аңа мөнәсәбәте.

Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» хикәясендә үткәрелгән фикерләр.

«Яшь йөрәкләр» романында Зыя һәм Сабир образлары.

«Яшь йөрәкләр» романында психологик, иҗтимагый-милли, эстетик, фәлсәфи катлам.

«Яшь йөрәкләр» әсәрендә психологик кичерешләрне сурәтләүче детальләр.

«Безнең көннәр» романында эсерлар партиясенең идеологиясе чагылышы.

Әдипнең хикәяләрендә мәхәббәт фәлсәфәсе («Сөю-сөгадәт», «Яшь йөрәкләр»).

Әдипнең романтик дәверендә яшәү мәгънәсе, бәхет концепциясе («Сөю-сәгадәт», «Диңгездә», «Уты сүнгән җәһәннәм»).

«Безнең көннәр» романында шәкертләр хәрәкәтенең чагылышы.

«Безнең көннәр» романында эшче-большевикларның сыйнфый көрәшен гәүдәләндергән сюжет сызыгы.

«Безнең көннәр» романында Гәрәй Солтан образы.

«Безнең көннәр» әсәрендә романтик буяулар, алымнар.

Әдип иҗатында кеше образы тудыру алымнары (психологизм, табигатьне тасвирлау, тышкы кыяфәт).

Әдип әсәрләрендә психологизм алымнары: психологик анализ, үзанализ, эчке монолог, аң агышы һ. б.

Язучы хикәяләрендә фәлсәфи катлам («Диңгездә», «Мәрхүмнең дәфтәреннән», «Уты сүнгән җәһәннәм» һ. б.).

**Әдәбият**

Ибраһимов Г. Г. Әсәрләр: 9 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974-1976: Т. 1. Хикәяләр (1907-1929).– 1974. – 508 б.

Т. 2. Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. 1975.– 477 б.

Т. 3. Безнең көннәр. – 1976.– 461 б.

Ибраһимов Г. Г. Сайланма әсәрләр: 3 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1957.

**Төп әдәбият**

Нуруллин И. З. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – ББ. 159-176.

Хәсәнов М. Х. Галимҗан Ибраһимов / Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Т. 3.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.– ББ. 338-357.

**Өстәмә әдәбият**

Абдуллин Я. Г. Милләт язмышы: Уйланулар: Мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Фән, 1999.– ББ.130-147.

Әхмәдуллин А. Г. Офыклар киңәйгәндә: Мәкаләләр җыентыгы.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.– ББ. 225-238.

Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман. Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары, – Казан: Фикер, 2003.– 272 б.

Ганиева Р. К. Галимҗан Ибраһимов һәм Көнчыгыш әдәбиятлары // Казан утлары.– 1987.–№ 3. – ББ. 134-141; Галимҗан Ибраһимовның «Көтүчеләр» хикәясе / Татар әдәбияты: традицияләр, бәйләнешләр.– Казан: КДУ нәшр., 2002.– ББ. 224-231.

Гыйләҗев Т. Ш. Г.Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» һәм әдәби-тәнкыйди фикер // Әдәби мирас: тарих һәм заман. Мәкаләләр җыентыгы,– Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.– ББ. 27-34.

Заһидуллина Д. Ф. Әдәбият кануннары һәм заман. – Казан: Татар, кит. нәшр., 2000. – ББ.208-212; Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.– ББ. 108-110; 118-120; 122-124.

Ибраһимов Г. Г. Әсәрләр: 9 томда. Т. 9.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 464 б.

Нигъмәти Г. Г. «Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгәниләр биргән?»;

«Г.Ибраһимов һәм аның иҗат юлы»; «Безнең көннәр» һәм аның стилендә бишенче еллар сыйнфый көрәшенең чагылышы / Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.– ББ.55-72; 73-91; 92-118.

Халит Г. М. Чынлык һәм гүзәллек гармониясе // Казан утлары. – 1987.– № 3.– ББ. 121-134; Тормышчан батырлык һем сәнгатьчә матурлык сере (Галимҗан Ибраһимовның герое һәм әдәби осталыгы) // Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән.– Казан, 1975.– ББ.76-98.

Хәмидуллин Л. Х. Ак төннәр хәтере. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.– ББ. 96-107.

Хабутдинов А. Ю. Лидеры нации.– Казань: Татар. кн. изд–во, 2003.– С. 128-136.

Хасанов М. Х. Галимджан Ибрагимов. – Казань: Татар. кн. изд–во, 1969.– 432 с.

Хәсәнов М. Х. Галимҗан Ибраһимов // Әдәбият (ХХ гасыр башы һәм 20 нче еллар): Унберьеллык урта мәктәпнең 10 ҹчы сыйныфы өчен дәреслек,– Казан: Мәгариф, 1994.– ББ. 273-306; Г. Ибраһимов – тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме // Ибраһимов Г. Г. Әсәрләр: 9 томда. Т. 5.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – ББ.531-543.

## ТЕМА 3. ФАТИХ ӘМИРХАН (1886-1926)

Фатих Әмирхан күренекле прозаик, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе һәм әдәби тәнкыйтьче. Тулы исеме Мөхәммәтфатих Зариф улы Әмирханов 1886 елның 13 гыйнварендә Казанның Яңа Бистәсендә мулла гаиләсендә туа. Әнисе рухани булса да, иске карашлы кеше булмый, яңача фикер йөртә һәм балаларын кысып, изеп яшәми, ә күпмедер дәрәҗәдә ирек бирергә тырыша. 7-8 яшькә җиткәч Фатих Әмирханны мәхәллә мәктәбенә укырга бирәләр, ә ике ел үткәч алдынгы мәдрәсәләрдән саналган Мөхәммәдиягә

күчерәләр. 1895 елдан алып 1905 елга кадәр Фатих Әмирхан шул мәдрәсәдә укый. Монда дин фәннәрен, дөньяви фәннәрне, Көнчыгыш һәм рус әдәбиятын үзләштерә. Ул укуда гына түгел, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша, шәкертләр хәрәкәтенең үзәгендә тора. Мәдрәсәдәге кайбер иске тәртипләрне тәнкыйтьләп «Мәгариф», «Тәрәкый» исемле кульъязма газета-журналлар чыгара. Хөсәен Ямашев, Гафур Коләхмәтов кебек революционерлар белән якыннан аралаша.

Фатих Әмирханның иҗади эшчәнлеге 1905-1907 елларда башлана. Бу елларда ул Петербургта һәм Мәскәүдә курсларда укый. Беренче басма әсәре «71 ел комуннасы». Бу тәрҗемә очерк була һәм Париж коммунасының 35 еллыгына багышлана, «Әл-гасрел җәдит» журналында басылып чыга. 1907 елда татар балалары өчен «Тәрбиятел этфаль» («Балалар тәрбиясе») журналы чыга башый. Монда язучы фәнни-популяр мәкаләләр («Зилзилә», «Менделеев»), Ганс Хрестин Андерсонның хикәяләрен ирекле тәрҗемә итеп бастыра. Бу журнал ябылгач Фатих Әмирхан Казанга кайта. Зур планнар, идеаллар белән кайтса да әдип фаҗигага юлыга, 21 яшьлек егетне паралич суга, һәм ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр коляскада үткәрергә мәҗбүр була.

**Иҗаты**

Беренче оригиналь әдәби әсәре «Гарәфә кич төшемдә» (Гает алды киче). Ул – 1907 елда «Әл-ислах» (реформа) газетасында басылып чыга. Гомумән, 1907-1909 еллар – «Әл-ислах» чоры. Әлеге газетада эшләү дәверендә Ф.Әмирхан Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал кебек шәхесләр белән якыннан таныша. Һәм Тукай Казанга килгәч ул иҗат иткән күпчелек әсәрләр шул «Әл–ислах» газетасында басылып чыга. Фатих Әмирхан үзе дә бу елларда актив иҗат итә. «Бәйрәмнәр» (1908), «Картайдым» (1909), «Татар кызы» (1909), «Танымаганлыктан таныштык» (1909) кебек хикәяләр иҗат итә, «Яшьләр» драмасы (1909), «Фәтхулла хәзрәт» повесте (1909).

Шуларга өстәп Ф.Әмирхан йөзгә якын очерк, фальетон, тәнкыйть мәкаләләре һәм публицистик мәкаләләр яза. 1910-1917 елларда заман тормышын тө яктан яктырткан әсәрләр иҗат итә. Алар арасында рус һәм татар тормышын капма-каршы яктан тасвирлап язган, яшьүсмер кызның эчке дөньясын ачып биргән «Хәят» повесте (1911) да бар.

«Урталыкта» романы (1912),

«Хәзрәт үгетләргә килде» (1912),

«Сәмигулла абзый» һәм башка юмористик-сатирик хикәяләре балалар өчен иҗат ителгән «Корбан», «Нәҗип», «Ул үксез бала шул» һ.б. әсәрләре бар.

Фатих Әмирхан геройлары рус-европа мәйданына йөз тотучы кешеләр, гимназистлар, курсистлар, укучы-студентлар. Бу әдипнең үзенең рус һәм Европа тормышына омтылуы белән аңлатыла. Беренче әсәрендә «Гәрәфә кич төшемдә» хикәяләүче үзенең төшен сөйли. Төшендә зур бер татар клубына меңәрләгән зыялылар килә. Алар арасында икътисад, тыйб (медиклар), хокук, электрика һәм башка фән белгечләре бар, һәм һәрберсе татар кешесе. Татар профессиясеннән тыш татар музыкантлары, җырчылары, татар скрипкачылары да бар монда. Хикәяләүче клубның китапханәдә булуын әйтә һәм газеталарда мондый хәбәрләр күрә: «Татар студентларының Англиядәге тормышы Бохарадагы яңа гимназияләргә татар мөгаллимнәре чакырылуы һәм башкалар. Ләкин болар барысы да төш икән, ә чынбарлыкта гает көне ыгы–зыгы белән тула. Мәчеттән чыккан кешеләр дин, фән турында уйланмыйлар, безнең мулла иртәрәк укып бетерде дип мактанышып утыралар. Мулла үзе дә гает көне турында түгел, күбрәк сәдака җыю турында уйлый.

1909 елда язылган беренче пьесасы «Яшьләр» дә дә татар тормышын башкача күрү теләге көчле. Бу драмада аталар һәм балалар арасындагы көрәш яктыртыла. Аталар лагерына сәүдәгәр Хөсәен, хатыны Мәрьям, кияүләре Рәхимҗан, олы кызлары Фәхерниса, балалар лагерына милләт өчен көрәшкән аннан өч яшькә кечерәк кызу канлы энесе Йосыф, йомшак табигатьле сеңелләре

Зәйнәп керә. Әсәрдә татарларның искечә яшәү рәвешләре тәнкыйтьләнә. 30 градус эсседә дә татарлар чапан, мамык шәл бөркенеп йөриләр, төрле им-томнарга, өшкерүләргә ышаналар. Әтиләре Хөсәен бакчада кызлар белән сөйләшеп йөргән өчен Газизәгә ташлана, Ә Газиз беләң Йосыф исә мулла һәм сәүдәгәрләрнең бозыклыкларына күз йома алмыйлар. Мондый яшәү рәвеше кешелеклелек сыйфатларын бетерә диләр. Ачык мисал – апалары Фәхерниса. Моннан 10 ел элек ул да чибәр, йомшак табигатьле, мөлаем кыз була. Хәзер исә ул зәһәр хатын. Ни өчен? Моңа Газиз җавап бирә. Башта ул усал кайната һәм кайнана изүе астында яши. Алардан котылгач ике тапкыр көндәш белән яшәргә мәҗбүр була. Хәзер исә атнасына ике тапкыр фәхешханәдән эзләп алып исерек ирен өенә алып кайта. Мондый тормышта яшәгән хатын-кыз – ди Газиз, көчсез булса чахоткадан үлә, көчле булса Фәхерниса кебек зәһәр хатынга әверелә.

**«Татар кызы»**

Әсәр башында эпиграф рәвешендә түбәндәге сүзләр китерелә, «тереләй күмелергә теләмәгән мөселман шәрекъ кызларына багышлыйм». Фатих.

Әсәрдә татар кызына традицион мөнәсәбәт кара көч символик образ аша бирелә. Туганнан алып алты яшькә кадәр татар кызы иркен яши. Аны ир баланы яраткан кебек яраталар һәм ул ир-балалар белән бергә уйный. Әмма 7 яшькә җиткәч, аңа абыйсы яки энесе булса, ул түзеп торырга тиеш, чөнки «кыз бала ир балалар белән сугышырга тиеш түгел». Шуннан соң кара көч аның әкрен генә иркен буа башлый. Башта ул үзенең хокуксызлыгын нигә? ни өчен? – дип сораса да, соңрак бу көчкә буйсына. Уку яшенә җиткәч аны абыстайга бирәләр. Абыстайда 3 ел буена кыздан җанлы курчак ясауны дәвам итәләр. 13 яшьтә кызга капчык кебек зур, бөтен җирне каплый торган чапан бирәләр. Чөнки кыз кеше башкаларга күренергә тиеш түгел. Соңрак аны дүрт стена арасына бикләп куялар. Бер бүлмә

аның өчен Азия да, Африка да була, урман да, елга да була. Кызның бердән-бер күңел ачу чарасы тәрәзәгә карау. Ә якшәмбе көнне аны тәрәзә яныннан да куалар, Һәм ниһаять кызны Биктимер исемле кешегә ярәшәләр. Атасы, анасы кызга кат-кат әйтәләр «ирең хакы – тәңре хакы, иреңнең аяк астында туфрак бул, синең вазифаң ирeңә уенчык булу һәм бала табу». Әлбәттә кыз каршы сүз әйтә алмый. Моны күреп кара көч кычкырып көлә, «татар кызы җанлы курчакка әйләнде, татар кызын терелəй күмделәр» – ди.

**«Хәят»**

Бу повесть Фатих Әмирхан прозасының иң күренекле үрнәге. Әсәрдә әле 16 яше дә тулмаган Хәятнең хис-кичерешләре тасвирлана, аның күңелендә Михаилга карата кызыксыну уяна. Әмма акылы рус егетенә карата булган бу хиснең үсешенә юл куймый. Повестьның төп сюжет сызыгын –Хәят күңелендә барган үзгәрешләр тәшкил итә.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

Ф. Әмирханның әдәби иҗатын иңләгән мәсьәләләрне аерып күрсәтегез?

Әдип иҗатында тергезелгән идеал татар тормышының моделен сурәтләгез?

Фатих Әмирхан нинди әдәби юнәлеш вәкиле?

Язучы үз иҗатында нинди модернистик агымнарның формаларын һәм алымнарын сыный?

Әдип иҗатындагы төп темаларны атагыз?

Ф.Әмирханның, каләменә нинди әдипләр йогынты ясаган?

«Хәят», «Сүнгәч», «Бер хәрабәдә» һ. б. әсәрләрендәге фәлсәфи, мәсьәләләр тирәсендә әдипнең уйлануларын, бәя-хөкемнәрен күзәтегез.

Әсәрләргә таянып, яшьләрнең рухи-фикри үсеш баскычларын аерып чыгарыгыз («Яшьләр», «Урталыкта», «Тигезсезләр» һ. б.).

«Язучы иҗатында хатын-кыз портреты» дигән темага инша языгыз.

**Контроль эш темалары**

Ф.Әмирхан хатларында әдәбият мәсьәләләре.

Әдипнең «Хәят» повестенда психологизм һәм хронотоп.

«Хәят» повестенда экзистенциализм фәлсәфәсенең чагылышы.

Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» драмасында күтәрелгән мәсьәләләр һәм аларның заманча яңгырашы.

Ф. Әмирханның «Бер хәрабәдә» хикәясендә сурәтләү алымнары һәм чаралары, үткәрелгән экзистенциаль фикерләр.

Әдипнең «Фәтхулла хәзрәт» повестенда, «Хәзрәт үгетләргә килде» хикәясендә сатирик рухани тибы.

Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повестенда буынара мөнәсәбәтнең чагылышы.

Драматургның «Яшьләр» драмасында яшь буын гәүдәләнеше.

«Яшьләр» драмасында милли чынбарлыкны яңарту юллары.

Әдипнең «Сүнгәч» хикәясендә мәхәббәт темасы.

«Халык кызлары» циклында тарихи мотивлар.

«Халык кызлары» хикәяләр циклында Зөһрә образы, аның идея-эстетик йөкләмәсе.

«Гарәфә кич төшемдә» хикәясендә авторның борчылу, сызлану сәбәпләре, автор файдаланган алымнар (төш – өн, реаль – ирреаль, матурлык–ямьсезлек һ. б.).

Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повестенда дин, тәрбия, әхлак мәсьәләләре.

Хатын-кыз образын тудыруда әдип файдаланган алымнар (психологизм, тирәлек, табигать, портрет һ. б.).

Сатирик әсәрләрендә әдип тарафыннан отышлы файдаланылган алымнар.

Әдипнең «Урталыкта» романының сюжеты һәм композициясе, аларның үзенчәлекләре.

«Урталыкта» әсәрендә күтәрелгән мәсьәләләр һәм язучы тарафыннан якланган фикерләр.

Язучының яшәү мәгънәсен мәхәббәттә, матурлыкта билгеләгән «Кадерле минутлар», «Яз исереклегендә» хикәяләре, сәнгати үзенчәлекләре.

Яшәү кыйбласын эзләүгә, үткәндә калган мәхәббәткә, яшьлеккә мөнәсәбәттә яшәү-үлем, яшьлек, матурлык, дин кебек мәсьәләләр тирәсендә уйланулар («Картайдым», «Сүнгәч», «Бер хәрабәдә» хикәяләре), әсәрләрдәге алымнар, детальләр төрлелеге.

**Гамәли биремнәр**

1. Ф.Әмирхан иҗатында татар тормышын яңарту темасы

Ф. Әмирханның бай һәм катлаулы тормыш юлы, аның рухи ныклыгы һәм бөеклеге; күпкырлы эшчәнлеге.

Ф. Әмирхан – Яңарыш чоры әдибе, реалист һәм романтик язучы, милли әдәбиятны модернистик агымнарның сыйфатлары тасвирчаралары белән баеткан сүз остасы.

Әдип иҗатында татар тормышын яңарту, үзгәртеп кору юллары турында уйланулар, якланган фикерләр («Гарәфә кич төшемдә», «Яшьләр», «Тигезсезләр» һ. б.).

Язучының әдәби мирасында яшьләр темасының яктыртылышы, яшьләрнең рухи-фикри, мәдәни үсеш баскычлары. Әсәрнең сюжет, композиция үзенчәлекләре, сәнгатьчә эшләнеше («Яшьләр», «Тигезсезләр», «Урталыкта» һ. б.).

2. Ф.Әмирхан иҗатында хатын-кыз темасы

Ф. Әмирхан иждтында хатын-кыз темасы. Милли чынбарлыкта хатын-кызның хәле, урыны, иреге, бәхете кебек мәсьәләләр һәм аларны хәл итү юллары турында уйланулар.

Әдип тарафыннан тудырылган хатын-кыз образлары һәм аларга йөкләнгән идея-эстетик мәгънә: «җанлы курчак» («Татар кызы»), Зәйнәп, Фәхерниса, Хәят, Сәлимә, Рокыя, Гөлчиһрә, Нәфисә, Ләйлә һ. б. Авторның характер тудыру алымнары.

«Татар кызы», «Хәят», «Яшьләр» әсәрләрендә хатын-кыз темасы белән бәйле сюжет сызыклары. Әсәрләрнең иҗат методы мәсьәләсе, аларда күзәтелгән модернистик алымнар, чаралар һәм детальләрнең байлыгы.

3. Ф. Әмирхан – сатира остасы

Ф. Әмирхан – XX йөз башы татар әдәбиятында сатирик юнәлешне үстерүче, аны фаш итү, көлү сыйфатларын тирәнәйтүче әдипләрнең берсе.

«Фәтхулла хәзрәт» повесте, аның жанры һәм иҗат методы мәсьәләсе. Әсәрнең көлү объекты һәм фаш итү алымнары. Повестьның каршылыгын тәшкил иткән буыннар төрлелегенә бирелгән бәя.

Әдипнең сатирик хикәяләр циклына кергән «Бәйрәмнәр», «Көндезге сәхәр, яки рузасызлар», «Сәмигулла абзый», «Хәзрәт үгетләргә килде», «Габделбасыйр гыйшкы» әсәрләре. Аларда кире кагу, тәнкыйть итү күренешләренең һәм көлке тудыру алымнарының төрлелеге.

4. Ф. Әмирхан иҗатында фәлсәфи мәсьәләләр һәм тарихи тема

Әдипнең яшәү мәгънәсен, матурлыгын мәхәббәттә, аңа ирешүдә билгеләгән «Хәят», «Кадерле минутлар», «Яз исереклегендә» әсәрләре. Аларда мәхәббәт, хатын-кыз, табигать культы, психологизм, импрессионистик сурәтләр.

Кешенең рухи кыйбласын эзләү, үткәндә калган мәхәббәт, яшьлеккә мөнәсәбәттә яшәү, үлем, бәхет, дин кебек төшенчәләр турында уйлануларны гәүдәләндергән «Картайдым», «Сүнгәч», «Бер хәрабәдә» хикәяләре, аларның сәнгати үзенчәлекләре; экзистенциализм агымы белән бәйләнешләр.

Ф. Әмирханның тарихи риваять һәм легендаларга нигезләнеп язылган «Ай өстендә – Зөһрә кыз», «Сөембикә», «Картада оттырылган Зөлхәбирә» хикәяләре. Әсәрләрдә мифологик һәм фәлсәфи катламнар, татар милләтенең үткән һәм хәзерге тормышына бәя, аны үзгәртү юллары турында уйланулар.

**Әдәбият**

Әмирхан Ф. Әсәрләр 4 томда.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1984-1985. Т. 1. Хикәяләр (1907-1922). – 478 б.

Т. 2. Повестьлар, роман һәм драма әсәрләре. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1985.– 486 б.

Әмирхан Ф. 3. Әсәрләр / Төз. Д. Ф. Заһидуллина, Т. Ш. Гыйләҗев, Ә. М. Закирҗанов.– Казан: Мәгариф, 2002.– 319 б.

**Төп әдәбият**

Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – ББ.177-211.

Нуруллин И. Фатих Әмирхан / Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Т. 3. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.– ББ. 295-314.

Ганиева Р. К. Фатих Әмирхан ижаты – мәктәптә; Художественные поиски Фатиха Амирхана // Татар әдәбияты: традицияләр, бaгланышлар. – Казан: КДУ нәшрияты, 2002. – ББ. 213-223; 92-100.

Заһидуллина Д. Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – ББ. 48-50; 52-54; 84-88; 107-108; 122-123; 155-158; 161-162; 166-167; 179-180.

**Өстәмә әдәбият**

Әхмәдуллин А. Г. Ф.Әмирханнын драматургик мирасы / Дөреслеккә ирешү юлында: Мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Мәгариф, 1993. – Б.191-197.

Бәширов Ф. К. XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Фикер, 2002. – 287 б.

Гыйләҗев Т.Ш. XX гасыр башы татар әдәбияты / Татар әдәбияты. Теория. Тарих. – Казан: Мәгариф, 2006. – ББ. 138-205.

Заһидуллина Д.Ф. Кереш сүз / Фатих Әмирхан. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2002. – ББ. 5-12.

Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминева В. Р. Әдәби әсәргә анализ ясау. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 6.

Мәһдиев М. С. Фатих Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 86 б.; Яңа бистә прометее / Әдәбият һәм чынбарлык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – ББ. 29-68.

Миңнегулов Х.Й. Әхлак һәм әдәбият // Мәгариф. – 1999. – № 5. – ББ. 24-27.

Нигъмәтуллин Ә.Г. Әдип иҗатына бер караш // Мирас. – 1996.– № 1-2. – ББ. 30-34.

Нуруллин И.З. Фатих Әмирхан,– Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – Б.27.

Рәмиев З.З. XX йөз башы татар әдәбияты: Авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. – Казан: Школа, 2000. – ББ.45-61

Сайганов А. Эстетика Фатиха Амирхана и его место в развитии татарской литературы. – Казань: Татар. кн. изд–во, 1982.– 168 с.

Саяпова А. М. Поэзия Дардменда и символизм,– Казань: Казанский пед. ун–т, 1997. – С.111-117.

Фатих Әмирхан турында истәлекләр / Төз.: Ф.И. Ибраһимова, Р.У. Әмирхан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 255 б.

.

## : Шәриф Камал
## (1884-1942)

Әдип 1884 елда Пешлә авылында туа. Башлангыч мәктәпне Ләбәжә авылы мәдрәсәләрендә укый; Алга таба белем алу теләге белән чит илләргә – Төркиягә (Истанбул), Мисырга (Каһирә) барып чыга. Соңгысында хикәяче һәм новеллист Йосыф Брагый һәм журналист Мөхәммәт Габдеһе (Габду) иҗатлары белән кызыксынып китә һәм, 1903 елда бәхет эзләп Россиягә кайта, зур тормыш тәҗрибәсе туплый: күмер ташый, тимер юл төзәтә, балык тота һ. б.

Инкыйлаб елларында Петербургка китә, һәм Шәриф Камалда язучылык дәрте уяна. Беренче иҗат тәҗрибәләренең нәтиҗәсе булып 1906 елда «Сада» («Аваз») исемле шигырь җыентыгы дөнья күрә.

1907-1910 елларда туган авылында мөгаллимлек итә. 1910 елда «Вакыт» газетасында журналистлык эшчәнлеге җәелеп китә һәм әдип «Аң», «Шура» журналларында актив языша башлый.

Ш. Камал татар әдәбиятында хикәя-новеллалар остасы буларак таныла, һәм ул бу жанрны беренчеләрдән булып реалистик юнәлештә үстереп җибәрә. Беренче әсәрләре үк авторны талантлы һәм үзенчәлекле каләм иясе итеп таныта. Аларда тормышның төрле почмакларында, төрле шартларында яшәгән кешеләрнең күңелсез һәм фаҗигале язмышы сурәтләнә. Хикәяләрдә психологик конфликтның кешеләр мөнәсәбәтендәге яхшылык белән явызлык, кешелеклелек белән ерткычлык арасындагы котылгысыз каршылыкка, бәрелешкә нигезләнүе. Гади кешеләрнең авыр көнитешен һәм рухи фаҗига белән тулы язмышын гәүдәләндергән «Уяну» (1909), «Буранда» (1909), «Сулган гөл» (1909), «Сукбай» (1910) хикәяләре. Әсәр геройлары (Муса, Мостафа, Гали, Камәр) тормыш гаделсезлеге, рәхимсез чынбарлык тудырган бәхетсезлек корбаннары буларак тасвирланалар. Ш.Камал әсәрләрендә кеше бәхете мәсьәләсе кызыл җеп булып сузыла, бәхеткә, хаклыкка омтылышның бәхетсезлек чынлыгы белән каршылыкка керә. «Әүвәл-әүвәл заманда» (1910), «Бәхет эзләгәндә» (1911), «Чит илдә» (1912) һ.б. әсәрләрендә бу мәсьәлә бик ачык гәүдәләнә.

«Кычкырыш» (1910), «Бер картның тойгылары» (1910), «Нәфисә» (1912), «Эч пошулы» (1912), «Курай тавышы» (1912) һ.б. хикәяләрендә кешелеклелек тойгысы, инсаният идеясе чынбарлыктагы явызлык күренешләре белән бирелә, шуның нәтиҗәсендә туган бәхетсезлек, вөҗдан газабы, драматизм, фаҗига сурәтләнә. Әдипнең аерым хикәяләрендә гади кешенең рухи дөньясындагы матурлык, керсез саф хисләр, гомумкешелек кыйммәтләре калкуланып китә («Ике яхшы», 1910; «Ата», 1910 һ.б.). Авыл зыялылары образларын үзәккә куйган «Авыл мөгаллиме» (1910), «Шәкерт» (1910) хикәяләрендә авыл халкын агартырга, аңа аң-белем бирергә дәртләнгән мөгаллимнең авылдагы иске карашлы дин әһелләре, власть сакчылары белән каршылыкка кереп, авыр шартларда, газаплы уй-кичерешләр эчендә калуы сурәтләнә. Икенче хикәядә исә пишкадәм Гомәрнең киләчәк тормышы, яшәү мәгънәсе

турында фәлсәфи гамьнәре, аның күңелендә туган ризасызлык, канәгатьсезлек хисләренең табигатьтән килгән эчпошыргыч тавышлар, көйләргә төрелеп бирелә, аларга янәшә куела. Әдипнең кайбер хикәяләренә «дин һәм вөжцан» мәсьәләсе килеп керә. Кеше күңеленең, вөжданының дини тойгылар тәэсирендә тагын да ачылып, сафланып, яңарып китүе, ягъни камилләшүе кебек фәлсәфәнең «Гөлчәһрә», «Гает көн», «Бәйрәмдә еламыйлар, бәгырем» хикәяләрендә чагыла һәм аларда рус классигы Л. Толстой идеяләре гәүдәләнә.

Вакытлы шахтерларның авыр тормышын, яшәү рәвешен ямьсез, караңгы буяуларда сурәтләгән «Козгыннар оясында» (1910) хикәясендә, хыял белән чынбарлык бәрелеше нәтиҗәсендә өметләре җимерелгән эшчеләрнең, кешелек сыйфатларын югалта барып, тормыш төбенә тәгәрәүләре күзәтелә. Әсәр күп образлар системасы, кеше һәм табигать образларыннан: Госман карт белән Мәрьям, мулла, Насрый Гомәров, артельче Хәлил Моратов, Габделхәй, Садрый һ.б. тора. Тышкы портретларда автор геройларның характер сыйфатларын, эчке дөньясын ачуга омтыла. Шахтерлар тормышын, яшәү рәвешен, төс-кыяфәтләрен сурәтләгәндә, әдип ямьсезлек эстетик категориясе белән эш итә. Автор үзенең әсәрендә Мәрьям белән Госманның фаҗигасен бик тәфсилләп бирә. Насрый Гомәровта кешелек сыйфатлары, вөждан газабы баш калкыта, әмма аның үзара мөнәсәбәтен уңай якка үзгәртүдә, әхлаксызлыкка каршы көрәшүдә көчсезлеге сизелә. Хикәянең күңелсез финалына ишарә ясап саташу, төш алымнары һәм Госман карт тарафыннан чыгарыла алмаган көй янгырый. Әсәрдә импрессионизм билгеләре күзәтелә

Шулай ук, әдип иҗатында психологизм һәм аның алымнары киң урын алган. Әсәрләрдә кеше күңеленә, рухи халәтенә, хис-кичерешләренә автор өстенлек бирә. Аңа төрек язучысы Зыя Ушаклыгөл, рус әдибе А. П. Чехов иҗатларының йогынтысы бик зур була. Ш.Камал хикәя-новеллаларында пейзаж, табигать күренешләре кеше кичерешләренә, рухи халәтенә аваздаш, охшаш. Герой

кичерешләре табигать, тирәлек белән музыка кораллары тудырган моң, көй белән бәйләнешкә керә, якыная. Бигрәктә ул «Уяну», «Буранда» һ.б. хикәяләрендә ачык чагыла. «Сулган гөл» хикәясендә Камәрнең кичерешләре табигатьтәге моң; «Курай тавышы» әсәрендә малайның күңел дөньясы, авыр һәм якты уйлары, курай тавышы, халык җыры, җанлы табигать тавышлары, сандугач сайраулары, матурлык, сафлык, югарылык көйләре фонында сурәтләнә. Ә инде геройларның өметсез, хәсрәтле кичерешләрен әдипнең күп вакытта җансыз табигатьтән килгән тавышлар, ыңгырашу, шаулау, сызгыру, ыжгыру кебек авазлар, «йөрәк өзгеч» моң белән ассоциациягә керә («Бер картның тойгылары», «Буранда», «Уяну», «Сукбай», «Чит илдә», «Козгыннар оясында» һ.б.). Хикәядә язучы каһарманнарының исемнәрен атамый, әсәрне башлаганда кинәтлек, кыска, тыгыз фикерле җөмләләр, күп ноктала р, ярымтоның, йомшак тоннар, төсләр дә импрессионистик стиль күрсәткечләре булып торалар. Алар турында әдипнең замандаш тәнкыйтьчеләре Җ.Вәлиди, Г.Ибраһимов, Ш.Мәрҗани һ.б. бик күп төрле фикерләр әйтәләр.

Ш. Камалның XX йөз башы иҗат чорында әдәби осталыгының иң югары ноктасы булып «Акчарлаклар» повесте (1914) тора. Ул, балык тоту промыселларына, акча эшләү нияте белән бәхет эзләп, эшкә килгән вакытлы эшчеләрнең тормышын сурәтли. Геройларның рухи дөньясы, психологик кичерешләре, хис-тойгылары, кеше язмышы үзәккә куела. Әсәрдәге образлар төрлелеге: эшчеләргә хас матур, күркәм сыйфатларны үзендә гәүдәләндергән Шәрәфи карт образы – гадилеге, тыйнаклыгы, аек акыл, намуслылык, кешелеклелек, хезмәт сөючәнлеге һ. б. белән аерылып тора. Хезмәт кешесенең физик һәм рухи матурлык гармониясен үзендә гәүдәләндергән Гариф образы да әсәрдә үзенә бер мөһим урын алып тора. Газизә белән аның мөнәсәбәте әдәби әсәрнең иң якты, күркәм сызыкларыннан берсе булып бирелә. Фабрикантлар нәселеннән Федор, кичәге солдат Хөснетдин, укымышлы мәхдүм Гариф, Сафа, балык тозлаучы Шәрәфи карт, тыйнак, әдәпле, саф хисле Газизә,

сабыр, кайгыртучан Сәгыйдә һ.б. тормышчанлыгы, эш-гамәлләренең, теләк-омтылышларының реальлеге аерым сызыклар белән бирелә. Повестьта милләтара мәсьәләләргә, социаль-икътисади мөнәсәбәтләргә, иҗтимагый гаделсезлеккә урын бирелә.

Әсәр сәнгатьчә: җыйнак, кыска, тыгыз сюжетка корыла. Тормышчан, халыкчан реалистик повестьның романтик, импрессионистик стиль билгеләре белән баетыла.

Әсәрдә пейзаж зур әһәмиятле урын алып тора. Язучы диңгезне кешенең рухи дөньясы, көндәлек тормышы, яшәеше һәм бәхете турындагы хыяллары белән тыгыз бәйләнештә күрсәтә, ягъни диңгез табигате белән кешеләр мөнәсәбәтенең лирик-психологик чагылышын сурәтли. Табигать сурәтләре: ай, диңгез, давыл, җил, яфраклар, ябалак-карчыга, таракан-кырмыска, аеруча акчарлакларның геройлардагы эчке кичерешләре, аларнын тормышларын сурәтләүдән аерылгысыз була.

Ш. Камал иҗатында сатира һәм юмор үрнәкләре зур урын алып тора. Ул төш формасында бирелгән хыялый вакыйганы сурәтләп, татар чынбарлыгындагы җитешсез, кимчелекле якларны, мәгънәсез күренешләрне сатирик үткенлек белән фаш итә. Әлеге күренеш аеруча «Сәмруг кош» (1910) фельетон-хикәясендә чагылыш таба. Гайнетдин Гайнелисламов, хикәяләүче «мин», «чалыш аяклы, озын бишмәтле, тәбәнәк кеше»ләр – һәммәсе сатирик образлар булып, мәгънәсез хыял белән чынбарлык арасындагы бушлык көлкесен тудырулар. Татар җәмгыятен Аурупа цивилизациясенең, мәдәниятенең йогынтысыннан чикләргә омтылган иске карашлы дин әһелләре, тар милләтчеләр дөньясыннан, аларның мәгънәсез ыгы-зыгысыннан, буш мактану һәм кыланышларыннан сарказм алымы ярдәмендә үтергеч көлә. Шулай ук көлүнең вакытлы матбугат ирегe игълан ителгәч күбәеп киткән һәм татар милләтенең мөһим, актуаль мәсьәләләреннән читтә торган газета-журналларга каршы юнәлтелгән булуы да Ш.Камал иҗатына тагын да этәргеч бирә. Татар милләтенең өмет һәм теләкләрен үтәүдән халык мәнфәгатьләреннән ерак торган,

үзләре өчен генә яшәүче депутатларның сатирик образын зур осталык белән тудырган «Депутат» (1910) әсәре, «Холера вакытында» (1910), «Җимерелгән звонок» (1911), «Көзге яңгыр астында» (1913) һ.б. хикәяләрендәге «кечкенә кеше»ләрнең буш, мәгънәсез яшәү рәвешеннән, эш-гамәлләреннән, рухи хәерчелегеннән ирония ярдәмендә көлеп, аларның психологик портретларын тудыра.

Ш.Камал татар драматургиясен үстерүгә дә зур өлеш кертә. Драматурглык юлының уңышлы адымнарыннан берсе булган һәм кадимче татар сәүдәгәрләренең әхлаксызлыгына каршы юнәлдерелгән «Хаҗи әфәнде өйләнә» (1915) комедиясе була. Әсәр мәзәкчел сюжетка корылган. Үзәк герой Юныс хаҗиның азгынлыгы, саранлыгы, икейөзлелеге ислам дине мифологиясеннән алынган образлар, коръән өйрәтүләре, көлке тудыручы алымнар ярдәмендә фаш ителә.

Ш.Камал иҗатына эчке, яшерелгән ирония алымы хас. Артист Җәләл, шагыйрь Габделхак, мөгаллимә Камилә, мөгаллим образларының пьесада тоткан урыны, аларның комик ситуацияне тудыруда катнашулары, шуның бер үрнәге булып тора.

Әсәрдә татар зыялы яшьләренең өстенлеге, тапкырлыгы, үткенлеге тагын бер кат раслана. Шагыйрь Габделхак персонажында халыкчанлык идеяләре ачык гәүдәләнә. Язучы халыкка хезмәт итүнең зурлыгын, олылыгын чәчәкләр бәйләме кебек символик образ аша гәүдәләндерә. Шушы уңайдан авторның Тукай шигъриятенә, аның осталыгына мөрәҗәгать итүе дә күзәтелә. Әдип сатирик хикәяләрен һәм комедиясен Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Тукай, М.Фәйзи, Г.Исхакый иҗатлары белән бәйли.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

Ш. Камал иҗаты нинди әдәби юнәлешкә карый?

Аның әсәрләре нинди метод, агым алымнары, чаралары белән баетылган?

Язучы иҗатында күзәтелгән импрессионистик стиль билгеләрен аерып чыгарыгыз.

Әдип әсәрләрендә актив кулланылган детальләрне санагыз.

Ш.Камал тормыш сукмакларының иҗатына, эстетик кыйбласына тәэсирен күрсәтегез.

Язучының беренче чор иҗатына таянып, әдәби бәйләнешләр мәсьәләсен күрсәтегез.

Әдип әсәрләренең конфликт үзенчәлеген билгеләгез.

«Ш.Камал иҗатында матурлык» дигән темага язма эш башкарыгыз.

Ш.Камалның сатирик хикәяләрендә көлү объектлары һәм алымнары.

«Курай тавышы» хикәясендә психологизм, музыка, автор мөрәҗәгать иткән алымнар.

«Акчарлаклар» повестенда кешенең рухи һәм физик матурлыгы.

Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясендә төп һәм ярдәмче каршылыклар.

Әдип әсәрләрендә сезонлы эшчеләр тормышын сурәтләү («Козгыннар оясында», «Акчарлаклар»).

Әдип иҗатында портрет.

Әдип ижатында табигать тасвирлары, пейзаж («Уяну», «Буранда», «Бәхет эзләгәндә», «Сукбай» һ. б.).

Ш. Камал хикәяләрендә хронотоп.

«Сулган гөл» хикәясендә автор файдаланган алымнар, сурәтләү чаралары.

Әдип иҗатында хикәя жанры.

Ш. Камал хикәяләрендә «кече кеше» темасын сурәтләү үзенчәлекләре («Көзге яңгыр астында», «Күңелсез эш», «Бер картның тойгылары» һ. б.).

Ш. Камал хикәяләрендә шәхес фаҗигасе.

**Гамәли биремнәр**

Шәриф Камал иҗаты. Әдипнең тормыш мәктәбе, рухи-фикри эзләнүләре, журналистлык эшчәнлеге, татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы.

Кече эпик жанрда уңышлы һәм актив эшчәнлеге, күзәтелгән тематик төрлелек, конфликт үзенчәлеге.

Язучының хикәяләрендә яшәү-үлем, гомер итәсе килү, сызлану кебек экзистенциаль мәсьәләләрнең, шәхес фаҗигасенең чагылышы («Уяну», «Буранда», «Курай тавышы», «Бәхет эзләгәндә», «Чит илдә» һ. б.).

Әдип реализмының импрессионистик алым һәм чаралар белән баетылуы, иҗатында психологизм, ул мөрәҗәгать иткән алымнар, әдәби детальләр («Сулган гөл», «Козгыннар оясында» һ. б.).

«Акчарлаклар» повестеның сюжет сызыклары, кешеләрдәге эчке һәм тышкы матурлыкка дан җырлау, анда күтәрелгән гомумкешелек һәм иҗтимагый-социаль мәсьәләләр, повестьта күзәтелгән романтик, импрессионистик һәм натуралистик алымнар.

Әдип мирасында сатира. «Депутат», «Сәмруг кош», «Көзге яңгыр астында» хикәяләрендә көлү объектлары, автор мөрәҗәгать иткән сатирик алымнар. «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясендә конфликт үзенчәлеге, көлкеле хәл һәм ситуацияләр.

**Әдәбият**

Камал Ш. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 380 б.

Камал Ш. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 446 б.

**Төп әдәбият**

Нуруллин И. З. XX йөз башы татар әдәбияты.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – ББ. 138-142.

Халит Г. М. Шәриф Камал / Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Т. 3.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.– ББ. 315-337.

Ганиева Р. К. Татар әдәбияты: традицияләр, багланышлар.– Казан: КДУ нәшрияты, 2002. – ББ.198-212.

**Өстәмә әдәбият**

Әхмәдуллин А. Г. Акчарлаклар / Әдәбият (ХХ йөз башы һәм 20 нче еллар): Унберьеллык урта мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек.– Казан: Мәгариф, 1994.– ББ.89-98.

Гыйләҗев Т. Ш. ХХ йөз башы татар өдөби-гыйльми фикерендә психологизм мәсьәләсе (Шәриф Камал иҗаты мисалында) // Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар. кит. нөшр., 2005.– ББ. 132-137.

Заһидуллина Д. Ф. Модернизм һәм ХХ йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2003.– Б. 158-160.

Мәрдиева М. Б. Мәкалә һәм фельетоннар остасы // Әйдә, халыкка хезмәткә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985.– ББ. 157-169.

Нуруллин И.З. Шәриф Камал иҗаты – Казан: КДУ нәшрияты, 1963.– 70 б.; Образлар дөньясында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964.– 140 б.

Халит Г.М. Кешегә һәм чынбарлыкка мәхәббәт белән. – Казан: Татар, кит. нәшр., 1975.– ББ. 51-75.

## ТЕМА 4. ХХ ЙӨЗ БАШЫНДА ПОЭЗИЯ

**Аннотация**: ХХ гасыр башында милли поэзиянең күтәрелеп китүенә йогынты ясаган төп сәбәпләр. 1905 елгы инкыйлаб чорында шигърият мәйданына күпләп шагыйрьләрнең чыгуы. Шигырьләрдә мәгърифәтчелек идеяләренең гражданлык хисләре белән сугарылуы. Инкыйлаб чоры поэзиясенең символик образларга мөрәҗәгать итүе, аңа публицистик аһәң, риторика хас булу. Милли һәм социаль азатлык хәрәкәте көчәю, иҗтимагый-сәяси тормышка, мохитка

тәнкыйть мөнәсәбәтенең тирәнәюе нәтиҗәсендә шигърияттә сатирик, сәяси лириканың калкулануы.

**Мөһим сүзләр:** диңгез, җил, давыл, таң, кояш кебек символик образлар;

**Теманы өйрәнүгә медодик рекомендацияләр**: Тема лекция формасында укытыла. Практик дәресләрдә студент күбрәк үзлегеннән эшли.

**Глоссарий**. Контраст – кеше характерының, предметның, күренешнең үзенчәлекләрен, сыйфатларын икенчесенә капма-каршы кую.

Татар шигъриятенең күпгасырлык тарихы, традицияләре бар. XX гасыр башында поэзия кинәт үсеп китә һәм моңа ким дигәндә 2 сәбәп табып була:

1) татар шигъри традициясенең кинәт көчәеп китәрлек көч саклап кала алуы,

2) матбугат дөньясына ишек ачылу, азатлык, хөрлек хисләре уяну.

Матбугат илнең төрле шәһәрләрендә чыга, газета һәм журнал битләрендә Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Миргазиян Укмасый һ.б. шигырьләре даими басылып тора. Хәтта алар гына түгел, драматург Мирхәйдәр Фәйзи, хикәяче Шәриф Камал да шигырьләрен бастырып чыгаралар.

Шигырьләрдә революциядән көткән өметләр сурәтләнә, азатлыкка дошманлыкка нәфрәт һәм ләгънәт җырлана.

Бу еллар поэзиясендә җил, дулкын, кораб кебек образ-символлар зур урын ала. Мәсәлән, Н.Думавиның «Революция заманы» шигырендә болай диелә:

Дулкынланды океаннар бу көннәрдә,
Томанадыр күңелләр һәм бу көйләрдә.
Талпынадыр мәмләкәтнең кораблары,
Сизелмәсә батып китәр бөтенләй дә.

Шуңа охшаш образлар Тукай, Дәрдмәнд, Гафури әсәрләрендә дә күренә.

Киң кулланылган икенче символик сурәт – таң ату, кояш чыгу, яктыру. Бу образлар С.Рәмиевнең «Таң вакыты» әсәрендә, мәсәлән, татар халкының уянуына, азатлык хәрәкәтенә кушылуына ишарә итә.

1905 ел революциясе татар поэзиясен халык, милләт, Ватан азатлыгы идеяләре белән сугара.

Икенче яктан шагыйрьләр изелгән хезмәт иясенә теләктәшлек итәләр. Димәк, азатлык идеясе белән бергә халык темасы әдәбиятта алга чыгарыла. Бу мотив, аеруча 1905 елгы революция җимерелгәннән соң көчәя. Реакция чорында Г.Тукай, М.Гафури иҗатында ул шактый тулы чагылыш таба. Мәсәлән, М.Гафури «Мин кайда» дигән шигырендә үзенең позициясен болай билгели:

Кайда ярлы, кайда зарлы, кайда моңлы күп була –

Мин алар янында булам, алар белән килешеп була, – (1912)

«Үзем һәм халкым» шигырендә автор үзенең халыктан беркайчан да аерылмаячагын әйтә.

XX йөз башы татар поэзиясе иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга, тарихи фактларга, заман рухына үз мөнәсәбәтен тиз, ачык һәм кискен белдерә. Бу яктан ул Тукай шигъриятендә аеруча да сизелә («Китмибез!», 1907).

Инкыйлаб еллары поэзиясендә реализм һәм халыкчанлык җәһәтеннән борылыш ясала, аерым әдипләр иҗатында Россия кичергән иҗтимагый-социаль тетрәүләре, икътисади һәм рухи гариплекләрнең экспрессионистик әдәбиятка хас билгеләр, алымнар белән сурәтләнүе күзәтелә. Бигрәк тә бу күренеш Нәҗип Думави иҗатында ачык чагылыш таба.

1908-1910 еллар шигъриятендәге сыйфат үзгәрешләре, аның сәбәпләре – инкыйлаб чигенеп, кара реакция еллары башланып, лирик геройның рәхимсез иҗтимагый-сәяси чынбарлык белән конфликты тирәнәю нәтиҗәсендә туган драматик, фаҗигале күңел кичерешләренә игътибар арту, өметсезлек, төшенкелек, кайгы-хәсрәт

мотивлары килеп керә. Милли поэзиянең тәнкыйди реализм принципларын үзләштерү белән бергә романтик сурәтләү алымнары, чараларына мөрәҗәгать итү арта. С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Ш. Бабич һ.б.ның әсәрләре шигърияткә яңа сулыш өрә. Чор поэзиясе идея-эстетик яктан катлауланып, аның тематикасы киңәя. Шагыйрь, шагыйрь-гражданин, шагыйрь-пәйгамбәр, мәхбүс, тоткын образлары калку итеп бирелә. Аларны тасвирлауда күзәтелгән традицион-романтик шартлылык, Аурупа-рус романтизмы һәм традицион романтизмның синтезы күзәтелә. С. Рәмиев, Ш. Бабич иҗатларында гыйсъянчылык мотивлары зур урын ала. Г. Тукай, М. Гафури һ.б.ның да үз шигырьләрендә табигать, мәхәббәт, хатын-кыз культы кебек романтик эстетиканың атрибутларына мөрәҗәгать итүләр арта. Милләт язмышы, аның киләчәге, яшәү һәм үлем, тәкъдир, язмыш, кеше гомеренең чикләнгәнлеге, вакытның мәңгелеге кебек фәлсәфи уйланулар, гамьнәр тирәнәя. Сәнгатьчә эшләнеше, художестволылыгы ягыннан шигърият яңа баскычка күтәрелә, традицион образларның мәгънәви яктан үзгәреше, символик эчтәлекле яңа образлар барлыкка килүгә китерә. Шагыйрьләр иҗаты халык, милләт язмышыннан аерылгысыз булып формалаша.

## XX гасыр башы татар әдәбиятының лирик герое

Ул революцияне кабул итә, реакциягә нәфрәт хисе белән яна. Милләтнең мәгърифәтле, якты киләчәгенә гашыйк, бәхетле язмышына ышана һәм бик кыю фикер йөртә. Шуңа карамастан бу лирик герой явызлыкка каршы һөҗүмнең бөтен газабын, бөтен авырлыгын үз җилкәсендә татыган.

Мәсәлән: С.Рәмиевнең «Алданган» шигыренә күз салыйк

Көн – авыр, төн – бер кабер бер,
Ел тоела сәгатем.
Әрни-әрни ләгънәт әйтәм
Тискәре бу дөньяга,
Мин мәхәббәт нуры дим, ул

Аерылу шәмен яга.

Шигърияттә реализмда үсә, ягъни лирик геройның кичерешләре чынбарлык, тарихи вакыйгалар белән бәйләнештә күрсәтелә. Шундый поэзиянең иң гүзәл үрнәкләрен Г.Тукай иҗат итте. Аның героеның эчке дөньясы тирән һәм катлаулы, ә Дәрдмәнд белән Рәмиевнның геройлары чагыштырмача гадиерәк яктыртыла.

Реакция елларында әдәбиятта төшенкелек, өметсезлек мотивлары көчәеп китә, ләкин бу өметсезлек ниндидер шәхси субъектив сәбәпләр аркасында түгел, ә халык өстенә төшкән авырлыкны зур газап белән кичерү нәтиҗәсендә туа.

Бу елларда лирик әсәрләрдәге шагыйрь образы да үзенчәлекле була. Беренче иҗат адымнарыннан ук Г.Тукай шагыйрьнең бурычы итеп дөреслекне күрү һәм язу дип әйтә. Ул дөньяга оптимистларча карый.

Горур һәм көчле ихтыярлы С.Рәмиев әсәрләрендә шагыйрь образы икенче төрлерәк бирелә: ул ялгыз, өметсезлек, төшенкелек мотивларын җырлаучы.

Икенче этап: 1910 елларда татар поэзиясе.

1910 еллар тирәсендә эшчеләр хәрәкәте кабат җанланып китә, яңа революцион күтәрелеш башлана. Татар шигърияте дә шуңа бәйле рәвештә үсә. Узган елларда явыз чынбарлыкка каршы куелган трагик герой образы үзәккә алынган иде. Реакция елларында шагыйрь һәм (гавам) герой концепциясенең көчәюе күренә. Шагыйрь һәм (гавам) герой арасында бернинди уртаклыкта юк. Романтик герой түбән тормышның көндәлек вак мәнфагатьләре белән яшәүче гавамнан югарырак итеп сурәтләнә һәм үзенең ялгыз горурлыгын гавамның яраклашып яшәвенә каршы куя. Бу аеруча М.Гафури, С.Рәмиев, Г.Тукай иҗатларында калку күренә. Шагыйрьләрдә реализм да үзәктә тора. Җиңелү белән килешмәгән әдипләр азатлык идеалогиясенә тугъры калалар, реакциягә каршы көрәшләрен дәвам итәләр. Аның явызлыгын фаш итәләр. Үзләренең төп бурычлары итеп халыкчанлык, тормышчанлык идеяләрен алга сөрәләр.

1910 еллар тирәсендә әдәбиятка яшь шагыйрьләр һәм яшь шагыйрәләр килә. Аларның иҗат мөмкинлекләре дә, сәләтләре дә төрлечә була. XX гасыр башы татар поэзиясенең икенче буыны вәкиле – Зыя-Ярмәки, Сәгыйть Сүнчәләй, Гыйффәт Туташ, Фәтхи Бурнаш һ.б. Аларның күбесе Тукай шигърияте йолдызлыгы астында туа. Тукай шигырьләрен укып тәрбияләнә. идея-эстетик якынлык мотивлар уртаклыгы – аларны Тукай – әдәби мәктәбе вәкилләре дип атарга мөмкинлек бирә.

Күргәнебезчә XX гасыр башы шигъриятендә реализм да, романтизм да зур урын алып тора. Романтизм – кеше характерының кабатланмас якларын алга чыгарып сурәтләде. Киң колач җәйгән мәгърифәтчелек реализмы исә уңай һәм тискәре геройларны яхшы һәм яман контраст итеп сурәтләп геройның индивидуальлегенә тиешенчә игътибар бирмәде. Гасыр башында үсеп киткән критик реализм боларның икесенең дә тәҗрибәсен үстерде. Ул кеше психологиясенең бер үк вакытта типик, тирә-якка һәм җәмгыятькә бәйле һәм бер үк вакытта кабатланмас булуына басым ясады.

## 1914-1917 еллардагы империалистик сугышның татар шигъриятенә йогынтысы

Бу сугыш шагыйрьләрнең идея-эстетик аңына кискен тәэсир ясый. Нәтиҗәдә шигъриятә яңа образлар һәм яңа сурәтләр туа. Аеруча күңел төшенкелеге, өметсезлек мотивлары өстенлек итә. Тормыштагы күпчелек очракта явызлыкның тантана итүе күпләрне «язмыштан узмыш юк» дигән фикергә китерә. Язмыш төшенчәсе илаһи һәм бер үк вакытта һәлакәтле төс ала. Мәсәлән, мисал итеп М.Гафуриның «Юктырсың ла, ала?», «Язмыш» шигырьләрен китерергә була. Моннан тыш «Сукбай», «Артык кеше», «Теләнче кыз», «Качкын» һ.б. образлар формалаша.

Элек шигырьләрдә бәйрәм һәм мәҗлес образлары чынбарлыкка каршы куеп сурәтләнсә, хәзер исә реаль тормыштагы бәйрәмнәр дә

күңелсез итеп тасвирлана. Әмма М.Гафури, С.Сүнчәләй кебек шагыйрьләр барыбер кайчан да булса бәйрәм киләчәгенә өметләнеп иҗат итәләр.

Унынчы елларда татар поэзиясенә шагыйрьләрнең икенче буыны килә:
С. Сүнчәләй (1889-1937), З. Ярмәки (1887-1965), Г.Харис (1893-1931), Г. Сөнгати (1894-1917), М.Фәйзи (1891-1928), Ф. Бурнаш (1898-1942), Н. Исәнбәт (1899-1992), Г. Сәмитова (1862-1929), М. Мозаффария (1873-1945), М. Вәлиева (Вәлиди) (1894-1925), З. Бурнашева (1895-1977), Х. Шаммасова (1875-1949), З. Сәгыйдә (1897-1994) һ.б. шуларга дәлил булып торалар. Иҗади мөмкинлекләре, талантлары төрле дәрәҗәдә булуга карамастан, унынчы еллардагы милли шигъриятнең эчтәлеген һәм юнәлешен билгеләү ноктасыннан ул шагыйрьләрнең үз урыннары, үз рольләре барлыкка килә. Татар әдәби-эстетик фикерендә психологизмга игътибар арта, Аурупа әдәбиятының йогынтысы, милли азатлык идеяләре белән тыгыз бәйләнештә күтәрелеп киткән романтизмның яшь шагыйрьләрнең иҗат юнәлешен билгеләгән төп эстетик факторларның берсенә әверелә. Аларның күпчелегендә Г. Тукай, М. Гафури, С. Рәмиевләр буыны тудырган демократик әдәбият традицияләре дәвам ителеп, реалистик һәм романтик тенденцияләр үстерелә.

Ш. Бабич, С. Сүнчәләй, М. Фәйзи, Г. Сөнгати, Х. Шаммасова һ.б. шигъри әсәрләрендә Тукай шәхесенең Урта гасыр татар әдәбияты традицияләрендәгечә илаһилаштырылып, аның шагыйрьлек роленең суфичылык әдәбиятыннан, Шәрык әдәбиятыннан килгән образлар аша калкуландырылып, идеаллаштырылып сурәтләнелә. Ш.Бабич, С.Сүнчәләй, Х. Шаммасова, З.Сәгыйдә, З.Бурнашева шигъриятләрендә Тукайның иҗат традицияләре, шагыйрь тудырган әдәби мәктәпнең билгеләре, тенденцияләре аеруча көчле була. Кырыс, рәхимсез, золым белән тулган чынбарлыкка, караңгылыкка лирик геройның күңел матурлыгы, өмете, якты хыялы каршы куела (Ш. Бабич, С.Сүнчәләй, Г.Харис һ.б. иҗатында). Унынчы еллар

поэзиясе өчен Ватан, ил, халык язмышы, социаль контрастлар, иҗтимагый гаделсезлек мәсьәләләренең чит булмавы хас. Аның аеруча Г.Тукай, М.Гафуриларның иҗат йөзен билгеләп, шигъриятнең икенче буыны вәкилләре – С.Сүнчәләй («Ил җыры» (1910); «Җыр» (1911); «Ярлы җыры» (1914)); З.Сәгыйдә («Нигә соң алай?», (1915)) һ.б. шигъриятендә тасвирланулары күзәтелә. Романтик поэзиянең табигый юлдашы булган музыканы илаһилаштырып, матурлыкны эзләп, табигатькә мөрәҗәгать итү, милли тойгыларның көчәюе, хатын-кыз гүзәллегенә баш ию, илаһи мәхәббәткә, явыз чынбарлыкка сабыйлык сафлыгын каршы куюы унынчы еллар шигъриятендә урын ала: Ш. Бабич («Мандолин», 1914; «Скрипка», 1915; «Кил, Сабия»); С. Сүнчәләй («Авыл», 1912; «Мәхәббәтем», 1913; «Кыз», 1914); М. Вәлидия («Мандолинага», «Мәхәббәт») һ.б.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында милли шигърият, татар шагыйрьләренең аңа мөнәсәбәте, поэзиянең идея-эчтәлеге кискен үзгәрә, хис-кичерешләр киеренкелеге күзәтелә, яңа темалар, мәсьәләләр килеп керә, эстетик фикерләүнең романтик төре тагын да куәтләнә. Чорның кырыслыгы, кешелеккә сугыш китергән физик һәм рухи гариплекләр, бәла-казалар шагыйрьләрнең дөньяга карашларын катлауландырып җибәрә, татар әдипләренең идея-эстетик эзләнүләренең чагылышы буларак модернистик агымнарга, аларга хас сурәтлелеккә, алымнарга мөрәҗәгать итүләре арта. Сугыш афәте Г.Сөнгати («Яз көткәндә», 1916); М.Укмасый («Дошманга», «Әсир төшкәч», 1916) һ.б. солдат-шагыйрьләр иҗатында кырыс рәхимсезлеге, мәрхәмәтсезлеге белән чагыла. Аеруча М.Гафури, Ш.Бабич, С.Сүнчәләй, Н.Думавиларның сугыш фаҗигасен, тормыштагы тоташ ямьсезлекне, тантана иткән явызлыкны авыр кичерүләре, аның сәбәпләре турында уйланулары, шул ук вакытта, сугыш бетеп, якты таң тууга өмет-ышанычлары чагыла. «Сугыш һәм язмыш» проблемасына бәйле рәвештә татар поэзиясендә «артык кеше», «гаепсез җинаятьче», сукбай, качкын, теләнче кебек образлар

формалаша, алар язмыш корбаны буларак тасвирланалар (Г. Шәрифи. «Теләнче», (1916); Н. Исәнбәт. «Артык кеше», (1916)).

Унынчы елларда романтик поэма һәм балладалар активлаша, алар электән килгән традицияләрне үстерeләр, яңа сыйфатлар белән баетылалар. Лиро-эпик жанр формаларында, сюжет һәм композициядә, геройларны сурәтләү алымнарында төрлелек күзәтелә:

а) фольклор әсәрләренең сюжетын иҗади файдалану: Кыяметдин Юлдашев («Чура батыр» һ.б.);

ә) Аурупа-рус әдәбиятларындагы романтик поэмаларны татарчалаштыру яисә аның сюжетын милли шартларга җайлаштырып үзгәртеп эшләү (С.Сүнчәләй. «Галиб», «Шильон мәхбүсе», «Әлмансур»);

б) дини мифологиягә мөрәҗәгать итү (М.Гафури. «Адәм вә Иблис», «Рисаләт»; Г. Сөнгати. «Хозыр» һ.б.). Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт, Г. Ибраһимов һ.б. ның бу төрдә уңышлы эшләүләре күзәтелә.

## ТЕМА 5. Г.ТУКАЙ. ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ ИҖАТЫ (1886-1913)

Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев 1886 елның 26 нчы апрелендә Казан артындагы Кушлавыч авылында дөньяга килә. Язмыш сабыйга карата кырыс һәм рәхимсез була. Кечкенәдән кулдан-кулга йөрергә мәҗбүр була, һәм һәр җирдә диярлек аңа артык тамакка караган кебек карыйлар. Ниһаять Яңа Бистә һөнәрчеләре Мөхәммәтвәли белән Газизә аны тәрбиягә алалар. Монда ул ике ел яши һәм гади һөнәрчеләр балага үзләренең күңел җылысын бирергә тырышалар. Ләкин икеседә кинәт кенә авырып китәләр һәм Габдулланы кире бабасы янына Өчилегә җибәрергә мәҗбүр булалар.

Шагыйрь күңеленә зур тәэсир ясаган икенче урын – Кырлай авылы. Сәгъди абзыйлар йортында 3 ел яши (1892-1895), һәм бу елларда крестьян тормышының матурлыгын да, авырлыгын да күрә. Хәзер инде ул зуррак яшьтә эти-энисенең кул арасына керә башлый

һәм беренче тапкыр укырга бара. Шагыйрь үзе бу җирне «күзем ачылган урын» дип атый.

1895 елны Кырлайдан Уральскийга атасының сеңлесе Газизә Зәбирова йортына тәрбиягә алына. Шул ук елны Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсенә укырга керә. Мәдрәсә каршындагы рус классларында дәресләр ала. Бу мәдрәсә иске типта булса да шәкертләргә азмы–күпме ирек бирелә. Шунысы да әһәмиятле, бу елларны җаек (уральск) татарлары яңача укыту хәрәкәтенә тартыла башлыйлар. Тукай мәдрәсәдә иң зирәк, иң үткен шәкертләрдән санала, һәм яңа үзгәрешләр тәэсиренә бик тиз бирелә.

1905 елгы революция алдыннан булган вакыйгалар (мәктәпләрдә реформа таләп итү, алдынгы мәдәният белән кызыксыну һ.б.) Тукайның аңы, зиһене үсешенә зур йогынты ясыйлар.

1905-1907 елгы революция Тукай шигъриятенең халыкка һәм милләткә хезмәт итүгә чакыруына этәргеч ясадылар. Тукайның әдәби теләкләре, хөр фикерләре уяна башлауга тагын бер әһәмиятле фактор йогынты ясый. Ул рус әдәбияты белән якыннан таныша, рус әсәрләрен тәрҗемә итә (Крылов баснялары).

Казан чоры иҗаты исә татарларның мәдәният үзәге булган башкалабызга килеп эләгү, атаклы әдипләр, ә соңыннан якын дуслары – Сәгыйть Рәмиев, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал һ.б. белән танышуы белән истәлекле.

**Иҗаты**

Башлангыч чор иҗатында ике мотив өстенлек итә:

1) изелгән гади кеше язмышына теләктәшлек. Бу төр шигырьләрдә рус поэзиясенең рухы сизелә. Мәсәлән, «Мужик йокысы» дигән шигыре, рус классик язучы А.В. Кольцовтан тәрҗемә ителә. Ләкин ул тәрҗемә әсәр буларак түгел, гади кеше язмышын сурәтләүче халык темасына язылган әсәр буларак кызыклы.

Ник йоклыйсың, мужик?
Яз җитте һәм үсте

Чирәмнәр йортында:

Тор, уян, күтәрел!

Үз-үзеңә кара:

Кем идең, кем булдың?

Нәрсә бар милкеңдә? –

Дөрес мужикның «бишмәте таланган, күлмәге сәдәфсез, өе балчыктан, бөкрәйгән карчыктай» булуында автор ялкаулыкны гаепли, тырышлыкка өнди. Әмма шул ук вакытта шагыйрь бу мужикның язмышы  өчен борчыла.

2) иң күренеклесе – азатлыкка, хөрриятkә чакыру. Мисал өчен «Дусларга бер сүз» шигырен китерергә була:

Барып керик хөрриятнең кочагына,

Тәрәккыйның (прогресс) күкләренә очмагына.

Революция елларында Г.Тукай татар вакытлы матбугатын булдыруга һәм ныгытуга зур тырышлык куя. Ул «Фикер», «Әлгасрел җәдит», «Уклар» кебек газета-журналларда наборщик һәм корректор булып кына эшләми, ә төп авторларның берсе дә була. Аеруча татар юмористик һәм сатирик журналын «Уклар»ны тулысынча хәзерләп, редакцияләп бара. Бу журнал ярдәмендә ул ирекле матбугат үрнәген тудырырга тели.

Гомумән алганда исә Тукайның башлангыч чор иҗатында шул елларның публицистик рухы сизелә.

Үзенең шигырьләрендә Тукай политик активлык та күрсәтә. Мәсәлән, Думаның халыкны коллыктан коткара алмавын, ач крестьяннарга җир бирә алмавын күреп, ул аннан мәсхәрәле рәвештә көлә: («Государственная Думага»):

Ач-ялангач мужикларга

Кайда ирек, кайда җир,

Бирәм дидең, вәгъдә бирдең

Күрсәт җирен, кайда? Бир!

Ах дума, дума, дума

Эшләгән эшең кая!

1907 елда Тукай тормышында да, эшчәнлегендә дә әһәмиятле үзгәрешләр була. Ел башында ук Мотыгия мәдрәсәсен ташлап китә һәм бу вакыйга уңаеннан «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» шигырен яза. Бу шигырьдә ул татар яшьләренең ни өчен иске тип мәдрәсәләрне ташлап китүен аңлата.

Бу елдагы тагын бер кыенлык – Камил Мотыгый типографиясен һәм «Әлгасрел-җәдит», «Фикер» газетасын сатарга мәҗбүр була. Хәзер Тукай эшсез кала һәм үзенең трибунасын да югалта.

1907 елда ул «Китмибез» шигырен яза. Бу әсәр шагыйрьнең кыюлыгы, батырлыгының бер үрнәге булып тора. Явыз чынбарлык белән көрәшүче шагыйрь образы шулай ук «Байроннан», «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Дөньяда тормыйммы? дип киңәшләшкән дустыма» һәм башка шигырьләрендә тасвирлана.

1907 елда ул Казанга күчә һәм үзенең хисләрен «Пар ат» шигырендә тасвирлап бирә. Тукайның Казанга күчүе реакцион көчләрнең – байлар, динчеләр, милләтчеләрнең көч җыйган көннәренә туры килә. Демократик матбугатлы алдынгы язучыларны эзәрлекләү башлана. Г.Тукай бу авырлыкларның барысын да үз җилкәсендә татып нинди авыр көрәшкә алынганлыгын ачык аңлый. Мәсәлән, «Сорыкортларга» шигырендә болай дип яза:

«Яза күрмә җитәр артык
Тукаев восторк бар бит,
Куярлар асып дарга»

Ләкин шунда ук «көрәш юлында чебен кебек җаным кызганыч түгел» – дип яза.

Уральскийда Тукай зур шагыйрь һәм көчле сатирик булып җитешә. Әмма төп халык массасы аны шагыйрь буларак белми әле. Тукайның халык арасында тиз таралып өлгергән әкиятләре, балаларга багышланган шигырьләре, «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы Казанга килгәч языла. Беренче шигырьләр җыентыгы да Казанда дөнья күрә. Казанда Тукайның сатирик эшчәнлеге өчен дә киң мәйдан ачыла. 1908 елның августында Г.Камал белән берлектә

алар «Яшен» исемле рәсемле сатирик журнал чыгара башлыйлар. 1909 елда «Яшен» чыгудан туктый. 1910 елның «Ялт-Йолт» журналы чыга башлый. Бу журнал тышында Тукай: «Ялт-йолт уты Яшеннән чыга», – ди.

Тукайның атаклы сатирик әсәре «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» Казанга килүенең икенче елында языла. Бу поэмада Тукай кадимче сәүдәгәрләрнең, руханиларның мораль түбәнлеген фаш итә. Иске тип сәүдәгәрләрнең бер вәкиле булган Кисекбашны Караәхмәт исемле батыр да күтәрә алмый, чөнки аның эчендә пычраклыклар тулып ята: мең пот (1 пот – 16 кг) фанатизм, йөзләгән кирелек амбары, мең пот сыраның пары, ун вагон наданлык, мең вагон «мин беләмлек».

Г.Тукай татар әдәбиятында беренчеләрдән булып халык әдәбиятын фәнни-теоретик нигездә өйрәнүне башлап җибәрә. Аның «Су анасы», «Шүрәле», «Япон хикәясе», «Кәҗә белән сарык», «Милли моңнар» кебек әсәрләре фольклордан алынган сюжет һәм мотивларга нигезләнеп язылган. Әмма халыкның җанлы сөйләм теленнән алынган афоризмнарны, мәкаль-әйтемнәрне еш куллана. Халык авыз иҗатын үрнәк итеп алып Тукай үзенең шигъри әсәрләрен генә түгел, иң әһәмиятле политик мәкаләләрен дә, сатирик прозасында саф татар телендә язды.

Тукайның беренче зур остазы – халык үзе булса, икенчесе рус әдәбиятының күренекле вәкилләре Пушкинә, («Пушкинга») шигырендә Пушкинны тагында бел дип яза һәм үзе турында Пушкинның шигърият бакчасына кереп җимешләреннән авыз иттем ди, һәм бу әсәрдән күренгәнчә Тукайның иң зур теләге Пушкин шигыръләренә тиң булган татарча шигырьләр язу. Пушкин, Лермонтов, Байрон исемнәре бөтенләй икенче темага язылган әсәрләрендә дә искә алына. Мәсәлән «Мәхәббәт» шигырендә.

Тукай иҗаты асылда төрки татар шигъриятенең меңъеллык үсешенә йомгак булды. Бу, Тукай иҗатының шигърияте өчен мөһим

булган барлык сыйфатларда да күзгә ташлана. Мәсәлән шигырь калыбын гына алыйк.

Тукай башлыча ике юллы строфалар белән эш итә. Шул үрнәктә язылган әсәрләрдән газәл, кагыйдә үрнәкләре бар. Мәсәлән «Көзге җилләр» газәл калыбында эшләнгән. Тукай шигъриятендә рифмалашу ысуллары төрле булган әсәрләр бар. Хәтта үтәдән-үтә бер рифмага корылган шигырьләрне дә очратырга мөмкин. Мәсәлән, «Мәхәббәт» шигыре:

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы,
Кайдан алсын шигырен шагыйрь
булмаса, илһамчысы.
Бу гүзәлдән кайсы шагыйрь әйтегез «рухланмаган»
Байроның, Лермонтовың, Пушкиныңмы – кайсысы
Файдасыз  ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк,
Парә-парә кисмәсә гыйшыйк мәхәббәт кайчысы.

Филология фәннәре докторы профессор Нурмөхәммәт Хисамов фикеренчә, Тукайның шигъри фикерләве тулысынча диярлек шәрыкъ традицияләренә нигезләнгән, шәрыкъ сурәтләре белән сугарылган. Иң беренче чиратта бу ислам рухындагы сурәтләргә карый: алла, фәрештәләр, пәгамбәрләр, тарихи изге шәхесләр һәм шәһәрләр, иблис, шайтан һәм башкалар. Мәсәлән, яңа туган баланың сафлыгын сурәтләгәндә ул болай ди:

Пакъ җаның вә пакъ тәнең – барлык вөҗүдең пакъ синең
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең…

Г.Тукай үзенең шигырьләрендә төрки татар шигъриятендә меңнәрчә ел дәвамында яктыртылган сюжетларга легендар образларга да мөрәҗәгать итә (« Ләйлә һәм Мәҗнүн» образы берничә шигырендә очрый).

XX гасыр башында атаклы – Тукай шигъри мәктәбе барлыкка килә. Аның иң күренекле вәкиле Шәехзадә Бабич. Шулай ук Нәкый Исәнбәтнең башлангыч чор иҗатында язылган шигырьләре дә Тукай мәктәбе йогынтысында язылалар. Г.Тукайның эшчәнлеге, аның

традицияләре күп кенә төрки язучыларга халыкчан сәнгать үрнәге булдылар.

«Ул кыска гына гомере эчендә, – дип яза Казан язучысы Сабит Муканов, – Россиянең барлык төрки халыклары арасында еракларга яңгыраган дан казанды. Башка милләттәге шагыйрьләр яшәү һәм иҗат шартлары икенче булганга үз милләтләренең тар рамкаларында калдылар

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

Г.Тукай шигъриятендә үтәли сузылган мотивларны билгеләгез?

Шагыйрь әсәрендә еш кулланылган композицион алымны күрсәтегез.

Әдипнең реакция еллары шигъриятендә романтик башлангыч көчәеп китүнең сәбәпләрен ачыклагыз?

Г.Тукайның аерым әсәрләрендә күзәтелгән сызлану, чарасызлык сәбәпләрен күрсәтегез?

Шагыйрь сатирасында киң файдаланылган алымнарны санагыз.

«Өмет» шигырендә автор кулланган тел-сүрәтләү чараларын, алымнарны, хисләр көчешен ачыклагыз?

Г.Тукай иҗатында эшләнгән милли идеалның фәлсәфи, эпик, эстетик, әдәби, иҗтимагый тамырларын ачыклагыз.

**Гамәли биремнәр**

Г. Тукай – Яңарыш чоры шагыйре. Тормыш баскычлары.

Тәнкыйтьче, публицист, журналист, җәмәгать эшлеклесе, методист, балалар язучысы һ.б.

Язучының иҗат методлары. Шагыйрь рухи мирасында Шәрык, Урта гасыр татар, Гареп әдәбиятлары традицияләре.

Г.Тукай иҗатында тематик киңлек һәм мотивлар төрлелеге.

Г.Тукайның гражданлык лирикасы.

Язучы лирикасында күңел, пейзаж, фәлсәфи лирика.

Шагыйрь иҗатында сатира һәм аларның башка төрләре.

Дини мотивлар.

**Әдәбият**

Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – ББ. 83-127.

Халит Г. Габдулла Тукай. Татар әдәбияты тарихы 6 томда. Т. 3. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – ББ. 104-150.

Галимуллин Ф. Халыкның үз шагыйре. / Эзләнү вакыты. – Казан: Мәгариф, 2005. – ББ. 28-46.

Галиуллин Т. Шигърият баскычлары. – Казан: Мәгариф, 2002. – ББ. 20-46.

Гыйләҗев Т. Әдәби мирас: тарих һәм заман – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – ББ. 13-119.

Гыйләҗев Т. Татар әдәбияты. XX гасыр башы: лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2007. – ББ. 68-71.

Лаисов Н.Х. Лирика Тукая. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1976. – 166 с.

## ТЕМА 6. СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВ – ТАҢ ВАКЫТЫ ҖЫРЧЫСЫ (1880-1926)

XX йөз башында гөрләп үсеп киткән татар әдәбиятында иң талантлы шагыйрьләрнең берсе Сәгыйть Рәмиев иде. Шактый кыска гомерендә бу иҗат әһеле шигърияттә, драматургиядә, прозада һәм публицистикада, ягъни иҗатның төрле өлкәләрендә эшчәнлек күрсәтергә өлгерде. Аның безгә калдырган әсәрләре артык күп түгел. Ләкин әдәбият-сәнгатьтә күләм иҗатның зурлыгын күрсәтмәскә мөмкин. С.Рәмиев «Таң вакыты» шигыре белән генә дә шагыйрьләребез рәтендә лаеклы урыннарның берсен алыр иде.

С.Рәмиев – үз заманының актив җәмәгать эшлеклесе, халыкның иҗтимагый аңын үстерүгә зур өлеш керткән, мәдәниятебезне чәчәк аттыру өчен ихлас янып-көеп яшәгән шәхес. Ул – әдәбиятыбызда

үзенә лаеклы бәяне әле исән чагында ук алган бәхетле иҗат кешесе. Соңыннан да аның тормыш юлы, иҗаты белән күп кенә әдипләр кызыксыналар. Бу юнәлештә Шамил Садретдинов эшчәнлеге аеруча игътибарга лаек. Сәгыйть Рәмиев язган әсәрләренең күбесе аның тарафыннан тупланып «Таң вакыты» исеме астында басылып чыга.

Сәгыйть Рәмиевнең бала чагы Оренбург төбәге Урал яклары белән бәйле. Ул 1880 елның 12 февралендә Оренбург өлкәсендәге Акман (Ибрай) авылында дөньяга килсә дә, аларның гаиләсе бер урында гына тормый, вакыт-вакыт күченеп йөрергә мәҗбүр була. Әтисе Лотфулла агач сату-алу, сал агызу эшләре белән шөгыльләнә. Шактый укымышлы кеше була.

Оренбург – татар, казакъ, башкорт кебек кардәш халыкларның бергәләп оешып яши торган төбәге. Бу якларда туып үскән Сәгыйть тә әлеге төрки милләтләрнең телен, җырларын, халык рухын кечкенәдән үк күңеленә сеңдереп үсә. Ул бай күңелле, нечкә хисле, төрле яклап талантлы шәхес булып җитешкән икән, димәк, тугандаш халыкларның рухи байлыклары белән кечкенәдән үк әнә шулай азыклануы моңа ярдәм иткән дигән сүз. Болар өстенә ул, Иләк шәһәрендә башлангыч мәктәпне тәмамлап, 1890-1902 елларда, ягъни унике ел буена Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган вакытта төрек, гарәп, фарсы телләрен, әдәбият үрнәкләрен нигезле өйрәнгән. Аннары өч сыйныфлы рус мәктәбен да тәмамлау булачак иҗат кешесен кирәкле белем күнекмәләре һәм гыйлем белән баеткан. Аның үзе укыган «Хөсәения» мәдрәсәсендә үк мөгаллим итеп калдырылуы күп нәрсә турында сөйли.

С.Рәмиев 1906 ел башында Казанга килә. Ул моңа кадәр үк, 1905 елгы революция көннәрендә эсерларга якынлаша, шул даирәдәге Гаяз Исхакый йогынтысында була. Казанга килгәч, С. Рәмиевнең: эсерлар тарафыннан чыгарылган демократик юнәлештәге «Таң йолдызы» гәҗитендә әдәби хезмәткәр булып эшли башлавы, а 19 июньнән аның мөхәррире итеп билгеләнүе очраклы түгел. Бу гәҗит озын гомерле булмый, бары 65 саны дөнья күрә, патша хакимияте тарафыннан

ябыла. С. Рәмиев үзе исә сәяси эшчәнлеге өчен бер ай төрмәдә дә утырып чыга. Ул «Тавыш» исемле гәҗит тә оештырып карый. «Таң йолдызы»ның дәвамы рәвешендә «Таң мәҗмугасы»исемле журнал чыгару эшенә дә керешә. Ләкин реакция чоры башлангач, Россиядә демократик ирекләр кысыла һәм татар телендә алдынгы фикерне таратучы вакытлы матбугатка да яшәү мөмкинлеге чикләнгәннән чикләнә. Мондый кысулар «Баянел-хак» газитенә, «Дин вә мәгыйшәт» кебек журналга гына кагылмый. Чөнки алар хөкүмәт сәясәтенә каршы килмилар. С.Рәмиев, бөтенләй эшсез калгач, «Баянел-хак» (дөреслекне әйтеп бирү мәгънәсендә) газите редакциясенә эшкә керә. Г.Тукай үзенең якын дусты С.Рәмиевне моның өчен нык кына тәнкыйтьли, чөнки әлеге басманың юнәлеше ул мөхәррирлек иткән «Таң йолдызы» гәҗите мәсләгеннән җирдән күк кадәр аерыла.

Ләкин тормыш бик катлаулы. Яшәү өчен журналистлык һөнәреннән башка килере булмаган кешенең «Казан мөхбире», «Баянел-хак» кебек гәҗитләрдә булса да эшкә урнашуы гаҗәп тә түгел. Ихтимал, үзе эшли башлагач, гәҗитнең юнәлешен аз гына булса да үзгәртеп булмасмы дигән теләге дә булгандыр. Әмма С.Рәмиев, өметләре акланмагач, 1910 елда Әстерханга китеп, андагы «Идел» гәҗитендә сәркәтип булып эшли башлый. Дөресендә С. Рәмиев әлеге басманың мөхәррире хезмәтләрен үти.

Шунысына игътибар итәргә кирәк, кайсы гына газиттә эшләмәсен, С.Рәмиев аның телен, төрек йогынтысыннан арындырып, халыкка якынайту гамәленә керешә. Бу аның иҗатында да чагыла. «Идел» газитендә күп кенә әйберләр бастыра: әдәби тәнкыйть мәкаләләре, шигырь техникасына караган хезмәтләре игътибарны җәлеп итә. «Татармы без, түгелме?» исемле мәкаләсендә үзенең барлык төрки милләтләрне берләштерү фикерен (пантюркизмны) якламавын белдерә. Чөнки төрки милләтләрнең уртак яклары күп булса да аларның бер-береннән үзгә булган нәрсәләре дә байтак. Шул сәбәпле, гомумтөркиләр өчен уртак мәсьәләләрне бергәләп хәл итә

алсалар да, аларның аерым-аерым, үз көйләренә яшәүләре, үз көннәрен үзләре күрүләре әйбәтрәк. Ә менә гарәп язуыннан яңа алфавитка күчү, аның исәбенчә, татарлар өчен файдалырак булыр иде.

Шушы газетта эшләгәндә ул Х.Ямашев, Г.Тукайлар вафатына багышлап та мәкаләләр бастыра.

С.Рәмиев, бер урыннан икенчесенә күчеп йөри, даими бер эш һәм тору урыны булмау сәбәпле, утыз дүрт яшенә җиткәч кенә өйләнә. Тик гаиләле булуына өч ай дигәндә, «Идел» газитен дә ябалар һәм С.Рәмиевне Әстерханнан сөрәлар. Ул аннан хатынының туган җире булган Уфага китә. Монда ул Уфа губерна-земствосы тарафыннан рус телендә басыла торган «Авыл көнкүреше журналы»на эшкә урнаша, дөресрәге, аны татарчага тәрҗемәче итеп урнаша.

Октябрь инкыйлабыннан соң бераз Уфада яши. Гражданнар сугышы башлангач, Урал өязенең Ваһапов исемле поселогына китәргә мәҗбүр була. Анда ревком секретаре итеп билгеләнә. Магнитка дигән станцада мәгариф эшләренә җитәкчелек итә. Верхний Урал шәһәрендә (1920) партия шәһәр комитетының меселманнар секциясендә хезмәт итә, Чиләбедә чыга торган «Кызыл Урал» газитендә дә эшләп ала (1921-1922), андагы педагогия техникумында татар әдәбиятын укыта. Уфага кайткач (1922 елның ахыры), җир эшләре халык комиссариатында нәшрият эшләре җитәкчесе була. Ләкин аның сәламәтлеге начарланганнан-начарлана бара. Ул 1926 елның 17 мартында үпкә авыруыннан вафат була.

С.Рәмиевнең Уфа зиратындагы кабер ташына менә мондый шигъри юллар язылган:

Булмас артык бер олуг эш,
Илгә хезмәт итүдән;
Илгә хезмәт хөрмәтенә
Үскән җирдән китүдән.

Шагыйрь бу строфаны 1906 елньщ 19 июнендә үзе «Таң йолдызы» газитенең мөхәррире итеп билгеләнгәч чыгарылган санында бастырган. Шулай итеп, ул әлеге газитнең мөхәррире буларак кына түгел, гомумән шәхес һәм шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе буларак та үз алдына куйган максатын әйтеп бирә, ул да булса – иң «олуг эш – илгә хезмәт итү». Гәрчә Г.Тукай аңа язган бер хатында аны «коеп куйган поэт» (шагыйрь) кына дип атаган булса да (аның бусы да бик олы мәртәбә), С.Рәмиев бер ук вакытта сәясәтче дә, җәмәгать эшлеклесе дә иде. Аның да күзе күпне күрде, колагы күпне ишетте, гомере буе туган халкы гаме белән яшәде һәм бөтен эшчәнлеген, тормышын шуңа багышлады.

**С. Рәмиевнең шигъри иҗаты**

С.Рәмиев кулына иҗат каләмен, шәхес буларак өлгереп, иҗтимагый-сәяси карашлары билгеле бер юнәлешкә кергәч ала. Билгеле булганча, ул 1902-1906 еллар арасында мәдрәсәдә мөгаллимлек итә. Ләкин С.Рәмиев мәдрәсә мөгәллимнәренең әзерлек дәрәҗәләреннән канәгать булмый. Казанга килгәч, беренче башлап иҗат иткән әсәре «Хәзрәтләр сакалы» («Хәзрәтләр эше») шигырен язудан максаты әнә шул шәкертләр алдында белемле булып кыланып та, дөресендә алардан да артта калган мөгаллимнәрнең эчке дөньяларын ачып бирүдән гыйбарәт. Аларның шәкерткә ник мыегың озын, кесәң ни өчен туры түгел, нигә урыс гәҗите укыйсың сыман сүзләр белән бәйләнеп торуларыннан көлә. Ләкин шәкерт укыган гәҗиттәге мәгълуматлар белән танышырга үзенең белеме җитми. Сакал йөртү генә әле кешегә акыл өстәми. Хәзрәт үзе дә: «Сакал ул – бер йон гына бит, язмага ярыймыни?» – дип әйтеп куярга мәҗбүр була. Дөрес, бу шигырь сәнгатьчә эшләнеш ягыннан йомшак. Бу очракта ул шагыйрь матбугатта чыккан беренче шигыре диn телгә алына. Шунысын билгеләп үтү мөһим: С.Рәмиев иҗат эшенә нигездә Казанга килгәч керешә һәм биредә яшәү вакытында иң талантлы әсәрләрен яза.

Шагыйрьнең иҗатында хатын-кызны олылау актив чагыла. Аның мондый шигырьләрен ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренчеләрендә ул хатын-кызның матурлыгын, назлылыгын җырлый, ир-егетләргә яшәү көче бирә торган зат итеп тасвирлый. Андыйларга «Син», «Ул», «Җәмилә» шигырьләрен кертеп була. Шагыйрьнең гүзәл затлар – хатын-кызларны тасвирлап язган юллары нәфислеге, рәсемлелеге һәм шагыйранә илһамлылыгы белән игътибарны җәлеп итә. Биредә шагыйрьнең каләменә Көнчыгыш сүз-сәнгатенең тәэсире дә сизелә. Билгеле булганча, фарсы, гарәп, төрек әдәбиятларында хатын-кызның гүзәллеген  җырлауның бик ерак вакытлардан килә торган традициясе бар. «Ул» шигырендә бу аеруча ачык күренә:

Кашлары – ай аның, яңа туган,
Йөзе – айның тулган көннәре.
Керпекләре – нурлар, кич чәчелгән,
Ике күзе – шул кичнең күлләре.

Шигырьдән күренгәнчә, гашыйк кешенең хисләре генә түгел, бәлки теле дә, сөйләгән сүзләре дә гүзәл була.

С.Рәмиев сүз сәнгатенең төрле тармакларында эшли. Шунысы үзенчәлекле – аның прозасы, драматургиясе, шигърияте һәм публицистикасы үзләренең идея-тематикалары белән дә, образлары һәм кайвакыт эчтәлеге белән дә үзара керешеп китәләр. Мәсәлән, хатын-кызны, мәхәббәтне олылау, ирекле һәм бәхетле тормышка чакыру, аның күп кенә әсәрләренә хас. Аерым шигырьләрен ул пьесаларына, повестьларына кертеп җибәрә. Мәсәлән, «Хатыннар галәме» шигыре тәүге (1 нче) мәртәбә «Яшә Зөбәйдә, яшим мин» исемле драмасында басыла. «Мәҗит сүзе» ул «исерек түгел иде» әсәренә мөнәсәбәттә туа.

Шулай ук, С.Рәмиев әсәрләрендә биографик моментлар да бар. Мәсәлән, «Яшә Зөбәйдә, яшим мин» драмасын китерергә була. Әсәрнең баш герое Сөләйман халыкка хезмәт итү өчен туган якларын ташлап Казанга килә һәм Сөләйманның монда кичергәннәре С.Рәмиевнең «Таң йолдызы» газитендә эшләгән чорын хәтерләтә.

Пьесаның басылып чыгуы дин әһелләре арасында зур шау-шу уята, басылып чыккан китапларны утта яндыралар.

Әлбәттә, барыннан да элек С.Рәмиев – шагыйрь. Аның шигырьләренең иң югары ноктасы – «Таң вакыты» шигыре. Ул аны беренче мәртәбә 1908 нче елның гыйнваренда әдәбият кичәсендә сөйли. Шигырь зур бәхәсләр тууга сәбәпче була, тиз арада русчага тәрҗемә ителеп тарала. Таң ату күренеше ярдәмендә автор татар дөньясында бара торган каршылыклы көрәш турында сөйли. Шигырьнең азаккы юллары актив хәрәкәткә чакыру булып яңгырый:

Бетмә надан, ту яңадан,
Мәгърифәтле анадан.
Бул кеше, үзең тырыш, өмет итмә
Хата ул өмет алладан.

Лирик геройның ялкынлы хисләре шартлы шигырь кысаларына гына сыймый, ирекле яңгыраш ала. Чыннан да, бу әсәрдә, без күнеккән шигъри үлчәм төгәллеге, рифмалашу тиешенчә сакланмаган. Автор үзе «Таң вакыты» әсәрен мөссәҗәгъ (нәсер) дип атый, ягъни рифмалы, ритмлы, лирик проза. С.Рәмиев шигырьләрендәге мондый үзенчәлекләрне алга таба Һади Такташ, Хәсән Туфан, Гадел Кутуй, Рәдиф Гаташ кебек шагыйрьләр дәвам итә һәм үстерә.

С.Рәмиевнең көчле рухлы, романтик шигърияте өчен арттыру, соң чиккә җиткереп тасвирлау хас. Шагыйрьнең мин образы да шундыйлардан. Ул горур басып гади кеше өчен бәхет даулый:

Дөньяда бар су минем
Бар кар, җир минеке.
Бар тау, урман, бар матур кыш –
Барысы да минеке.

1907 елдан соң патша хөкүмәтенең кеше хокукын изүе көчәя һәм мондый шартларда җәмгыятьтә күңел төшенкелеге, өметсезлек киң таралыш таба. Хис-тойгы кешесе булган С.Рәмиевта бу кыенлыкларны бик авыр кичерә. Бу чорда язылган шигырьләренең

исемнәре дә С.Рәмиевнең авыр рухи халәттә булуын сөйли – «Алданган», «Мин үләм», «Минем төн» һ.б. Автор болай дип яза:

Караңгы хәтта янган шәмем дә,
Караңгыдан рухым каралды.
Барда карыйлар миңа
Ямьсез тутыккан күз белән.

Моннан күренгәнчә, кешеләр арасындагы кыргый мөнәсәбәтләргә каршы хис-тойгы дөньясы, эмоциональ дөнья куела.

Алга таба С.Рәмиев та музыка сәнгатен пропогандалап мәкаләләр яза башлый. Шигъриятә исә көчле рухлы геройларны эзләп рус һәм Көнбатыш Европаның романтик поэзиясенә мөрәҗәгать итә. С.Рәмиев Лермонтов шигырьләрен, Шиллерның «Перчатка» балладасын тәрҗемә итә, Толстой иҗаты белән кызыксына, аңа багышлап мәкаләләр яза, Некрасов иҗаты, Демьян Бедный иҗаты да Сәгыйть Рәмиевка тәэсир ясый.

1917 елгы революция алдыннан ул бу газаплы тормыштан талчыккан була (жандармерия аны һәрдаим эзәрлекли, яный, куркыта, С.Рәмиевтан яшерен шпион ясарга тырыша), ләкин әлеге революция аның рухын күтәрә һәм ул шигырьләрендә яңадан инкыйлаб темасына мөрәҗәгать итә.

Сәгыйть Рәмиев прозасы, Г.Ибраһимов әсәрләрендә дәвам иттерелә, шигърияттә исә аның дәвамчылары булып Сәгыйть Сүнчәләй, Шаехзада Бабич, Һади Такташ, Нәкый Исәнбәт һәм башкалар исәпләнәләр. Сәгыйть Рәмиев иҗатын югары бәяләгән Мәҗит Гафури аның хакында болай дип яза: «Әдәбиятыбыз күгендә күп йолдызлар бар. Шуларның берсе Сәгыйть Рәмиевныкы. Бу йолдызга карап сине онытмаска. Сәгыйть күп йолдызлар арасында синең йолдызың һәрвакыт ялтырап торыр».

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

С.Рәмиев иҗаты заман, аның әдәби-мәдәни хәле һәм иҗтимагый-тарихи вакыйгалары белән ни дәрәҗәдә бәйләнгән?

Әдип кайсы иҗат юнәлешенә карый?

Шагыйрь иҗатындагы төп мотивларны атагыз.

С.Рәмиев һәм Г.Исхакыйны нәрсә берләштерә?

**Гамәли биремнәр**

Сәгыйть Рәмиев иҗаты. Гомер юлы, тормыш сукмакларындагы әһәмиятле тарихи вакыйгалар, мәдәни фактлар. Әдипнең рухи мирасында жанр үзенчәлекләре.

С.Рәмиев – гыйсъянчылык романтизмы шагыйре, аның шигъриятендәге лирик герой, романтик, матурлыкка гашыйк, бунтарь, ярсу йөрәкле, гыйсъянчы.

Шагыйрь әсәрләрендә милләтнен үткәне, бүгенге хәле, киләчәге һәм аны үзгәртү турында уйланулар («Уку», «Таң вакыты», «Кеше» һ.б.).

Шагыйрь мөрәҗәгать иткән алымнар, аның сүз-сурәт, образ тудыру осталыгы, милли шигъгрияткә алып килгән яңалыгы.

**Әдәбият**

Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – ББ. 52-54.

Садретдтнов Ш. Сәгыйьт Рәмиев иҗаты. – Казан: КДУ нәшр., 1980. – 260 б.

Ганиева Р.К. Сәгыйть Рәмиев – гыйсъянчылык романтизмы шагыйрьләре // Татар әдәбияты: традицияләр, бәгланышлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – ББ. 172-188.

Заһидуллина Д.Ф. С.Рәмиев иҗаты: тематика һәм образ-сурәтләр үзгәреше// Сәгыйть Рәмиев, Шаехзадә Бабич. Әсәрләр. – Казан: Мәгариф, 2005. – ББ. 7-22

**Дәрдемәнд (Закир Рәмиев)**
**(1859-1921)**

Дәрдемәнд – талантлы шагыйрь, тыйнак һәм укымышлы зыялы, милләт кадиме. Иҗатының әдәби-эстетик юнәлеш белән генә түгел,

үзенең иҗтимагый хәле буенча да татар әдипләре арасында үзенчәлекле урын тота. Дәрдемәнд – шагыйрьнең тәхәллүсе, псевдонимы: «моңлы зат», «хәсрәт чигүче», «кайгылы кеше» мәгънәсен белдерә.

Булачак шагыйрь 1859 елның 23 ноябрендә Оренбург губернасы Эстәрлетамак өязе Җиргән авылында сәүдәгәр Мөхәммәтсадыйк гаиләсендә дөньяга килә. Атасының гаиләсе белән 1862 елда Орск өязендәге Юлык авылына күчеп утыралар, анда алтын приискалары ачып җибәреп, соңыннан зур промышленниклар булып китәләр. Гаиләдә башлангыч белемне алганнан соң, олы агасы Шакир Рәмиев белән бергәләп, Орск өязе Муллакай авылы мәдрәсәсендә укый. Гарәп, фарсы телләрен өйрәнә, укымышлы әнисе Хәнифә йогынтысында рус теле һәм әдәбияты белән таныша башлый. 1880 елда Төркиянең Истанбул шәһәрендә урнашып, хосусый рәвештә төрек телен һәм әдәбиятын өйрәнә, ирекле рәвештә аерым укытучыларның лекцияләрен тыңлый, шушы елларда француз, алман теле белән кызыксына башлый. Төркиядә аңа культура йортлары, типография эшләре белән танышу бурычы да йөкләнгән була. Үз типографиясен ача, рәсми төстә татар телендә газета-журналлар чыгару ният-теләкләренең беренче рус инкыйлабы елларында тормышка аша. Татар халкының мәдәнияте, әдәбияты, тәнкыйте үсешендә аеруча зур роль уйнаган «Вакыт» (1906-1918), «Шура» (1908-1918) газета-журналларын нәшер итә. Аларның сәхифәләрендә татар әдипләренең, галимнәренең хезмәтләрен бастыруга игътибар бирелә, үзләре яшәгән авыл-шәһәрләрдә мәктәп-мәдрәсәләр, китапханәләр салдыра. Дәрдемәнд Дәүләт Думасына депутат итеп сайлана. Октябрь борылышларыннан соң чит илгә китмичә, үз Ватанында кала, алтын приискаларын, китапханәләрен, мал-мөлкәтен совет хакимиятенә тапшырып, Оренбургтан Орск каласына күчеп утыра, мәдәният, мәгариф эшләрендә катнаша. Шагыйрь 1921 елның 9 октябрендә 62 яшендә вафат була.

Дәрдемәнд татар поэзиясе күгендә классик романтик шагыйрь буларак танылa, фәлсәфи лирикага нигез сала, символларны файдалануның иң югары, уңышлы үрнәген күрсәтә. Истанбулдан Россиягә кайткач, язу эшләре белән шөгыльләнә башлый, 1902-1903 елларда «Тәрҗеман» газетасында кечерәк күләмле шигырьләре басыла, шушы елларда хикәя жанрында беренче тәҗрибәләр ясый. Иҗади күтәрелеше 1905-1907 елларга, ягъни инкыйлаб чорына туры килә.

Татар телендә чыга башлаган газета битләрендә басылган беренче шигырьләрендә үк Дәрдемәнд лирикасының төп хасиятләре, шигъри таланты, дөньяга карашлары, эстетик омтылышлары сиземләнә. «Каләмгә хитаб» (1906) исемле шигырендә тарихи барыш, якты дөньяга килеп киткәннәрнең хәлен бәян итү, җәберләнгәннәрнең аһ-зарын, моңлы, хәсрәтле гамьнәрен сөйләү һ.б. чагылыш таба, «Яз чәчәге» (1906), «Тал чыбык» (1906) әсәрләрендә исә әдипнең кинаяле сөйләмгә, фикри тирәнлеккә, символик сурәтлелеккә осталыгы күзәтелә. Рухи, иҗтимагый, мәдәни яңару юлына баскан милләт тормышында татар шәкертләренең хәл-әхвәле, хәятына бәйле лирик геройның үкенү хисләре яз чәчәге – умырзая, тал чыбык символик образлары аша гәүдәләнә. Кеше һәм вакыт, урын (пространство), дөньяның бакыйлыгы-мәңгелеге, гомернең фанилыгы (чикләнгәнлеге), гомер агышы, тәкъдир, яшәү һәм үлем турында фәлсәфи уйланулар әдип иҗатында кызыл җеп булып сузыла. Шушы гомумкешелек мәсьәләләргә бәйле лирик геройның сагышын, борчылуын, үкенү хисләрен гәүдәләндергән «Без» (1908), «Бүзләрем мана алмадым» (1908), «Куанды ил» һ.б. шигырьләре билгеле. Алар милләт, ил, халык язмышы турындагы гамьнәр белән кушылып китәләр.

Җәмгыять, аны хәрәкәт иттерүче көчләр, бу хәрәкәттә ил, Ватан, халык, милләт язмышы, аңа автор мөнәсәбәтенең Дәрдемәндне татар матбугатында олуг шагыйрь итеп таныткан фәлсәфи-символик эчтәлекле «Кораб» (1908) шигырендә гәүдәләнә. Әсәрдә кораб,

диңгез, җил, давыл кебек символик һәм мифологик образлар гәүдәләнә. Шәрык, Урта гасыр суфыйчылык әдәбиятыннан килгән традицияләрнең, символик образлар «Хәят» (1908), «Хикәяи гыйшык» (1908), «Җәй үтте» һ.б. әсәрләрдә иҗади үстерелә. Дөньяга килү, үлем, борчылу, кайгыру, өметсезлек, билгесезлек, язмышның котылгысызлыгы кебек билгеләрнең шагыйрь иҗатын экзистенциализм агымы белән китереп бәйли. Шул ук вакытта лирик геройның күңел дөньясы, хис-кичерешләре, авторның халәте импрессионистик әдәбиятка хас алымнар: аһәң, музыкальлек, ритмик төгәллек, образлар гармониясе, табигать тавышлары, пейзаж күренешләре, моң, тынлык белән тирәнәйтелә («Сагыш», «Ятам кайчакларда моңлап», «Исәрме җил тугай буйлап», «Гөрләсә су», «Гөрләгән сулар» һ.б.). Шагыйрь мирасында туган илгә, Ватанга тирән мәхәббәт белән сугарылган, лирик геройның сагыну, ачыну, өзгәләнү хисләрен традицион-романтик образларда чагылдыра: «Видагь», «Әгәр барсаң, саба җил», «Туган-үскән җир» шигырьләре. Мондый рухтагы әсәрләренә җылылык, табигыйлек, самимилек, гадилек хас. Барлык хис-кичерешләрдән дә шагыйрь үз милләтенә, туган кавеменә мәхәббәтен, милли-рухи бердәмлек, кардәшлек хисләреннән өстен куя («Гөрләгән сулар» һ.б.). Дәрдемәнд шигырьләрендә милли горурлык, телнең сафлыгын, чисталыгын кайгыртучы лирик герой алга планга куела. Аларның бүген дә заманча яңгырашы билгеле: «Тел – илнең колагы», «Татар углы – татармын», «Тел уйнатучыларга» һ.б. Алардагы шигырь юллары афоризмга, канатлы сүзләргә әверелә. Романтик эстетиканың атрибутлары булган мәхәббәт, хатын-кыз, табигать культы Дәрдемәнд иҗатында гәүдәләнә («Рәсем», «Әгәр барсаң, саба җил», «Тиң булырмы», «Аның янында» һ.б).

Дәрдемәнднең тыйнак мирасында пейзаж лирикасы зур урын тота. Табигать күренешләре, пейзаж матурлыгы, хозурлыгыннан шатланган, юаныч тапкан лирик герой «Яз», «Көлемсерәп көн башланды» һ. б. шигырьләрендә сурәтләнә.

Дәрдемәнд робагый, фәрд, газәл, мәдхия, мәсәл кебек жанрларда эш итә. Аның шигъриятендә Й.Баласагунлы, Харәзми, С.Сарай, Мөхәммәдьяр, Акмулла иҗатларыннан килгән традицияләр дәвам иттерелә. Шулай ук Шәрык классикасы, рус шигъриятеннән аерым әсәрләрне тәрҗемә итүе белан аерылып тора.

Шагыйрь поэзиясендәге мәгънәви тирәнлек, шигъри нәфислек, сүзләрне файдалануда үзгә осталык, кыскалык, сурәтләү чараларының муллыгы, Дәрдемәнд иҗатының, идея-эстетик үзенчәлекләре турында Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Сәгъди, Ф.Кәрими, М. Гайнуллин, Г.Халит, И.Нуруллин, С.Хәким, Й.Нигъмәтуллина, Н.Хисамов, Х.Миңнегулов, Ф.Галимуллин, А.Сәяпова, Ф.Яхин һ.б. бик хозурланып язалар

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

Дәрдемәнднең (Закир Рәмиев) үзенчәлекле социаль хәле турында сөйләгез?

Бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләрнең татар халкының рухи-мәдәни, әдәби, милли тормышында тоткан урыннары нидән гыйбарәт?

Шагыйрь иҗаты үрнәгендә фәлсәфи романтизм сыйфатларын барлагыз?

Дәрдемәнд әдәби-эстетик, фәлсәфи-әхлакый карашларының байлыгын дәлилләгез, шартлы, романтик сурәтлелекнең тамырларын, чыганакларын билгеләгез.

Дәрдемәнд әсәрләрендә сагыш хисенең үзгәрү сәбәпләрен күрсәтегез.

«Татар халкын мәгърифәтле һәм мәдәниятле итүгә багышланган гомер» дигән темага парча языгыз.

Дәрдемәнднең «Кораб» шигырендә символик сурәтлелек.

Шагыйрь лирикасында фәлсәфи мотивлар.

Аның шигъриятендә мотивлар төрлелеге.

«Җәй үтте» шигырендә күпмәгънәлелек, сүз-сурәтләрдә образлылык.

Дәрдемәнд шигърияттендә Ватан, ил, милләт мотивлары («Әгәр барсаң, саба җил», «Гөрләгән сулар», «Видагъ» һ.б.).

Аның рухи мирасында символизм агымының сыйфатлары нинди?

Шагыйрь әсәрләрендә лирик герой кичерешләрен тирәнәйтүче импрессионистик алымнар, билгеләр.

«Без», «Бүзләрем мана алмадым» шигырьләрендә хис-кичереш сәбәпләре, автор файдаланган образлар.

Дәрдемәнд рухи мирасында риторик эндәш алымы («Видагъ», «Куанды ил», «Тал чыбык», һ.б.).

«Татар шагыйрьләре» китабында Г.Ибраһимов тарафыннан Дәрдемәнд поэзиясенең аерып чыгарылган сыйфатлары нинди?

«Хәят» шигырендә лирик герой, суфичылык әдәбияты образларының янача яңгырашы.

Дәрдемәнд лирикасында үтәли чыккан сагыш мотивы.

**Гамәли биремнәр**

Дәрдемәнднең (Закир Рәмиев) тормыш юлы. Шагыйрь, милләт кадиме, матбагачы, алтынчы, иганәче һәм җәмәгать эшлеклесе. Иҗатының өйрәнелү тарихы.

Дәрдемәнд – фәлсәфи романтизм вәкиле. Шагыйрь әсәрләренең әдәби-эстетик, этик, фәлсәфи тамырлары; әдәби бәйләнешлар мәсьәләсе.

Шагыйрь әсәрләрендә символизм сыйфатлары: күптавышлылык, кинаяле сөйләм, сәнгатьчә фикерләүдәге фәлсәфи-романтик шартлылык («Яз чәчәге», «Кораб», «Җәй үтте» һ. б.).

Дәрдемәнд шигърияттендә лирик герой, әдипнең барлык әсәрләрен бер үзәккә туплаган лейтмотив, төп сыйфат. Аларда яшәү һәм үлем, гомер агышы, тәкъдир, язмыш, тарих барышы, киләчәктәге

билгесезлек турында уйланулар, гамь, сагыш («Каләмгә хитаб», «Без», «Куанды ил», «Видагъ» һ. б. шигырьләре).

Мәхәббәт, табигать күренешләрен тасвирлаган шигырьләрендә лирик герой («Рәсем», «Аның янында», «Яз», «Көлемсерәп көн башланды» һ. б.).

Дәрдеменд лирикасында Ватан, милләт, туган кавем, кардәшлек, туган тел турында уйланулар, бәя-хөкемнәр («Әгәр барсаң, саба җил», «Гөрләгән сулар», «Татар углы – татармын», «Тел уйнатучыларга» һ. б.).

Шагыйрь әсәрләрендә бизәк-нәкышләр, метафоралар, символлар һ. б. Дәрдеменд романтизмының импрессионизм, экзистенциализм алым-билгеләре белән баетылуы.

**Әдәбият**

Дәрдеменд. Агарган кыл. Шигырьләр //Төз. кереш сүз авт. Ренат Харис.– Казан: Мәгариф, 1999.– 112 б. (рус һәм татар тел-дә)

Дәрдеменд (Закир Рәмиев). Сайланма әсәрләр,– Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.– 125 б.; Исә җилләр: Шигырьләр,– Казан: Татар. кит. нәшр., 1980.– 253 б.

Дәрдеменд шигырьләре //Бертуган Рәмиевләр: Фәнни-биографик җыентык,– Казан: Рухият, 2002.– ББ.164-223.

Ил корабын җил сөрә: XX йөз башы татар поэзиясе,– Казан: Мәгариф, 2001. – ББ.145-154.

Татар поэзиясе антологиясе. 1 китап.– Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.– ББ. 445-451.

Гайнетдин М.В. XX йөз башы татар поэзиясе // Гасырлар мирасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.– ББ.142-197.

Гайнуллин М.Х. Дәрдеменд //Дәрдеменд. Сайланма әсәрләр,– Казан: Татар. кит. нәшр., 1959.– 3–18 б.

Галимуллин Ф. Г. Халыкның үз шагыйре // Эзләнү вакыты.– Казан: Мәгариф, 2005.– ББ. 125-161.

Галимумин Ф.Г. Дәрдемәнд // Әдәбият (XX йөз башы һәм 20 нче еллар): Унберъеллык урта мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек,– Казан: Мәгариф, 1994.– ББ.153-168б.

Саяпова А.М. Поэзия Дардменда и символизм. – Казань: Казанский пед. ун-т, 1997.– 210 с.

Халит Г.М. Шагыйрь иҗатында дөнья һәм тарих концепциясе // Казан утлары.– 1979.– № 12.– ББ.146-156.

Хәким С. Шагыйрьнең осталыгы //Дәрдемәнд (Закир Рәмиев). Исә җилләр: Шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 3.

## ТЕМА 7. ШАЕХЗАДА БАБИЧ (1895-1919)

Ш. Бабич 1895 елның 15 январьда (2 январь) Башкортстанның Дүртөйле (элекеге Уфа губернасы Бөре өязе) Әсән авылында дөньяга килә. Атасы Мөхәмәтзакир мулла була. Бабичлар исеме электән билгеле нәсел була. Тамырлары белән Мохтар бабай исемле кешегә барып тоташалар. Бу кеше Башкортстаннан Казанга күченгән була.

Мохтар бабасының 5 баласы булуы билгеле: Илекәй, Ишбулды, Ишкилде, Ишалды, Гайнулла.

Ишбулдының дүртенче малае Гыйльван Мөхәмәтзакирнең әтисе була. Ләкин Мөхәммәтзакир яшьтән ятим калып бабасы тәрбиясендә үсә. Аның бабасын авылда хөрмәтләп Аксакал, Акбабай дип йөртәләр. Үз гомерендә Мөхәммәтзакир 3 тапкыр өйләнә, беренче, икенче хатыны авырып вафат булалар. Аның барлыгы 17 баласы була. Ләкин шуларның 11 генә исән-сау үсә. Шаехзада Бабич 3 нче хатыны Бибисаҗидәдән туган улы. Бибисаҗидә абыстай бик тыйнак, артык сабыр, уку-язуга исе китмәгән хатын була. Әмма ул башкалардан тегү-чигүгә осталыгы белән, җыр, моң яратуы белән, нечкә күңеле белән аерылып торган.

Ире Мөхәммәтзакир исә гадел, туры сүзле, ярлыларны кыерсыткан кеше белән судка барып җитәргә дә курыкмаган кеше була. Бу чорда чыккан гәҗит-журналларның барысын да диярлек,

җыеннар вакытында дөнья хәлен аңлатучы буларак та танылa. Шундый чыгышларның берсе өчен хәтта төрмәдә дә утырып чыга.

Шаехзадә Бабич әнә шундый кешеләр гаиләсендә иркенлектә һәм иркәлектә үсә. Әтисенең җәдит мәдрәсәсендә белем ала. 1908 нче елның җәендә Казах далаларында балалар укыта, 1911 елда Уфаның атаклы Галия мәдрәсәсенә керә һәм укуның беренче елында ук үзенең шигырьләр җыентыгын әзерли. Әмма нииндидер сәбәпләр аркасында китап басылмый кала. Халык иҗаты да Шәехзадә Бабичта зур кызыксыну уята. Мәкальләр, халык көйләре турында үзе дә фәнни мәкаләләр яза.

Мәсәлән, Башкорт көе «Таштугай» турында болай дип яза:

«Борынгы казакъ яулары илләрне баскан чакларда Башкортлар туган җирләренә күчкәннәр. Шул вакытта таштугай дигән су буена килгән башкорт кызы бу көйне чыгарган…».

1913 елда Ш.Бабич «Шура» журналында шагыйрь буларак чыгыш ясый. Аның башлангыч чор иҗатында кояш, йолдыз, ай образлары өстенлек итә. Ләкин шигырьләрендәге ай һәм кояшлар күк җисемнәре генә түгел, ә мәгърифәт, матурлык, шигъри иҗат символлары да була.

Ш.Бабичның лирик герое тынгысыз, ярсулы, бер урында утыра алмый, югарыга таба үрмәли:

Айга мендем, ай нуры белән коендым, уйнадым
Күп сөендем, сөенеч белән туендым, туймадым.
Туймадым, айдан узып мендем кояшка ашкынып
Юк шулай да булмады ташкын күңелне бастырып

(«Айга мендем», 1914).

Әмма бу ярсулы теләк-омтылышларында Ш.Бабич халкыннан аерылып калмый. Ул «тормыш тигезсезлекләрен уйлап яна», чөнки күзләре алдыннан егълап, ярлы мескеннәр уза.

1914 елда язылган «Бай һәм ярлы» шигырендә болай ди:

Эч яна, тормыш тигезсезләрен уйлап яна,
Моңлы, мескен бәндәләрнең моңнарын сөйләп яна.

Шулай итеп лирик герой айга һәм кояшка менгәндә дә халкы турында онытмый, әмма аның үз кояшын югалткан вакытлары да күп була.

Февраль революциясе башланган көннәрдә Ш.Бабич иҗаты зур үсеш кичерә. 1916 елда ул – аллага, дингә, кануннарга каршы чыккан газраил дингә поэмалар, баллада яза. Шул ук елда «Кандала» поэмасын иҗат итә, һәм эпиграммалар циклын яза. Шул рәвешчә сатирик буларак та танылa. Әмма аның сатирасы Тукайныкыннан аерылып тора. Г.Тукайның сатирасы ачы тәнкыйть итүгә, фаш итүгә нигезләнсә, Бабичның сатирик әсәрләрендә юмор өстенлек итә. Нәкъ менә юмор лирик геройның көр рухын саклап кала алды. Г.Ибраһимов Бабичның сатирасы турында «күз яшьләре аша көлә», – дип әйтә.

Ш.Бабич татар һәм башкорт сәхнәсен үстерүгә дә зур өлеш кертте. Галия мәдрәсәсендә укыганда ук мәдәниятне үстерергә сәләтле булган барлык татар, башкорт һәм өлешчә казах әдипләре, телчеләре, музыкантлары белән аралаша. Мәҗит Гафури белән якыннан дуслаша, Сәгыйть Рәмиев белән танышу аңа поэтик осталыгын үстерергә ярдәм итә.

## Журналистика өлкәсендәге эшчәнлеге

Журналистика өлкәсендә Ш.Бабич революция тәэсирендә тартыла. Әхмәд Таҗетдин Рахманкулов дигән журналист белән «Хөр милләт» исемле газета чыгарып йөри. Газетаның беренче санында ук «Яшәсен эшчеләр» исемле шигырен бастыра. Ләкин 1917 елның июль айларында Уфага кайта һәм Г.Ибраһимов чыгара торган «Ирек» газетасына эшкә керә. Уфада да озак тормый Оренбургтагы «Кармак» газетасына эшкә китеп бара. Ул газеталарда гына эшләми, концертлар уздыра, әдәби түгәрәкләр оештыра. Оренбургта аның күптәнге хыялы тормышка аша – ул Дәрдемәнд белән таныша.

1917 елларда матур лозунгларга ышанып Ташкент милли хәрәкәтенә кушыла. Әмма 1919 елда кызыллар (большевиклар) ягына

чыга һәм бу турыда «Башкорт халкы көйле хитап (эндәшү)» шигырендә әйтә:

Нигә ярышмаска большевик белән,

Безнең сукмак киткәч сул яктан…

1919 елның 25 февралендә Ш.Бабич башкорт матбугатының хезмәткәре итеп билгеләнә. Әмма күп тә үтми шагыйрьнең гомере фаҗигале рәвештә өзелә. 1919 елның 28 мартында Ш.Бабич революция дошманнары тарафыннан җәзалап үтерә. Бу вакытта аңа бары тик 24 кенә яшь була.

XX йөз башында яшәгән шагыйрьләрдән М.Гафури, С.Сүнчәләй, Ф. Бурнаш һ.б. әсәрләрендә, инкыйлаби вакыйгаларның ил, халык, сыйнфый азатлык өчен барган көрәш рухында кабул итеп, уңай мөнәсәбәт белдереләләр, аны милләтнең, халыкның якты киләчәге белән бәйләп карыйлар, өмет, ышанычлар буларак, сәяси лирикага хас булганча, публицистик аһәң, риторика килеп керә. Ш. Бабич һ.б. шагыйрьләрнең иҗтимагый-сәяси карашлары катлаулана, татар, башкорт халыкларының милли азатлык көрәшләрен шартлы романтик образларда сурәтләгән шигырьләрен иҗат итәләр. С.Рәмиевнең, Дәрдемәнднең иҗатлары сүлпәнләнә.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

Ш.Бабич шигъриятендә романтик эстетика сыйфатларын табыгыз.

Шагыйрь лирикасы кайсы индивидуаль үзенчәлекләре белән замандашларына каршы куела?

Ш.Бабич иҗатында әдәби бәйләнешләр йогынтысының нинди алымнары, формалары күзәтелә?

Шагыйрьнең әдәби мирасында нинди жанрлар өстенлек итә?

**Гамәли биремнәр**

Ш.Бабич иҗаты. Аның катлаулы һәм фаҗигале тормыш юлы, табигать тарафыннан мул итеп бирелгән сәләт, тырышлык, киң һәм күпкырлы эшчәнлеге.

Ш.Бабич шигъриятендә лирик герой, аның үсеш-үзгәреше: мәгърифәтче-милләтче, көрәшче-гыйсъянчы.

Әдип иҗатында юмор һәм сатира, көлү һәм фаш итү объектлары, сатирик алыинар.

«Газазил» поэмасының идея эчтәлеге, күтәрелгән мәсьәләләр, автор бәя-хөкемнәре. Анда сурәтләнгән вакыйгалар катламы, образ-сурәтләргә салынган мәгънәләрне шәрехләүдә төрлелек.

**Әдәбият**

Нуруллин И. ХХ йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – ББ. 222-225.

Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т. 3. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – ББ. 247-251.

Ганиева Р.К. Романтические мотивы творчества Ш.Бабич// Татарская литература: традиции и взаимосвязи. – Казань: Татар. кни.изд–во, 2002. – С. 122-141.

Гыйләҗев Т. Татар әдәбияты. ХХ гасыр башы: лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2007. – ББ.94-96.

## Сәгыйт Сүнчәләй (1889-1937)

Талантлы шагыйрь, балалар язучысы, публицист, оста тәрҗемәче, уңышлы пьеса авторы. Шагыйрь 1889 елның 2 августында Саратов губернасы Хвалын өязе Мастак авылында дөньяга килә, татарча һәм русча белем ала. 1905-1907 елларда демократик хәрәкәтләргә якыная, «Борһане-тәрәккый» газетасында хәбәрчелек итә, кышларын Казан мәдрәсәләрендә укый. 1908 елдан Гәйнә ягындагы бер авылның земство мәктәбендә укытучылык итә башлый.

Унынчы елларда Сәгыйт Сүнчәләй белән Тукай арасында шәхси дуслык һәм иҗади мөнәсәбәтләр урнаша. Октябрь борылышларыннан соң Сүнчәләй дәүләт органнарында (Төркиядә Совет илчелегендә), әдәбият һәм мәгариф өлкәсендә эшли.

Әдип әдәби эшчәнлек белән унынчы елларда шөгыльләнә башлый, беренче шигъри тәҗрибәләре, рус һәм Аурупа классикларыннан тәрҗемә әсәрләре була. Аларда романтик герой белән җәмгыять арасындагы каршылыкның фаҗигале чишелешенә игътибар ителә. Байроннан тәрҗемә ителгән «Шильон мәхбүсе» (1910) поэмасында җәмгыятькә тәнкыйди-иронияле караш ташлаган геройның физик һәм рухи яктан имгәтелеп, гарипләндереп ташлануын гәүдәләндерелә; Пушкинның «Тазит»ыннан үзгәртеп эшләнгән «Галиб» (1911) поэмасында иске тормыш, иске тәртипләр белән арасын өзгән геройның тирәлек тарафыннан сөрелүе, кире кагылуы; Гейнедан татарчалаштырылган «Әлмансур»да (1913) изге идеалга омтылган геройның явыз, рәхимсез тормыш басымы нәтиҗәсендә үз-үзен һәлак итәргә мәҗбүр булуы тасвирлана. Традицион тоткын, «мәхбүс» образының романтик-символик гәүдәләнеше «Мин иректә» (1915), «Мәхбүс» оригиналь әсәрләрендә күзәтелә, аларда шәхес ирегеннән, азатлыгын буган иҗтимагый тәртипләргә, көчләргә гәүдәсе богауланган геройның ирониялe мөнәсәбәте дәвам иттерелә, физик тоткынлыкка күңел, рухи азатлык каршы куела.

Сүнчәләйнең романтик поэзия вәкиле буларак танылып, лирик геройның катлаулы психологиясен, эчке кичерешләрен сурәтләүгә зур урын бирелә. «Каһарманга» (1911), «Ышаныч» (1911), «Нәсер» (1913) кебек шигырьләрендә кайгы-хәсрәт, ачы күз яшьләре, төшенкелек, өметсезлек мотивлары урын ала. Аларда лирик геройның газаплы, фаҗигале күңел дөньясы тасвирлана. Алга таба мондый эчтәлектәге шигырьләре кими төшеп, лирик геройның тормыштагы вәхшилеккә, зольмәткә, караңгылыкка үз өметен, якты хыялын каршы куйган шигырьләрнең артуы, «таң ату», «кояш чыгу» мотивлары

көчәя: «Караңгы һәм газаплы төн» (1911), «Җыр» (1911), «Маяк» (1911), «Гомерем» (1912), «Күзләрендә» (1913) һ. б. Аларда җирдәге байлыкка, акчага, коллыкка үз «җыр»ын, «вөждан»ын, үз халкына мәхәббәтен каршы куйган ярсу йөрәкле лирик герой гәүдәләнә. «Җырларым – күз нурым» әсәрендә татар халкының язмышы, киләчәге турында шагыйрьнең фәлсәфи уйланулары, гамьнәре чагылыш таба. Бу еллар поэзиясенең, бер яктан, «төн», «болыт», «караңгылык», «кан», икенче яктан, «таң», «кояш», «йолдыз», «нур», «маяк», «якты юл» кебек романтик-символик образлар белән баетылуы бер дә гаҗәп түгел. С. Сүнчәләй шигърриятендә, романтик эстетиканың билгеләре буларак, мәхәббәт, хатын-кыз, табигать культының куәтләнүе («Кыз», 1911; «Авыл», 1912; «Таң көтәм», 1913; «Мәхәббәтем», 1913 һ. б.) моңа дәли булып тора. Сүнчәләй иҗатында Тукай шәхесенә һәм иҗатына, Дәрдемәнд, С. Рәмиев поэзиясенә мөнәсәбәт, алар арасында әдәби багланышлар булуы күзәтелә. Шагыйрьнең «Тукай мәктәбе» вәкиле булуы ассызыклана. Традицион шагыйрь-пәйгамбәр образының иҗади үстерелеше булып, Сүнчәләй поэзиясендә «азан әйтүче шагыйрь» образы («Азан») килеп керә. «Габдулла Тукаевка багышлыйм» дип куелган әлеге шигырьдә бу геройның төп миссиясе: милләтне гасырларга сузылган йокыдан уятып, аның күзен ачып, яктылык, милли рух тарата. Иҗаты нурларга тиңләнгән Тукай шәхесе «Иңеш» (1913) шигырендә лирик герой өчен югары үрнәк буларак тасвирлана. «Татар хатыны» (1912) шигырен турыдан-туры Тукай тәэсирендә иҗат итә. Шагыйрь әсәреннән аермалы буларак, биредә кияүгә чыгып, коллыкка, «җанлы курчак» хәленә дучар ителгән татар хатынының ачы, газаплы тормышы тәэсирендә нечкә күңелле лирик геройның газаплы, авыр кичерешләре тасвирлана. «Мәхәббәтем» (1913), «Сөенер идем» (1914) һ.б. әсәрләре Дәрдемәнд рухында, аның шигъри формасын файдаланып ижат ителә, соңгысында шагыйрьнең яшәү мәгънәсе турындагы фәлсәфи уйланулары киная, ишарә юлы белән символик образларда гәүдәләндерелә. Автор өчен Ватан, ил, туган авыл, халык

язмышы, социаль гаделсезлек мәсьәләләренең чит булмавы: «Ил җыры» (1910), «Җыр» (1911), «Сөаль» (1914), «Ярлы җыры» һ. б. ачыклана. Сүнчәләйнең беренче бөтендөнья сугышы елларында иҗат ителгән әсәрләрендә лирик геройның күңел дөньясы тагын да катлаулана. Җир йөзен баскан күз яше, ятимлек, кайгы-хәсрәтнең лирик геройны фаҗигале кичерешләргә этәрә: «Төн буе» (1914), «Ил кайгысы» (1914) һ.б. Империалистик сугыш елларында тантана иткән явызлыкка, байлар сыйныфына, патша хакимиятенә нәфрәт хисләре сурәтләнү белән бергә, аларга каршы көрәшкә үч алырга чакырган, сугыш бетеп, якты таң туачагына шагыйрьнең өмет-ышанычларын белдергән «Интикам» (1915), «Иман» (1916) шигырьләре иҗат ителә. Февраль, Октябрь инкыйлаблары аралыгында Сүнчәләй сыйнфый, социаль азатлык, иҗтимагый гаделлек, сәяси ирек мәсьәләләрен җырлауга күчә. Бу аның «Марсельеза», 1917; «Ихтилал», 1917; «Ирек», 1917; «Матәм», 1917; «Октябрь», 1917 әсәрләрендә чагылыш таба.

**Әдәбият**


Сүнчәләй С. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1961.– 112 б.;

Сүнчәләй С. Әлмәнсур//Мирас.– 1994.– №2–5;

Мусабекова Р. Сагид Сунчелей: Судьба и творчество.– Казань: Уныш.– 1995.– 157 с.


## Мәҗит Гафури
## Тормыш һәм иҗат юлы (1880-1934)

Мәҗит Гафури татар һәм башкорт әдәбиятының классик язучысы. Ул язучы гына түгел, күренекле шагыйрь һәм публицист.

Мәҗит Гафури 1880 елның җәендә Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе Жилемкаран авылында туа. 13 яшенә җиткәч әти-әнисе бер-бер артлы үлеп китәләр һәм булачак әдип тулы язмыш башлый. Ләкин кысынкылыкка карамастан, ул укырга да, эшләргә дә өлгерә.

Иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. Беренче шигыре сатирик характерда «Иман шәкертләренә» дип атала. 1902-1903 елларда М.Гафури Казахстан Кыргый далаларында укытучылык итә һәм шушы елларда «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» хикәясен һәм «Себер тимер юлы яки әхвале милләт» дигән шигырен яза. Шулай итеп, әдәбият мәйданына Мәҗит Гафури шагыйрь һәм прозаик булып килеп керә.

Беренче рус инкыйлабы йогынтысында язылган шигырьләрендә өмет, ышаныч мотивлары чагыла, аларда берләшү, дуслык идеясе үткәрелә, хөсетлек, көнчелек, тарлык, дошманлыкка каршы чыгу күзәтелә. Ул язучының «Шатлык шигыре», «Алмашыну», «Хөррият дәверендә», «Инсаф вә иттифак» кебек шигырьләрендә аеруча ачык чагыла. Язучы шигъриятендә тарихи барышка мөнәсәбәт, социаль мотивларның тирәнлеге, иҗтимагый-сыйнфый тигезсезлекне конкрет сурәтләр аша тәнкыйть итә. Аларда реалистик җанлылык, публицистик аһәң көчәюе сизелә. Мәсәлән, ул әлеге шигырьләрендә аеруча сизелә: «1906 нчы елдан 1907 нче елга васыять», «Бай кеше», «Җиденче елның җавабы», «Базарга чыктым» һ.б. Халык көченә, рухына ныклы ышаныч белән сугарылган «Халык теләге», «Үзем һәм халкым», «Мин кайда?» шигырьләре. Әлеге шигырьләре аша язучы революциянең һәркемгә сыйнфый аерымлыкларга карамыйча шатлык китерүенә ышана. Ләкин 1906 елның гыйнварендә язылган «Эч пошу» шигырендә ул революциягә башкачарак карый башлый. Шул елларда иҗат иткән әсәрләрендә уңышларны күрсәтә, ләкин кара көчләрнең әле җиңелмәвен искәртә.

1907 елдан соң иркенлек кысыла башлый. Кара реакция канатын җәя һәм автор «1907 нче елның җавабы» шигырендә үч алуны туктатмаска, җинаятьчеләрнең җеназаларын укырга чакыра. Ләкин кызганычка каршы бу хыяллар әле тормышка аша алмый.

Реакция елларында М.Гафури күбрәк мәсәлләр яза һәм аларда күп урынны ярлылар тормышын сурәтли. Бу чор иҗатында бер яктан эш юклыктан һәм ачлыктан интегүче ярлылар сурәтләнсә, икенче

яктан нәфрәт белән байлар тормышын тасвирлый. Шулай ук руханиларның һәм дин әһелләренең кешегә зарар кылулары турында ул язмыйча кала алмый. Әдипнең мәсәл жанрына мөрәҗәгать итүе дә очраклы хәл түгел. Ул аларда актуаль политик проблемаларны күтәрә. Мәсәлләрнең күпчелеге шигъри формада язылган һәм эштә аның остазы дип рус язучысы Крыловны атап булыр иде. Шагыйрь кешеләр арасындагы гаделсезлекне, мәкерлелекне, усаллылыкны, явызлыкны, икейөзлелекне фаш итә. Әлеге фикерләр «Үгез белән Бүре», «Сарыкны кем ашаган?», «Тавык белән Үрдәк», «Эт беләң куян» кебек әсәрләрендә ачык чагыла.

М.Гафуриның 1908-1913 еллар лирикасында идея-эстетик үзгәрешләр, идея-тематик киңлек, хис-кичерешләр тирәнлеге хас. ә 1914-1916 еллар шигъриятендә сугыш чынбарлыгы, ул китергән бәла-каза, кайгы хәсрәтне кичерүче лирик герой образы бирелә: «Фитрәт заманы» (ахыр заман), «Кыямәт», «Юктырсың ла Алла…», «Кем ул?» һ.б. әлеге шигырьләре заманы өчен батырлык санала алган.

Хезмәт кешесенә ярдәм итмәүдә шагыйрь АллаҺы Тәгаләнең үзен дә гаепли:

Юктырсың ла Алла, әгәр булсаң,
Сабыр итмәс идең бу эшкә.
Бөтен кодрәтеңне, баглап куймас,,
Идең җирдә алтын-көмешкә.
Күрер идең көчсез бәндәләрне,
Ярдәм итәр идең аларга,
Ирек бирмәс идең көчлеләргә,
Көчсезләрне болай таларга.

Шагыйрьнең башка шигырьләрендә дә сугыш алып килгән ачлык, газап чигүче кешеләр, ятимнәрнең һәм гарипләрнең моң-зары зур урын ала. Юкка гына М.Гафурины үз чорының «күзе һәм колагы» дип атамаганнар. Чөнки, һәр шигырен һәм һәр эшен ул хезмәт ияләрен яклап башкара һәм хезмәт кешесенең явыз заманы булган

патша хакимиятенең бәреп төшерелүен шатланып каршы ала һәм шул көннәрдәге хисләрен «Хөррият иртәсе» шигырендә тасвирлый.

1917 елгы революцияне тәбрикләп, революцион рухтагы шигырьләр яза, җиңү символы булган Кызыл байрак образына мөрәҗәгать итә. «Шатлык көннәренең берсендә», «Ирекле көннәр» шигырьләре әнә шундыйлардан. Аларга тирән лиризм һәм сәнгатьлелек ягыннан югары эшләнелеш хас.

Язучының пәйгамбәрләр тарихына мөрәҗәгать итеп язылган тәмамланмый калган «Рисаләт» поэмасы бар. Ул кешеләр арасында рәхимлелек, шәфкатьлелек, дуслык һәм мәхәббәт таратучы Мөхәммәд пәйгамбәр образын тудырган әсәр. Поэмада кешелек җәмгыятендә күп гасырлар буе хөкем сөргән хаксызлыкка, социаль гаделсезлеккә ишарә ясала.

Автор шигърият белән паралелль рәвештә прозада да уңышлы эшләп килә. Ул беренче әсәрләре белән үк милли әдәбиятка тема яңалыгы – гади халык, авыл, шәһәр ярлыларының, көнчеләрнең авыр, михнәтле тормышын сурәтләүне алып килде. Үзенең геройлары яшәгән матди тирәлекне, яшәү-көнкүреш шартларын, тормыш күренешләрен ваклап, җентекләп сурәтләргә омтылып, М.Гафури прозасында натуралистик тенденцияләрне чагылдырды.

Язучы иҗатында романтизның үзенчәлекле гәүдәләнеше чагылыш тапкан. Беренчедән, Урта гасыр татар әдәбиятыннан килә торган традицияләрнең үстерелүе һәм халык авыз иҗатының йогынтысы сизелә, икенчедән, замана җиле (беренче рус инкыйлабы) белән килүче хыял-омтылышарның романтик сурәт-образларга төрелеп бирелүе, өченчедән, тарихи темаларның романтик рухта яктыртылуы («Хан кызы Алтынчәч», «Болгар кызы Айсылу» һ.б.) күзәтелә.

Шулай итеп, үзенең халык мәнфәгатьләре белән яшәве, хезмәт иясе белән өзелмәс бәйләнеше, революцион хәрәкәтне һәрвакыт шатланып каршы алуы белән Мәҗит Гафури Тукай традицияләрен дәвам итте. Аның үзенең иҗаты да бу елларда иҗат итүчеләргә үрнәк

булып тора. Һәртөрле жанрда хезмәт кешесенә файда китерерлек һәртөрле өлкәдә эшләве аны Туган иленең чын улы итте. Дөрес болар барысы да аның биографиясе белән бәйләнгән.

Димәк, М.Гафури (1880-1934) башлангыч чор иҗатында мәгърифәткә, шәхес, акыл уянуына дан җырлый. 1905 ел инкыйлабы татар поэзиясен активлаштырып җибәрә, шигърияткә көчле ташкын булып Г.Тукай (1886-1913), Н.Думави (1883-1933), М.Укмасый (1884-1948), З.Бәшири (1888-1962) һ.б. шагыйрьләр килеп керә. Милли поэзия демократик идеяләр белән сугарылып, үзәктә хөррият, шәхес иреге, социаль, милли, ил, халык азатлыгы темаларының урын ала. Г.Тукайның «Хөррият хакында» (1905), «Дустларга бер сүз» (1905), М.Гафуриның «Шатлык шигыре» (1905), «Алмашыну» (1905) һ. б. әсәрләрендә инкыйлабка ышаныч, өмет чагыла. Мондый рухтагы әсәрләрдә мәгърифәтчелек реализмы принциплары өстенлек итә, шуңа күрә аларда белем, гыйлем, үгет-нәсыйхәт, дидактика билгеләре урын ала. Шул ук вакытта мәгърифәтчелек идеяләренең гражданлык хисләре белән үрелеп үсеше күзәтелә. Татар милләтенең мәдәни, рухи артталыгына, наданлыгына, ялкаулыгына, таркаулыгына борчылу, кайгыру, бу хәлдән чыгу юллары турында шагыйрьләрнең уйланулары, гамьнәре чагыла. Инкыйлаб чоры поэзиясенең диңгез, җил, давыл, таң, кояш кебек символик образларга мөрәҗәгать итүе күзәтелә. Өмет-хыялларның тормышка ашмавы, патша самодержавиесе ясаган ташламаларның, вәгъдәләрнең кәгазьдә генә калуы татар шагыйрьләрендә ризасызлык уята, милли һәм социаль азатлык хәрәкәтен көчәйтеп җибәрә, иҗтимагый-сәяси мохиткә тәнкыйди мөнәсәбәтләр тирәнәя. Г.Тукайда сатирик, М.Гафурида сәяси лирика калкулана (Г.Тукай. «Государственная думага», 1906, «Сорыкортларга», 1906, «Безне урынсыз яманлыйлар», 1907; М.Гафури. «1906 нче елдан 1907 нче елга васыять», 1906, «Җиденче елның җавабы», 1907; Н.Думави. «Эч поша, күңел болгана», 1906, «Җәй үтеп, кышның башы җиткән иде», 1906; С.Рәмиев. «Таң ата, эшлик, туганнар», 1906, «Татарча Марсельеза», 1906 һ.б.).

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

М.Гафури әдәби-эстетик карашларының тамырларын ачыклагыз?

Шагыйрьнең иҗатында реалистик поэзия күрсәткечләрен барлагыз?

Шагыйрь поэзиясендә шәхсиләшкән кичерешләргә караганда, гомумиләшкән кичерешләр өстенлегенең сәбәпләрен аңлатыгыз?

**Гамәли биремнәр**

М.Гафури шигърияте. Тормыш баскычлары.

Язучы иҗатында мәгърифәтчелектән тәнкыйди реализмга күчеш, реакция һәм аннан соңгы чор әсәрләрендә романтик башлангычның көчәюе.

Шагыйрь иҗатында мотивлар төрлелеге. Башлангыч чор шигъриятендәге уку, гыйлем һәм әхлак мәсьәләләреннән иҗтимагый-социаль темаларга борылу: «Себер тимер юлы», «Инсаф вә иттифак», «Шатлык шигыре», «Бай кеше», «Җиденче елның җавабы», «Үзем һәм халкым» һ.б.

М.Гафури шигъриятендә сугыш темасы.

Әдип мирасында дини мотивлар.

Шагыйрь әсәрләрендә тел-сурәтләү чаралары, образ-тасвирлар. Автор мөрәҗәгать иткән алымнар: риторик эндәш, детальләштерү, арттыру-гипербола, антитеза, кабатлау.

**Әдәбият**

Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – ББ. 229-236.

Гыйләҗев Т. Татар әдәбияты. XX гасыр башы: лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар: Югары уку йортлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2007. – ББ. 75-78.

# ТЕМА 8. XX ЙӨЗ БАШЫНДА ДРАМАТУРГИЯ

**Аннотация:**Репрессияләнгән авторларның әсәрләрен яңадан халыкка кайтару иң изге бурычка әйләнә. 1956 елда драматургия классигы К.Тинчуринның “Сайланма әсәрләре” чыга; театрларда аның “Зәңгәр шәл” белән “Казан сөлгесе” драмалары сәхнәгә куела.

**Мөһим сүзләр:** схематизм, пассивлык, сюжет һәм композициядәге ясалмалылык, психологик халәт һ.б.

**Теманы өйрәнүгә методик рекомендацияләр:** Тема лекция формасында укытыла. Практик дәресләрдә студент үзлегеннән эшли.

**Глоссарий**. Конфликт – әдәби әсәрдә характерларның, идеяләрнең, теләк-омтылышларның кискен бәрелеше.

Милли драматургия башка әдәби төрләр белән чагыштырганда, беренче адымнарын XIX гасырның соңгы чирегеннән ясый башлый.

XX йөз башы татар драматургиясе тарихын чорларга бүлеп караганда, беренче чор 1887-1905 елларны үз эченә ала. Бу елларга Г.Ильяси, Ф.Халиди, Г.Камал, Г.Исхакый һ.б. иҗатлары хас.

Алар яңа чорда яңа жанрларга нигез салалар. Беренче драма һәм комедияләрдә мәгърифәтчелек әдәбиятына хас шәхес иреге, хатын-кыз азатлыгы, мәктәп-мәдрәсә, тәрбия, әхлак мәсьәләләре темаларъі гәүдәләнә. Драматурглар үз әсәрләрен сентименталь әдәбиятка хас алымнар, сыййфатлар белән баеталар. Шул ук вакытта сурәтләү принциплары, алымнары, идея эчтәлеге белән мәгърифәтчелек әдәбияты кысаларына сыймаган пьесалар мәйданга килә, бу үзенчәлекләр – татар әдәбиятына төрек әдәбиятының йогынтысы, тәрҗемә әсәрләр барлыкка килү белән аңлатыла.

Татар драматургиясе тарихында икенче чор 1906 елдан башлана. Ул 1906-1911 еллар аралыгын үз эченә ала.  Беренче рус инкыйлабы, милли профессиональ театр барлыкка килә.

1906 елның 22 апрелендә Уфада татар яшьләре көче белән Г. Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» драмасы рәсми төстә сәхнәгә

куела, бу вакыйгадан соң ике атна узгач, Казанда «Шимбә» түгәрәге яшьләре тарафыннан Г.Камалның «Бехетсез егет», «Кызганыч бала», Г.Кәрам тәрҗемә иткән «Гыйшыйк бәласе» пьесалары сәхнәләштерелә. Татарлар яшәгән төбәкләрдә «Сәйяр», «Нур» һ.б. театр труппалары барлыкка килә һәм алар татар драматургиясен җанландырып җибәрәләр. Татар сәхнәсе ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатыннан, әдипләрнең рус, Көнбатыш Европа, төрек әдәбиятларына мөрәҗагать итә. Н.Гоголь, А.Чехов, М.Горький һ.б. рус язучыларының пьесалары тәрҗемә ителә; алардан әдәби осталыкка өйрәнү, кеше, аның яшәешен гәүдәләндерүнең яңа принциплары, алымнары үзләштерелә.

Татар драматургиясенең «театрлы» дәверендә Г.Камал (1879-1933), Г.Исхакый (1878-1954), С.Рәмиев (1880-1926), Ф.Әмирхан (1886-1926), Г.Коләхмәтов (1881-1918), И.Богданов (1886-1916), Ш.Саттаров (1887-1972), Г.Терегулов (1883-1938) һ.б. иҗатларында үз чорның актуаль һәм мөһим, алдынгы мәсьәләләре күтәрелә. Иң беренче нәүбәттә феодаль торгынлыкка, наданлыкка, кадимчелеккә, иске карашлы, фанатик дин әһелләренә, әхлаксызлыкка каршы юнелдерелген пьесалар күпләп языла. Нәтиҗәдә комедия жанры активлаша, сатирик комедия, водевиль кебек яңа формалар барлыкка килә. И.Богдановның «Помада мәсьәлесе» (1908), С.Рәмиевнең «Низамлы мәдрәсе» (1908), Г.Камалның «Беренче театр» (1908), «Бүләк өчен» (1909), «Банкрот» (1911), «Безнең шәһәрнең серләре» (1911) пьесалары икенче чор драматургиясендә күренекле комедияләр булып, җәмгыятьтәге тискәре күренешләрне, җитешсезлекләрне, иске тип сәүдә буржуазиясен, рухи ярлылыкны фаш итәләр. Җәмгыять белән шәхес арасындагы кискен каршылыкны тасвирлаган, социаль, сыйнфый көрәш мәсьәләләрен яктырткан, искелек һәм яңалык тартышларын күрсәткән инкыйлаби эчтәлекле драмалар иҗат ителә. Пролетар әдәбият вәкиле булган Г.Коләхмәтовның «Ике фикер» (1906), «Яшь гомер» (1908) пьесаларында әлеге проблемалар пролетар, марксистик идеология

белән үрелеп тасвирлана, әлеге драмаларында кеше бәхете, иҗтимагый, социаль гаделлек өчен көрәшүче актив шәхес концепциясенең фәлсәфи, эстетик нигезләре эшләнә, идея-тематик, форма яңалыгы күзәтелә. Г.Исхакыйның «Алдым-бирдем» (1907), аеруча «Тартышу» (108) тарихи-инкыйлаби драмасында яңа тормыш, революцион көрәш өчен үзен корбан иткән татар яшьләре үзәккә куела. Г.Исхакыйның «Мөгаллмм» (1908), С.Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» (1908), Ф.Әмирханның «Яшьләр» (1909), Ш.Саттаровның «Татар тәгассеб вә җәһаләтенең корбаны» (1911), «Татар милләтен тәрәккый иттермәүчеләр» (1911) һ.б. драмаларда татар тормышын яңарту өчен кәрәш сурәтләнә, халыкка, милләткә хезмәт итү теләге белән яшәгән зыялы яшьләр төрле типлары тудырыла. Мондый рухтагы әсәрләрдә геройларның рухи дөньясына, психологик кичерешләренә игьтибар арта. Милли драматургиянең тематик киңлекләргә чыгуын, сәхнә әсәрләре язу осталыгын, сәнгати яктан үсешен дәлиллеген Г.Исхакыйның «Зөләйха» (1907-1912, сәхнәгә куела 1917) әсәре иҗат ителә. Пьесса татар халкы үткән тарихи юлның иң авыр, фаҗигале вакыйгаларын тасвирлый. Бу чор драматургиясе чынбарлыкны гәүдәләндерүнең реалистик төрен, ягьни тәнкыйди реализм принципларын, алымнарын үзләштерү, шул ук вакытта мәгьрифәтчелек реализмы принципларын да кире какмый, романтизм методының билгеләре, сыйфатлары аерым әсәрләрдә чагыла.

Татар драматургиясенең өченче чорында (1912-1917) иҗат иткән Ф.Әмирхан, Г.Исхакыйның дөньяга карашларында, әдәби-эстетик эзләнүләрендә яңарышлар, үзгәрешләр барлыкка килә. М.Фәйзи (189-1928), Ш.Камал (1884-1942), Ф.Сәйфи-Казанлы (1888-1937), К.Тинчурин (1887-1938), Ф.Бурнаш (1898-1942) һ.б. яңа көчләр килә. Тематик яктан, образ-характерлар тудыру алымнарына, конфликт төзелешенә нигезләнеп, чор драматургиясендә берниче юнәлеш ассызыклана. Искелекне, бозыклыкны, татар тормышындагы җитешсезлеклерне фаш итүгә юнәлтелгән, хатын-кыз азатлыгын,

шәхес иреге, мәгърифәт кебек мәсьәләләрне яклаган М.Фәйзинең «Яшьләр алдатмыйлар» (1912), Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», (1915), Ф. Сәйфи-Казанлының «Безнең заман» (1912), Ф.Бурнашның «Язмыш» (1914), «Сукбай» (1916) һ.б. пьесалары языла. Инкыйлаби, сыйнфый көрәш, социаль каршылыклар икенче планга чыгарылып, татар халкының барлык социаль катлаулары берләшеп, милләтнең матди хәлен ныгыту, мәдәниятен, мәгарифен үстерү өчен барган көрәшне гәүдәләндергән драмалар иҗат ителә (Ф.Әмирхан. «Тигезсезләр», 1913). Шушы рухта язылган Г. Исхакыйның «Мөгаллим»е (1913) романтик драмасында шәхси бәхетеннән, мәхәббәтеннән баш тартып, үзен милләткә, халыкка багышлаган мөгаллим тормышы сурәтләнә. Романтик иҗат ысулы өстенлек иткән М.Фәйзинең драмаларында, аерым алганда «Кызганыч» (1913) мелодрамасында, мәхәббәт хисләре белән милләткә хезмәт итү идеалы арасында калган укытучы хатын-кызның рухи кичерешләре, газаплары тасвирлана, шартлы-романтик мәгънәгә ия булган идеаль образ тудырыла. Татар тормышын яктыртуга омтылган демократик яшьләр хәрәкәтендәге эчке каршылыклар, идеяләр бәрелешен сурәтләгән, яшәүнең фәлсәфи һәм әхлакый нигезләрен төрлечә аңлаган яшьләр тибын тасвирлаган пьесалар языла: (К.Тинчурин. «Беренче чәчәкләр», Ф.Сәйфи-Казанлы. «Ямьсез тормыш», һ.б.) Әлеге әсәрләрдә мәхәббәт культы традицияләре романтик рухта үстерелә. Бурыч белән хис каршылыгы арасында калган романтик геройның фаҗигале кичерешләре психологик киеренкелек белән сурәтләнә. М.Фәйзинең «Тәкъдирнең шаяруы» (1913), К.Тинчуринның «Соңгы сәлам» (1917) әсәрләрендә Гыйсмәт, Гөлшат, Вахитларның үлеме үзләре яшәгән тирәлеккә, тәртипләргә, әхлакый кануннарга протест, ләгънәт булып яңгырый. Өченче чорның тагын бер үзенчәлекле сыйфаты – гади халык тормышына, аның гореф-гадәтләренә, йолаларына, халык җырларына йөз белән борылуы, ягъни халыкчанлык принцибының эчтәлеге байый Аерым бер әсәрләрдә ясалмалылыкка китерсә дә, социаль мәсьәләләргә,

иҗтимагый гаделсезлекләргә урын бирелә (М.Фәйзи. «Авыл бәйрәме» (1915); «Галиябану» (1916); Ф.Бурнаш. «Яшь йөрәкләр», (1917) һ.б.).

Бу елларда драматургия татар халкының тарихына мөрәҗәгать итә. Ф.Туйкин «Ватан каһарманнары» (1912), Гали Хәйдәрнең «Сөембикә» исемле драмалар иҗат итә. Өченче чорда драма жанрының хәлиткеч роль уйнавы, аның сатирик, психологик, тарихи, романтик, музыкаль драма кебек формалары туа; водевиль, трагикомедия белән жанр ягыннан төрләнә. Унынчы ел драматургиясе кеше, аның яшәешен гәүдәләндерү принциплары, алымнары ягыннан катлаулана: романтизм куәтлеге, романтизм белән реализмның табигый берлеге, романтизм белән сентиментализм синтезы күзәтелә, реалистик эчтәлек импрессионизм билгеләре белән баетыла һ.б. Конфликт оештыру, образ-характерлар тудыру, сәнгатьчә эшләнеш ягыннан драматургия җитлегә.

XX йөз башы татар драматургиясенең катлаулы үсеш юлы үтә. Унынчы елларга кадәр формалашу дәвере кичереп, алганнан соң үзенең үсеш тарихында яңа баскычка күтәрелә.

## Галиәсгар Камал
## (1879-1933)

Г.Камал – реалистик татар драматургиясенә нигез салучы, хикәяче һәм шигырьләр авторы, тәнкыйтьче, публицист, журналист, тәрҗемәче, рәссам, театр эшлеклесе.

Г.Камал «Госмания», «Халидия» һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә, алар янындагы русчага өйрәнү сыйныфларында укый. Әдәбият, театр сәнгате белән кызыксына, аеруча драматургиягә мәхәббәте арта. Дини-әхлакый һәм дөньяви әсәрләр белән таныша, К.Насыйри, Г.Ильяси, Ф.Халиди иҗатлары белән кызыксына.

Китап бастыра һәм аны сату эшен оештыра. Г. Камалның милли әдәбиятта иң яшь булган драма жанрына алына, беренче пьесаларында үзенә кадәрге мәгърифәтчелек әдәбиятының

традицияләрен дәвам иттерә. Драматург әдәби иҗатындагы беренче тәҗрибәләре булган «Бәхетсез егет» (1 нче вариант, 1898), «Өч бәдбәхет» (1900) пьесалары һәм «Сабир хәзрәт, яки Гыйбрәт» (1900, басыла: 1903) хикәясендә үз чоры өчен иҗтимагый әһәмияте булган, милләт язмышы белән бәйле мәгърифәт һәм әхлак мәсьәләләрен үзәккә куя. Алар «Бәхетсез егет»тә яңа фикерле Әхмәт, ә икенче пьесада укымышлы, гыйлемнең тормыштагы файдасы турында уйланган һәм бу яктан Мәхмүткә каршы куеп сурәтләнгән Гомәр мисалларында раслана. Бала тәрбиясе, шәхес иреге һ.б. проблемаларның Урта гасыр татар әдәбияты традицияләре, ислам мәдәнияте, дини кануннар белән бәйләнеше күзәтелә. Беренче пьесалардагы образларда схематизм, пассивлык, сюжет һәм композициядәге ясалмалылык, хәрәкәткә караганда сөйләп аңлатуы өстенлек итә. Шул ук вакытта аларда шактый ачык драматик конфликт, хәрәкәт, геройларның психологик хәлен сурәтләүгә омтылыш, халыкка аңлаешлы саф татар теле билгеләнә. «Сабир хәзрәт, яки Гыйбрәт» әсәрендә бозык, азгын, аталык хисләреннән мәхрүм Сабир хәзрәтнең тормышы укучыларга гыйбрәт итеп сөйләнә. Аңа керсез күңелле, яхшыны яманнан аера белүче, сабыр холыклы, гыйлемле, хуш табигатьле Габдулла мулла каршы куела. Хикәянең финалында Урта гасыр әдәбиятындагы гыйбрәтле хикәя алымнары күзәтелә.

Төрек әдибе Н.Кемал тарафыннан иҗат ителгән «Зәваллы чужык» драмасының Г. Камалга бик зур йогынты ясый. Ул аны «Кызганыч бала» (1898) исеме белән тәрҗемә итә. Пьеса идея-эстетик үзенчәлекләре белән мәгърифәтчелек әдәбияты кысаларына сыеп бетми, ул XIX гасыр ахырында төрек әдәбиятының романтик рухлы француз сүз сәнгате йогынтысында булуы белән аңлатыла. «Кызганыч бала» романтик эчтәлекле сентименталь драма әсәре буларак билгеле. Бу сыйфатлар Гата белән Шәфыйка арасындагы хис-тойгы, эш-гамәлләрне, мәхәббәт язмышын тасвирлаганда ассызыклана. Пьесада рухи мәхәббәт гәүдәләнә. Җан, рух белән

яраткан Шәфыйканың фаҗигасе: атасының бурычларын түләү хакына Хәлил патшага кияүгә чыгарга ризалык бирә, ачы газаптан авыруга сабыша, мәхәббәт тарихы романтикларча хәл ителә.

Беренче рус инкыйлабы Г.Камал эшчәнлеген активлаштырып җибәрә, ул ныклап журналистлык эшчәнлеге белән шөгыльләнә башлый. 1906 елда демократик рухлы «Азат», ул ябылгач, «Азат халык» газеталарын нәшер итүдә бик зур көч куя. Тукай белән берлектә «Яшен», «Ялт-Йолт» сатирик журналларда эшли. «Йолдыз»да хатлар бүлегенең сәркәтибе вазифаларын башкара. Ниһаять, Г.Камал театр сәнгатен оештыра, һәм ул эшне җайга салуда бик күп эш башкара – артист, режиссер, сәхнә бизәүче, драматург. Бу еллар иҗгимагый-сәяси вакыйгалар, татар мәдәнияте, рухи Хәятындагы үзгәрешләр Г.Камал шәхесенә, каләменә зур йогынты ясый, ул рус, Көнбатыш Аурупа драматурглары иҗатын җентекләп өйрәнә. Шушы шартларда Г.Камал ныклап иҗат эшенә кереп китә, үзенең башлангыч чор әсәрләренә тәнкыйть күзе белән карап, икенче вариантын яза. Мондый рухтагы пьесаларның берсе – «Бәхетсез егет» (1907) драмасы. Әсәрдә төп герой Закир белән бәйле фаҗигале вакыйгалар сурәтләнә. Пьесада яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсе куела һәм, беренче варианттан аермалы буларак, Закирның фаҗигасендә ата-анасы, аларның баланы тәрбия итә белмәве гаепле дигән фикер үткәрелә. Кәрим, Җәмилә образлары, аларның бала тәрбиясе мәсьәләсенә карашлары, яңаруга йөз тоткан татар тормышына мөнәсәбәт ассызыклана. Пьесада бу гаиләгә каршы куеп сурәтләнгән Сәгыйт Сабитовлар тормышы, яшәү рәвеше, көнитеше, Гайшә һәм Әхмәтләрдә авторның уңай идеаллары гәүдәләнә. Гайни, жуликлар образында җәмгыять тудырган тискәре күренешләр чагыла. Закирның каршылыклы хис-кичерешләрен, күңел дөньясын ачуда әдип психологизм төрләренә мөрәҗәгать итә. Отышлы итеп монолог, сюжет-композицион яктан төзеклеге кулланыла. Драма тәнкыйди реализм билгеләре белән баетылып мәгърифәтчелек реализмы әсәре буларак кабул ителә.

«Уйнаш» (1910) драмасы – шулай ук «Өч бәдбәхет» пьесасының эшкәртелгән варианты. Анда хатын-кыз темасы сурәтләнә. Шәхес азатлыгы, гаилә бәхете, мәхәббәт, рухи һәм матди байлык мәсьәләләр куела. Әсәр кешенең ирекkә, бәхеткә омтылыш хисе белән бөтен нәрсәне акча, мал белән хәл итүчеләрнең кыргый, кешелексез сыйфатлары каршылыгына корылган. Бер якта – мәхәббәткә, гаилә бәхетенә омтылган Сәрбиҗамал, ә икенче якта аны үзләре корган тозакка төшерү өчен акчаны эшкә җиккән бозык Әнвәр, ялганчы, явыз Мәгълифә карчык, кешелексез, мәкерле Фәтхерахман. Сәрбиҗамал фаҗигасе пьесада кара, караңгылык кебек символик төсләр, хыялый шәүләләр, табигатьнең гадәттән тыш күренешләре – яшен, күк күкрәү, җил сызгыру белән тирәнәйтелә.

Г.Камал гаилә тормышы материалында әхлак мәсьәләләрен күтәргән «Каениш» драмасын 1912 елда иҗат итә.. Усал каенана Бәдигыльҗәмалнең җинел акылы, көнчелеге аркасында гаиләдә туган ыгы-зыгы, күңелсез хәлләр тасвирлана: кызы Гөлҗамал язмышында да аның холыксызлыгы тискәре роль уйный, улы Ибраһим гаиләсен таркалу куркынычы алдына куя. Габделкәрим, Гөлҗамал образларында чиста күңеллелек, аек акыл, сабыр холык хуплана.

Г.Камалның приказчиклар яшәешеннән алынган «Дәҗҗал» (1912) пьесасы. Анда яхшы күңелле, эчкерсез, намуслы Әхмәт, хөсетлек, тар күңеллелек, үчлек корбанына әверелеп, эчкечелеккә бирелә, гаиләсеннән, эш урыныннан мәхрүм калу вакыйгасы тасвирлана. Кешеләрдәге көнчелек, икейөзлелек, ихтыярсызлык, бүтәннәр исәбенә яхшы тормыш корырга ниятләү, хәмергә бирелү кебек күренешләр, тискәре сыйфатлар, омтылышлар кире кагыла.

Г.Камал комедия жанрында аеруча уңышлы эшли, комедия остасы буларак таныла. Аның сәбәпләре: драмаларында комедиячел ситуацияләрне сурәтләүдә тәҗрибә туплау; илдәге үзгәрешләрнең, тарихи вакыйгаларның аңа тәэсире, әдәби-эстетик карашларының үсеше; кискен рухи, иҗтимагый яңару юлына баскан милли хәятга

комедия жанры өчен отышлы булган тормыш материалының тулып ятуы һ.б.

Татар дөньясындагы демократик үзгәрешләрнең берсе – беренче тапкыр театр уйналу вакыйгасын һәм аңа бәйле рәвештә иске, феодаль-патриархаль тәртипләр хөкем сөргән сәүдәгәр Хәмзә бай гаиләсендәге хәлләрне, күренешләрне гәүдәләндергән «Беренче театр» (1908) комедиясе барлыкка килә. Әсәрнең төп һәм ярдәмче конфликтларын пьесада түбәндәге образлар тудыра: Вәли, Факиһә һәм Хәбибрахман, Гафифә, Биби. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар реаль җирлек, аларда чагылган тормыш дөреслеге. Пьесаның сәнгатьчә эшләнеше итеп: комик хәл, ситуацияләр, сүз уйнату, арттыру, санап китү һәм башка сатирик алымнарны атарга була.

Г.Камалның тагын бер әсәре – байлык, мал-мөлкәт, кием-салым колы булу, мещанлыкка каршы юнәлдергән сатирик юнәлешле «Бүләк өчен» (1909) комедиясе. Пьесада күтәрелгән мәсьәләләр итеп – милли чынбарлыктагы яңалык хәрәкәтен тоя башлаган улы шәкерт Габдуллаҗанны өйләндерү уңае белән баеп калырга ниятләгән Хәмидәнең икейөзлелеге, ата-ана, балалык хисләреннән мәхрүм булуы, намуссызлыгы, искергән гореф-гадәтләрне үз максатларына буйсындырырга омтылуы фаш ителә. Бу вакыйгага гаилә башлыгы сәүдәгәр Әхмәтҗанның мөнәсәбәте, аның борчылу сәбәбе: туй чыгымнарыннан артык зур була. Комедиядә ике як арасындагы каршылыкның чишелеше күрсәтелә. Хәмидә үзенең комсызлыгы аркасында комедиячел хәлдә кала.

Иске тип сәүдә буржуазиясенә, аның яшәү рәвешенә, түбән әхлагына, мещанлык тормышына каршы юнәлдерелгән тагын бер әсәре – «Банкрот» (1911) комедиясе. Пьесада сәүдәгәр Сиражетдин Туктагаевның, ялган банкротлыкка чыгып, хәйлә юлы белән зур табыш алу вакыйгасы һәм аның реаль җирлеге сурәтләнә. Әлеге пьесада уңай зат ролен феодаль-мещан әхлагыннан, яшәү мәгънәсен акча, байлыкка, капиталга кайтарып калдырган иске тип сәүдәгәрләрдән ачы итеп көлү күренеше күзәтелә. Анда намус-

сызлык, комагайлык, икейөзлелек, алдакчылык, түбән җанлылык кебек сыйфатлар фаш ителә. Әсәрнең идея-эчтәлеген тирәнәйтүче ярдәмче персонаж доктор образы, ул Сираҗетдинның икенче сыңары була. Комедиянең күбрәк хатын-кызлар катнашкан күренешләрендә төрле катлау, төркемнәрнең эчке дөньясы, уй-фикерләре, теләк-ниятләре, яшәү рәвеше гәүдәләнә. Алар арасындагы хөсетлек, икейөзлелек, мәгънәсезлек, гайбәт, нахак сөйләү тәнкыйтьләнә. Шул ук вакытта гаилә туганлык, дуслык, ир-хатын мөнәсәбәтләренең дә ялганга корылуы фаш ителә. Әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләр заманча яңгыраш ала.

Әдипнең иске, милли чынбарлыктагы ямьсез, тискәре күренешләрдән, артталыктан, кадимчелектән, бозыклыктан ачы көлгән тагын бер әсәре – «Безнең шәһәрнең серләре» (1911) комедиясе. Пьесаның үзенчәлекле сюжеты һәм композициясе бар. Ул – бер бөтен сюжетка корылмыйча, аерым күренешләрдән тора, Казанга өйләнергә килгән Себер бае һәм аңа ияреп йөри торган яучыны комедиядә сурәтләнгән күренешләр үзара бәйләп торулар. «Җәмгыяте хәйриядә», «Ресторанда», «Клубта», «Базар чатында», «Әдәбият кичәсендә җәнҗал» күренешләрендә әдип үзе яшәгән җәмгыятьтәге җитешсезлекләрне, кимчелекләрне сатира һәм көлү алымнары ярдәмендә калкулатып, зурайтып сурәтли һәм фаш итә.

Г.Камал драматургиясен жанр ягыннан төрләндереп, баетып җибәргән «Өйләнәм!.. Ник өйләндем?» (1915, басыла: 1918) траги-комедиясе. Ул, үзендә комизм элементларын да, трагизм элементларын да берләштергән сәхнә әсәре буларак билгеле. Автор бу пьесасында драматургиянең тормыш-чынбарлыгын сурәтли, жанр мөмкинлекләрен киңәйтүгә омтыла. Трагикомедиянең беренче өлешендә, аеруча икенче күренештә катнашучының бер генә булуы, пьеса-монолог яралгылары күзәтелә; характерны үстерә, фикерне тирәнәйтә. Ул Г.Тукайның «Өйләнү – түгел сөйләнү» шигыренә мөрәҗәгать итә. Әсәрдә градация, антитеза алымнарын отышлы кулланыла. Пьесада образлар системасыннан үзәк герой Әхмәт

өйләнгәннән соң туган хәл, гаилә тормышы, анын яшәү рәвеше, авыр көнитеше автор тарафыннан күз яше аралаш көлү алымы ярдәмендә сурәтләнә. Әсәр исеменең ирониялe яңгырашы, пьесаның идея эчтәлеге белән бәйләнә.

Г.Камал драма һәм комедияләренең бай сәхнә тарихы бар. Ул әдәби тәнкыйтьне формалаштыруда үзеннән лаеклы өлеш кертә, Камалның бу төр иҗатында реалистик тәнкыйть сыйфатлары ассызыклана. Драматургның әдәби эшчәнлеге турында Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Кариевның тәнкыйди язмалары. М.Гайнуллин, И.Нуруллин, А.Әхмәдуллин, Н.Ханзафаров, Г.Арсланов, Ә.Закирҗанов, Р.Харрасова, Т. Гыйләҗев һ.б. ның Г.Камал иҗатын фәнни-гыйльми тикшеренүгә керткән өлешләре, аларның хезмәтләрендә Г.Камалның татар әдәбияты тарихында үз урыны бар икәнлеген ассызыклый.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

Г.Камалны драматург итеп формалаштырган әдәби-мәдәни, милли-иҗтимагый җирлекне атагыз?

Әдип иҗатында үзенә кадәрге әдәбиятның нинди традицияләре дәвам иттерелә?

Г. Камал һәм Г. Тукай сатирик әсәрләренең уртак көлү, фаш итү объектларын билгеләгез?

«Безнең шәһәрнең серләре» комедиясендә конфликт үзенчәлеге, төп һәм ярдәмче каршылыкларны билгеләгез?

Г. Камал комедияләрендә актив файдаланылган көлке тудыру алымнарын аерып чыгарыгыз.

Драматург иҗатындагы кайсы каһарманнарның прототиплары билгелез?

Әдип мирасында милли чынбарлыкны яңартуның нинди юллары тәкъдим ителә?

Г. Камалның әсәрләре нинди әдәби юнәлеш кысаларында иҗат ителә?

«Өч бәдбәхет» һәм «Уйнаш» драмаларының сюжет вакыйгаларын билгеләгез, идея-эстетик катламнарында төп аерымлыкларны табыгыз, аларны күрсәтүче таблица төзегез.

**Гамәли биремнәр**

Г. Камал – драматург һәм хикәяче

Г. Камалны күренекле драматург итеп формалаштырган әдәби-мәдәни җирлек, тарихи вакыйгалар. Аның журналистлык эшчәнлеге. Әдипнең милли драматургияне һәм милли профессиональ театрны үстерүгә керткән өлеше.

Әдипнең башлангыч чор иҗаты, беренче драма әсәрләрендә («Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет», «Кызганыч бала») Урта гасыр татар һәм төрек әдәбиятларының йогынтысы. Драмаларда күтәрелгән мәсьәләләр, аларның сәнгатьчә хәл ителеше.

«Бәхетсез егет» (2 нче вариант), «Уйнаш» пьесаларында драматик шәхесләр. Икенче вариант әсәрләрендә сюжет һәм характерлар бирелешендәге аермалыклар. Сюжет нигезендә яткан конфликт үзенчәлеге.

Г. Камал – хикәяче. «Сабир хәзрәт, яки Гыйбрәт», «Күгәргән алтыннар» хикәяләренең әдәби-эстетик тамырлары. Милли чынбарлыкта кеше характерындагы кимчелекләрне кире кагу максатыннан кулланылган алымнар һәм чаралар.

Г. Камал – комедия остасы

Г. Камал иҗатында сатираның үсеше, аның социаль җирлеге. «Беренче театр» комедиясе. Пьесада төп һәм ярдәмче каршылыклар, автор тудырган образлар, автор тарафыннан расланган дөреслек, үткәрелгән фикерләр.

Әдипнең «Банкрот» һәм «Бүләк өчен» комедияләре. Әсәрләрнең язылу тарихы. Пьесаларда комедиографның чагылдыру өлкәсе; ачы көлү һәм фаш итү объектлары; көлке тудыру алымнары һәм чаралары.

«Безнеӊ шәһәрнеӊ серләре» комедиясе, сюжет һәм композиция үзенчәлеге. Әсәрдә Г.Камал тәнкыйтьләгән татар тормышындагы төп кимчелекләр, җитешсезлекләр.

## Галиәсгар Камал иҗаты буенча тест

1. Г.Камалныӊ туган елы.

а) 1859

б) 1878

в) 1880

г) 1879

2. Г.Камал белем алмаган мәдрәсә.

а) Күл буе мәдрәсәсе

б) «Мөхәммәдия»

в) «Халидия»

г) «Госмания»

3. Г.Камалныӊ иҗади һәм шәхси якын дусты.

а) Ш.Мөхәммәдъяров

б) Ш.Бабич

в) М.Гафури

г) Г.Тукай

4. Г.Камал мөхәррирлек иткән газета.

а) «Йолдыз»

б) «Азат халык»

в) «Вакыт»

г) «Таӊ йолдызы»

5. Г.Камалныӊ тәнкыйди язмаларына киӊ урын биргән матбугат органы.

а) «Казан мөхбире»

б) «Таӊ йолдызы»

в) «Йолдыз»

г) «Кояш»

6. Г.Камал эшләгән сатирик журнал.

а) «Карчыга»

б) «Ялт-Йолт»

в) «Туп»

г) «Әлгасрелҗәдит»

7. Г.Камалның Казанда беренче тапкыр рәсми төстә уйналган пьесасы.

а) «Бәхетсез егет»

б) «Беренче театр»

в) «Банкрот»

г) «Уйнаш»

8. Г.Камалның вакыйга һәм урын берлеге сакланган әсәре.

а) «Бәхетсез егет»

б) «Безнең шәһәрнең серләре»

в) «Беренче театр»

9. «Бәхетсез егет» драмасында күтәрелгән мәсьәлә

а) хатын-кыз азатлыгы

б) милләт язмышы

в) тәрбия, әхлак

г) сыйнфый көрәш

10. «Бүләк өчен» комедиясенең каһарманы.

а) Гафифә

б) Гарифә

в) Хәмидә

г) Җәмилә

д) Сәрбиҗамал

**Әдәбият**

Гыйззәт Б.Н. Галиәсгар Камал/ Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. Т. 3. / XX йөз башы – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – ББ. 383-401.

Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – ББ. 57-82.

Гыйләҗев Т. Галиәскар Камалның башлангыч чор драматургиясе: традицияләр һәм багланышлар (Әдипнең тууына 125 ел тулу уңае белән))/ Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар кит.нәшр., 2005. – ББ. 154-161

Закирҗанов Ә. Драматурглар иҗатын монографик өйрәнү (Г.Камал иҗаты мисалында) /Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәлаләре. – Казан: Мастер–Лайн, 1997. – ББ.31-53.

Закирҗанов Ә. Хәзерге татар драматургиясендә Г.Камал традицияләре// Заман белән бергә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – ББ. 81-90.

## Мирхәйдәр Фәйзи
## (1891-1928)

Мирхәйдәр Фәйзи татар әдәбияты тарихында драматург буларак урын ала, шулай ук шигырь һәм хикәя жанрларында да уңышлы эшли. Аның тормыш сукмаклары Оренбург губернасы Орск өязе Күкшел авылыннан башлана. Мирхәйдәрнең яшүсмер еллары Оренбург, Урал, Башкортстан якларындагы матур табигать кочагында үтә, булачак әдипкә аның йогынтысы – сихри матурлык, гүзәллек, моң һ.б. күренешләр тәэсир итә. Орскта, Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәләрендә укый, шәкертлек елларында К.Насыйри әсәрләре, гарәп, фарсы телендәге китаплар белән таныша. Г.Тукай, М. Гафури поэзияләре йогынтысында кулына каләм ала. Татар драматургиясе өлкәсендә беренче тәҗрибәләре: «Татар туе» (1905), «Ике Хәсән» (1909) пьесалары тора. Унынчы елларда матбугат битләрендә шигырьләр бастыра, аларны «Минем шигырьләрем» (1912), «Яшь күңел» (1913) исемнәре астында туплап, китап итеп бастырып чыгара. Шагыйрь поэзиясендә сәнгатьчә фикерләүнең романтик төре өстенлек итә. Аның шигъриятендә сөю-сөелү хисләрен олылаган, зурлаган, табигать күренешләренең, пейзаж матурлыгын, сихри гүзәллеген күреп сокланган, аның белән хозурланган лирик геройның хис-кичерешләрен тасвирлауга зур урын бирә. Әдип шигъриятендә замандашларыннан аермалы буларак, рухи мирасында калку

гәүдәләнгән авыл, дуслык мотивлары зур урын ала. Авыл табигатенә, кешеләрнең физик ныклыгына, рухи сафлыгына, табигыйлегенә, хезмәт романтикасына дан җырлаган («Хәйран булам», 1912; «Чәчәк җыры», 1912; «Табигать манзарасы», 1912; «Җәйге төн», 1915; «Гыйшык», 1912; «Егетләр», 1912; «Чын дуст», 1912; «Дустым өчен (Фәләк)», 1912; «Печән чапканда», 1915 һ.б). «Габдулла әфәнде Тукаев намына» әсәрендә шигъри остазы Тукайның романтик образы иҗат итеlә, ул халыкка, милләткә хезмәт итүнең идеалы буларак гәүдәләнә. М.Фәйзи шигърияте унынчы елларда идея-эстетик яктан катлаулана, психологик анализ тирәнәя. Аурупа-рус әдәбиятларында формалашкан модернистик агымнардан экзистенциализм, экспрессионизм билгеләре, аларга хас сурәтләү чаралары ярдәмендә лирик геройның каршылыклы, газаплы кичерешләре тасвирлана. «Үз иркемә куй» (1912), «Соңгы теләк» (1912), «Рәхәт кайда?» (1912), «Бәхет» (1912), «Зарлану» (1913) шигырьләрендә экзистенция баскычындагы геройның кичерешләре сурәтләнә. Әлеге үзенчәлекләр бу еллар матур әдәбиятында күзәтелгән эзләнүләр, тәҗрибәләр белән бәйле була. Лирик геройның туган ягын, илен яратуы үз халкы белән горурлануы, милли хисләр белән үрелеп китә («Илем», 1915). М.Фәйзи иҗаты сандугач, былбыл, таң, гөл, төн, йолдыз, алтын тәхет, нур, бәйрәм, диңгез, давыл, җил, яшен кебек традицион-символик образлар белән баетыла. Аның шигъриятендә Г.Тукай, Ш.Бабич, Дәрдемәнд, С.Рәмиев иҗатлары белән уртак мотивлар, Көнбатыш Аурупа, рус романтизмы традицияләре гәүдәләнә. Фольклорчы М.Фәйзинең халык җырларын туплап, тематик яктан төркемләп, «Халык җырлары» (1915) исемендә бастырып чыгара. Аларны теоретик яктан өйрәнүгә омтыла: җырларның жанрлар системасы, тематикасы, башкарылу формасы, шигырь юлларының эчке мәгънәсен бәйли һ.б.

М.Фәйзи драматургия өлкәсендә уңышлы эшли, бу төрдә үзенчәлекле пьесалар иҗат итеп, үз сукмагын булдыра. Кадимчелеккә, искелеккә, бозыклыкка, искергән гореф-гадәтләрне фаш

итүгә юнәлдерелгән «Яшьләр алдатмыйлар» (1911, басыла: 1919) водевиле дөнья күрә. Анда мәзәк ситуация сурәтләнә, әсәр конфликты «аталар» һәм «балалар» каршылыгына корыла. Яшьләрнең тапкырлыгы, зирәк акылы хуплана. Ике арада барлыкка килгән каршылыкта, Гали хәзрәт, Сәлимәләрнең җиңелеп, Мәгърүфә, Шакир өстенлек ала, каһарманнарның яңа характер сыйфатлары ачылып китә. Комедия талантлы каләм белән языла, авторның характерлар тудырудагы осталыгы, герой мөнәсәбәтләренең тормышчанлыгы, композицион бөтенлек күзәтелә.

Фаҗигале мәхәббәт тарихын сурәтләгән «Кызганыч» (1913, басыла: 1914) сентиментал драмасын әдип 1913 елда яза һәм 1914 елда нәшриятта бастырып чыгара. Әсәр сюжеты нигезендә «аталар» һәм «балалар» каршылыгы, милли хисләр белән байлыкка омтылу ята. Ул бурыч һәм хис, акыл һәм йөрәк омтылышларының каршылыгы кебек ярдәмче конфликтлар белән тирәнәйтелә. Шәхес иреге, кешенең бәхеткә, мәхәббәткә хокукы мәсьәләләренең «аталар» һәм «балалар» тартышы, милләткә, халыкка хезмәт итү проблемалары белән үрелеп китә. Бу яктан Гәүһәр белән Заһидны берләштергән, ата белән улны каршы куйган сыйфатлар барлыкка килә. Сөләйман акыл белән яшәү, өйләнү фәлсәфәсен, акылны хискә каршы куя. Әсәрнең сәнгатьчә эшләнешендә үзәктә илаһи мәхәббәт культы куела. Геройларның хис-тойгылары, кичерешләре, күңел дөньясы калкуландырыла. Пейзаж, табигать күренешләре, музыка, мәхәббәт символы – сандугач сайраулары фонында сөю, гыйшык хисләре гәүдәләнә. Әдип сентиментал әдәбиятка хас алымнарга мөрәҗәгать итә: ачы күз яшьләре, аһ-зарлары, кайгылы, хәсрәтле күңел кичерешләре, хат һ.б. Гәүһәр, Сөләйманнарның күңел-хис кешеләре тасвирлана, гомумән, хис культына урын бирелә. Пьеса романтизм һәм сентиментализм синтезы рәвешендә иҗат ителә.

М.Фәйзи иҗатына француз әдәбиятының көчле йогынтысында булган төрек әдәбияты уңай тәэсир ясый. Аурупа әдәбиятларында сурәтләнеп килегән хәл-әхвәлне драматург татар җирлегенә күчерә.

Язуның илаһи мәхәббәткә бәйле романтик геройларның күңел дөньясындагы рухи кичерешләрен сызлану фәлсәфәсе яссылыгында тасвирлаган тагын бер әсәре – «Тәкъдирнең шаяруы» (1913) пьесасы. Әсәрнең жанр сыйфатлары, сюжеты, конфликт үзенчәлегендә яшьли кияүгә чыгып та, олы мәхәббәтен саклап кала алган изге күңелле, саф йөрәкле, тугрылыклы, фидакарь Мөршидә образы тора. Ире Гыйсмәт бәхете хакына үз мәхәббәтен генә түгел, тормышын да корбан итәргә әзер була. Алдагы гомер юлында мәхәббәтен очраткан Гыйсмәтнең рухи газаплары, кичерешләренең тирәнлеге ассызыклана.

«Кызганыч» драмасында күтәрелгән акыл белән ярату-сөю фәлсәфәсенең бу әсәрдә дә үзенчәлекле үстерелеш һәм аңа авторның мөнәсәбәте үз урын таба. Тәкъдир, язмыш аларны зур сынау алдында калдыра. Кызгану хисе мәхәббәт хисен вакытлыча җиңә. Чарасызлык, тормыш гаделсезлеге, кара язмыш кочагына ыргытылган Гыйсмәт яну-көю, авыру ала, ә Гөлшат чахоткага сабыша. Пьеса финалында фаҗигалелек куертыла: гомеренең соңгы минутларын кичергән Гөлшаттан хат алган Гыйсмәт үлә, Мөршидә һушын югалтып, иренең үле гәүдәсенә егыла. Автор мәхәббәт фаҗигасен иске тормыш тәртипләре белән бәйләргә омтыла. Мелодраманы драматургның үз әсәре «Кызганыч» һәм К.Тинчуринның «Соңгы сәлам» пьесасы белән бәйләп карарга була.

М.Фәйзинең «Авыл бәйрәме» (1915) пьесасында, авыл тормышы күренешләре җанландырыла. Әсәр жанр ягыннан музыкаль комедиягә якын тора. Пьеса конфликты ярсу, шашкын, бунтарь йөрәкле яшьләр белән аталар арасындагы каршылыкка корылган, аны автор яңа тормыш белән иске тормыш тартышы рәвешендә бирергә омтыла. Анда реалистик элементларга да урын бирелә. Яшь күңелле, шаян, яңалыкка омтылган Әхмәдулла образы үз хатыны Шәфкыйга каршы куелып сурәтләнә. Заманның алдынгы яшьләре буларак калада укыган Йосыф, шәһәр егете Заһид тәкъдим ителә. Тапкыр, җор телле, шаян Шәйхинең җанлы образы тудырыла. Иске тормыш сагында

торучы «аталар», тискәре көчләрнең эш-гамәлләре, яшьләрнең аларга каршы протесты әсәрдә абстракт рәвештә күрсәтелә.

Драмада яшьлеккә, саф күңеллелеккә, рухи азатлыкка, яңа тормышка, тапкырлыкка дан җырлана. Пьесаның сәнгатьчә эшләнеше: уен-көлке, мәзәкләр, такмаклар, халык җырлары, биюләр, гади халык тормышыннан алынган этнографик детальләр, гореф-гадәтләр, йолалар белән баетыла. Сюжет җепләре таркаулана.

М.Фәйзинең ХХ йөз башы драматургиясенең даны һәм таҗы булган «Галиябану» музыкаль драмасы 1916 елда дөнья күрә. Пьесаның жанр үзенчәлеге, сюжет һәм композициясе бөтен, камил. Драманың образлар системасы: кеше образлары (төп, ярдәмче, эпизодик, җыелма, аталучы), ясалма образлар (хат, җыр, шәл һ.б.). Әсәр конфликты олы мәхәббәт хисләре белән чынбарлык, иҗтимагый гаделсезлек каршылыгына корылган. Пьесада гади авыл яшьләренең күңел матурлыгына, рухи ныклыгына, саф керсез хисләренә дан җырлана. Исмәгыйльдәге мин-минлек, тәкәбберлек, дуамаллык, үзен-үзе ярату, миһербансызлыкның социаль хәл белән мотивлаштырыла. Чишелештә Исмәгыйль һәм Хәлилнең яңа сыйфатлары ачылып китә. Дөреслекнең, байлыкка омтылышның ачысы Бәдри, Галимәдә гәүдәләнә. Мәхәббәт хисенең илаһилыгы, зурлыгы раслана. Пьесада реалистик һәм романтик алымнарның синтезы күзәтелә. Акча, байлык тирәсендә барган күренешләрдә реализмның өстенлеге ачыклана. Мәхәббәт темасын тасвирлаган картиналарда романтик алымнар, чаралар чагылышы, халык авыз иҗатыннан, мәхәббәт дастаннарыннан килә торган традицион романтик шартлылык, капма-каршы җырлашу, фаҗигале финал, геройларның тышкы матурлыгын, холык сыйфатларын арттырып сурәтләнә; әсәр тукымасына уңышлы кертеп җибәрелгән халык җырлары, гореф-гадәтләр, этнографик детальләр һ.б.

**Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр**

М.Фәйзи поэзиясендәге төп мотивларны барлагыз?

М.Фәйзи шигъриятендә лирик геройның сызлану сәбәпләрен ачыклагыз.

«Кызганыч» мелодрамасында кемнәр кызганыч?

«Галиябану» пьесасының татар әдәбиятына алып килгән яңалыгы нәрсә белән аңлатыла?

М.Фәйзи һәм К.Тинчурин драматургиясендәге уртак сыйфатларны билгеләгез.

«Мәхәббәт, вөждан һәм намус» дигән темага реферат языгыз.

Хәлил һәм Исмәгыйль образларына чагыштырма характеристика төзегез.

Нинди тышкы сәбәпләр Галиябануның күңелендә тирән драматик кичерешләр барлыкка китерә?

М. Фәйзи шигъриятендә авыл культы.

Шагыйрь әсәрләрендә физик хезмәт романтикасы.

Әдип лирикасында яшьләр темасы.

Шагыйрь иҗатында Тукай темасы («Габдулла әфәнде Тукаев намына»).

М. Фәйзи һәм Тукай.

М. Фәйзи шигъриятеңдә экзистенциаль мотивлар.

Шагыйрь иҗатында мәхәббәт мотивы.

М. Фәйзи – фольклорчы.

Шагыйрь әсәрләрендә музыка мотивы.

Әдип драматургиясендә жанр төрлелеге.

«Яшьләр алдатмыйлар» комедиясендә күтәрелгән мәсьәләләр һәм үткәрелгән фикерләр.

«Кызганыч» мелодрамасында төп һәм ярдәмче конфликтлар, күтәрелгән проблемалар.

М. Фәйзи ижатында татар-төрек әдәби багланышлары.

«Галиябану» музыкаль драмасында конфликт үзенчәлеге.

«Тәкъдирнең шаяруы» пьесасында драматик шәхесләр – Мөршидә, Гыйсмәт, Гөлшат; төп һәм ярдәмче конфликтлар, сюжет сызыгы элементлары.

**Гамәли биремнәр**

Мирхәйдәр Фәйзи – шагыйрь

Әдипнең кыска, әмма бай гомер юлы. М.Фәйзи әдәби мирасында жанр төрлелеге: шигырь, поэма, хикәя, драма, көндәлек-хатирә һ.б. Аның халык җырларын барлау һәм туплауга керткән өлеше.

М.Фәйзи – романтик шагыйрь, аның поэзиясендә романтик эстетика атрибутларының чагылышы; нечкә күңелле, моңлы, матурлыкка гашыйк лирик герой. Иҗатында мотивлар төрлелеге («Хәйран булам», «Табигать манзарасы», «Гыйшык», «Егетләр», «Печән чапканда» һ.б.).

Шагыйрь рухи мирасында Тукай темасы («Габдулла әфәнде Тукаев намына») һәм экзистенциаль мотивлар («Соңгы теләк», «Рәхәт кайда?», «Бәхет», «Зарлану» һ. б.). Лирик геройның кайгыру, сызлану сәбәпләре. Әдип әсәрләрендә шартлы-романтик.бизәкләр, замандашлары белән уртак сыйфатлар.

**Мирхәйдәр Фәйзи – драматург**

М. Фәйзи – милли драматургиядә үз сукмагын булдырган, классик әсәрләр авторы буларак билгеле. «Яшьләр алдатмыйлар» водевилендә ата белән бала каршылыгының сәбәбе күрсәтелә. Комедиядә автор тарафыннан хакыйкать раслана.

«Кызганыч» сентименталь драмасының сюжет сызыгы, образлар системасы: Заһид, Гәүһәр, Сөләйман һ. б. Геройларны хәрәкәткә китергән төп конфликт, каһарманнарның эчке каршылыгына корылган ярдәмче каршылыклардан тора. Әсәр хис, күңел культы, романтик сурәтлелекнең сентиментализм билгеләре белән баетыла.

«Тәкъдирнең шаяруы» пьесасы традицион мәхәббәт өчпочмагы мотивына корылган. Аның конфликт үзенчәлеге булып – чарасызлык баскычындагы романтик каһарманнарның сызлану, өзгәләнү сәбәпләре, фаҗигалелек тора.

Драматургның «Галиябану» музыкаль драмасында жанр үзенчәлеге һәм иҗат ысулы мәсьәләсенең куелышы. Пьесада төп һәм

ярдәмче конфликтлар. Әсәр каһарманнарының каршылыкларда ачылган характер сыйфатлары. Автор тарафыннан якланган кыйммәтләр. «Галиябану» драмасының сәнгати яктан камиллеге, бөтенлеге. Характерлар тудыруда драматург осталыгы, ул мөрәҗәгать иткән алымнар. Әсәр тукымасындагы халык җырлары, этнографик детальләрнең роле. М.Фәйзи иҗатына замандашларының, төрек әдәбиятының йогынтысы.

**Әдәбият**

Нуруллин И.З. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – ББ. 261-282.

Ханзафаров Н. Мирхәйдәр Фәйзи // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. – Т.3. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – ББ. 412-435.

Закирҗанов Ә. «Кызганыч»та нәрсә кызганыч?» (М.Фәйзи иҗатына күзәтү) // Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре. – Казан: Мастер-Лайн, 1997. – ББ. 69-77.

**XX йөз башы татар әдәбиятыннан йомгаклау тесты**

1. XX йөз башы татар әдәбиятының хронологик чикләре.

а) 1901-1917

б) 1905-1918

в)1895-1917

г1908-1917

2. XX йөз башында нәшер ителгән иң озын гомерле газета.

а) «Фикер»

б) «Вакыт»

в) «Йолдыз»

г) «Тормыш»

3. Тәнкыйди реализм агымының билгесе.

а) кеше яшәешен тасвирлауның рухи принцибы

б) типик характерлар типик хәлгә куелу

**в**) кешене яшәеш алдында кечкенә һәм көчсез итеп сурәтләү

г) геройның бер сыйфатын гипербола дәрәҗәсенә җиткереп зурайтып сурәтләү

4. Аталар һәм балалар тартышы сурәтләнмәгән әсәр.

а) «Алдым-бирдем»

б) «Тигезсезләр»

в) «Яшьләр»

г) «Ике фикер»

5. Халыкчылык идеясе гәүдәләнмәгән әсәр.

а) «Мөгаллим»

б) «Мөгаллимә»

в) «Алдым-бирдем»

г) «Теләнче кыз»

6. Г.Тукай иҗатына хас сыйфат түгел.

а) миллилек

б) халыкчанлык

в) халыкчылык

г) гыйсъянчылык

7. Реалистик поэзия вәкиле.

а) Ш.Бабич

б) С.Рәмиев

в) М.Гафури

г) С.Сүнчәләй

8. Төркиядә белем алган әдип.

а) М.Фәйзи

б) Г.Ибраһимов

в) Дәрдемәнд

г) С.Сүнчәләй

9. Ш.Камал иҗатында очрамый.

а) повесть

б) хикәя

в) фельетон

г) новелла

д) комедия

е) фаҗига

10. Тукай шигъри мәктәбе вәкиле түгел.

а) С.Сүнчәләй

б) З.Бурнашева

в) Дәрдемәнд

г) Ш.Бабич

11. Милләткә хезмәт итү хакына үз мәхәббәтеннән баш тарткан герой.

а) Зөләйха «Яшь гомер»

б) Рокыя «Тигезсезләр»

в) Галия «Алдым-бирдем»

г) Шакирә «Тартышу»

д) Фатыйма «Мөгаллимә»

12. Иҗатында татар зыялы яшьләр тормышы калку сурәтләнгән әдип.

а) Г.Ибраһимов

б) С.Рәмиев

в) Ф.Әмирхан

г) К.Тинчурин

13. К.Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» драмасының төп темасы.

а) табигать матурлыгы

б) мәхәббәт тарихы

в) татар зыялы яшьләренең рухи-фикри эзләнүләре

г) сыйнфый көрәш вакыйгалары

14. Сугыш темасын калку итеп гәүдәләндергән әдип.

а) С.Сүнчәләй

б) Ш.Бабич

в) М.Гафури

г) Н.Думави

15. Традицион шигырь калыбын җимерүче шагыйрь.

а) Г.Тукай

б) С.Рәмиев

в) Ш.Бабич

г) Н.Думави

## «XX гасыр башы татар әдәбияты» курсы буенча укылырга тиешле әдәби әсәрләр исемлеге

**1.Тукай Г. Әсәрләр. Биш томда.** Т.1.Шигырьләр. Поэмалар.(1901-1908). – 1985.

Т.II. Шигырьләр. Поэмалар.( 1909–1913). –1985.

1905ел: «Гөлүмең бакчасында...» (Гыйлемнең бакчасында...»). Мужик йокысы. Хөррият хакында. Иттифакъ хакында. Дустларга бер сүз.

1906 ел: Пушкинә. Сорыкортларга. Государственная думага. Милләтә. Көз. Пыяла баш. Сөеклемнең кабер ташында. Үз-үземә.

1907 ел: Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр Шагыйрьгә. Китмибез. Алтынга каршы. «Дөньяда торыйммы?» – дип киңәшләшкән дустыма. Пар ат. Туган җиремә. Бер татар шагыйренең сүзләре. Шүрәле.

1908 ел: Шагыйрь. Ысулы кадимче. Өмид. Мулланың зары. Мәхәббәт. Милләтчеләр. Булмаса. Күңелсез минутта. Бәйрәм бүген. Таз. Су анасы. Печән базары,яхуд Яңа Кисекбаш.

1909 ел: Пәйгамбәр. Ишан. Муллалар. Эштән чыгарылган татар кызына. Туган авыл, Милли моңнар. Туган тел. Ана догасы. Таян аллага. Кәҗә белән сарык хикәясе.

1910 ел: Җәйге таң хатирәсе. Өмидсезлек. Яшьләр. Өзелгән өмид. Актык тамчы яшь.

1911 ел: Сайфия. Көзге җилләр.

1912 ел: Хөрмәтле Хөсәен ядкяре. Татар яшьләре. Дошманнар. Казан вә Кабан арты. Ваксынмыйм. Казан мулласы һәм булачак депутат .Аң. Авылда авырып яту.

1913 ел: Шиһаб хәзрәт. Хәстә хәле. Даһигә. Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмидләре. Кыйтга ( «Көчләремне мин...»). Мөхәрриргә.

**2. Г.Исхакый (1878-1954)**

Проза әсәрләре: Кәләпүшче кыз. Бай угълы. Ике йөз елдан соң инкыйраз. Зиндан. Теләнче кызы. Тормышмы бу? Сөннәтче бабай. Мулла бабай. Остазбикә. Кәҗүл читек. Ул әле өйләнмәгән иде.

Сәхнә әсәрләре: Өч хатын берлә тормыш. Алдым-бирдем. Мөгаллим. Җәмгыять. Зөләйха. Мөгаллимә. Җан Баевич.

**3. Г.Ибраһимов (1887-1938)**

Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы. Яшьләр тормышыннан бер ләүхә. Татар хатыны ниләр күрми? Яз башы. Диңгездә. Сөю-сәгадәт. Карак мулла. Уты сүнгән җәһәннәм. ЯШЬ йөрәкләр. Карт ялчы. Көтүчеләр. Табигать балалары. Габдрахман Салихов.

«Татар шагыйрьләре»(1913) мәкаләсе.

**4. Ф.Әмирхан (1886-1926)**

Гарәфә кич төшемдә. Бәйрәмнәр. Авырулар галәмендә. Фәтхулла хәзрәт. Татар кызы. Хәзрәт үгетләргә килде. Сәмигулла абзый. Картайдым. Хәят. Кадерле минутлар. Яшьләр. Тигезсезләр. Габделбасыйр гыйшкы.

**5.Ш. Камал (1884-1942)**.

Сулган гөл. Уяну. Буранда. Сукбай. Бәхет эзләгәндә. Козгыннар оясында. Авыл мөгаллиме. Шәкерт. Сәмруг кош. Курай тавышы. Депутат. Жимерелгән звонок. Көзге яңгыр астында. Акчарлаклар. Хаҗи әфәнде өйләнә.

**6.Г.Камал (1879-1933)**

Бәхетсез егет (I вариант, 1898). Өч бәдбәхет. Кызганыч бала. Уйнаш. Бәхетсез егет (II вариант, 1907). Беренче театр. Бүләк өчен. Банкрот. Безнең шәһәрнең серләре. Өйләнәм... ник өйләндем...

**7. М.Фәйзи (1891-1928) лирикасы**.

Яшьләр алдатмыйлар. Кызганыч. Тәкъдирнең шаяруы. Авыл бәйрәме. Галиябану.

**8.С.Рәмиев (1880-1926).**

Лирикасы**.** Яшә, Зөбәйдә, яшим мин! Низамлы мәдрәсә.

**9. Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) (1859-1921).** Лирикасы. (Каләмгә хитаб). Яз чәчәге. Үткән көннәр. Без. Куанды ил. Кораб. Җәй үтте. Видагъ. Туган-үскән җир. Гөрләгән сулар. Тел – илнең колагы. Татар углы – татармын. Яз. һ.б.

**10. Шаехзадә Бабич (1895-1919)**

Лирикасы. Утрау. Ике аккош. Кандала. Газазил.

**11. М.Гафури (1880-1934)**.

М.Гафури шигырьләре. Яшь гомерем. Себер тимер юлы. Шатлык шигыре. Хөррият дәверендә. 1906 нчы елның 1907 нче елга васыяте. 1907 нче елның җавабы. Базарга чыктым. Халык теләге. Үзем һәм халкым. Кыямәт. Фитрәт заманы. Юктырсың ла, Алла? (Зарыйлык). Күңелсез бер көндә. Кем ул? Хөррият иртәсе. Кызыл байрак. Фәкыйрьлек белән үткән тереклек. Ярлылар, яки өйдәш хатын. Солдат хатыны Хәмидә» хикәяләре.

## Рефератлар, курс эшләре өчен темалар

1. Ш.Камал иҗатында кеше күңелен, рухи халәтен сурәтләү үзенчәлекләре.
2. Г.Исхакый иҗатында геройларның күңел дөньясын сурәтләү үзенчәлекләре.
3. Ф.Әмирхан һәм Г.Исхакый иҗатында фантастик сурәтләү алымнары.
4. Г.Тукайның шигъри тәҗрибәләре.
5. Г.Тукай иҗатында дини, дини-мифологик сюжетлар һәм сурәтләр.
6. Г.Тукай поэзиясенең халык авыз иҗаты белән бәйләнеше. Шагыйрь иҗатында әкияти темалар.
7. С.Рәмиев шигъриятендә символик сурәтләр.
8. Г.Тукай иҗатында сатирик сурәтләү алымнары.
9. Г.Ибраһимов иҗатында романтизм.
10. З.Бурнашева поэзиясе.
11. Г.Исхакыйның идея-эстетик карашлары.
12. XX гасыр башы татар әдәбиятында модернистик тенденцияләр.
13. Ф.Әмирхан иҗатында милли зыялылар типлары.

14. XX гасыр башы татар шигъриятендә образлы фикерләү үзенчәлекләре.

15. Г.Тукайның әдәби пародияләре.

16. Г.Тукай һәм Г.Исхакый иҗатында сатирик типлар.

17. Г.Исхакый прозасында этнографик сурәтләүләр, тасвирлаулар.

18. Г.Исхакый иҗатында мәхәббәт, никах, гаилә мәсьәләләренең сәнгатьчә яктыртылышы.

19. Ф.Әмирхан иҗатында мәхәббәт темасының сәнгатьчә бирелеше.

20. Г.Тукай иҗатында мәхәббәт темасы.

21. Г.Тукай һәм Г.Исхакый иҗатларында милләт язмышы проблемасының сәнгатьчә гәүдәләнеше.

22. Г.Исхакыйның кечкенә күләмле әсәрләрендә «кечкенә кеше» темасының бирелеше. «Кечкенә кеше» не сурәтләү алымнары.

23. Г.Тукай һәм С.Рәмиев иҗатларында шагыйрь образы һәм шагыйрьлек темасының гәүдәләнеш үзенчәлеге.

## Имтихан өчен сораулар

1. XX гасыр башында әдәби хәрәкәт һәм аның төп этаплары.

2. XX йөз башы татар әдәбиятының татар әдәбият фәнендә өйрәнелү дәрәҗәсе.

3. XX гасыр башы татар әдәбиятында метод һәм жанр үсеше.

4. XX гасыр башы татар поэзиясе үсешендә төп этаплар.

5. XX йөз башы татар поэзиясендә лирик герой (Г.Тукай, С.Рәмиев, Дәрдемәнд поэзиясе мисалында).

6. XX гасыр башы татар прозасы үсешендә төп этаплар һәм аларга кыскача характеристика.

7. XX гасыр башы татар драматургиясе тарихын чорларга бүлү мәсьәләсе. Төп этаплар һәм аларга кыскача характеристика.

8. Г.Тукайның идея-эстетик эволюциясендә төп этаплар һәм аларга характеристика.

9. Г.Тукай сатирасының иҗтимагый-сәяси эчтәлеге, көлү объектлары, шагыйрь кулланган алымнар.

10. С.Рәмиевнең әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге. Поэзиясенең төп үзенчәлекләре.

11. Дәрдемәнднең тормыш юлы һәм иҗаты. Дәрдемәнд поэзиясенең төп үзенчәлекләре.

12. Н.Думави поэзиясендә лирик герой.

13. Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте. Әсәрнең жанры, сюжет-композициясе, проблематикасы, стиль үзенчәлеге.

14.Г.Исхакыйның «Теләнче кызы» романында Сәгадәт язмышының сәнгатьчә яктыртылышы.

15. Г.Исхакыйның «Остазбикә» повестенда Сәгыйдәнең сурәтләәнү үзенчәлекләре. Вахид образының әсәрдә тоткан урыны.

16. Г.Исхакыйның «Мөгаллимә» драмасы. Анда хатын-кыз азатлыгы темасының яңача гәүдәләнеше. Пьесаның сюжеты, конфликт үзенчәлеге.

17. Г.Исхакыйның «Зөләйха» таргедиясе. Әсәрнең жанр һәм конфликт үзенчәлеге, анда күтәрелгән проблемалар. Зөләйха образы, аның характер сыйфатлары.

18. Ш.Камалның «Акчарлаклар» повестена идея-эстетик анализ.

19. Ш.Камалның прозасында стиль күренешләре (бер-ике хикәясе һәм «Акчарлаклар» повесте буенча).

20. Ш.Камал прозасында пейзаж поэтикасы.

21. Ш.Камал иҗатында юмор һәм сатира үрнәләре. Алардагы сатирик образлар, язучы куланган әдәби алымнар.

22. Г.Камалның «Бүләк өчен» комедиясе. Пьесада күтәрелгән мәсьәләләр. Хәмидә образының бирелеше.

23. Г.Камалның «Банкрот» комедиясендә сатирик образлар. Әсәрдә фаш итү һәм көлү объектлары.

24. Г.Камалның «Беренче театр» комедиясендә сатирик образлар.

25.Г.Ибраһимов иҗатында табигать сурәтләре («Табигать балалары», «Яшь йөрәкләр» һ.б. әсәрләре буенча).

26.Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романының идея-эстетик үзенчәлекләре.

27. Г.Ибраһимов. Тормыш һәм иҗат эшчәнлегенең төп этаплары, аларга кыскача характеристика.

28. Г.Ибраһимов иҗатында романтизм. Романтик әсәрләрендә шәхес һәм җәмгыять проблемасының бирелеше.

29. Ф.Әмирхан әсәрләрендә хатын-кыз идеалы.

30. «Хәят» һәм «Тигезсезләр» һ.б. әсәрләрендә Ф.Әмирхнның эстетик идеалының чагылышы.

31. Ф.Әмирханның «Тигезсезләр» драмасында җәмгыять һәм кеше язмышы проблемасының сәнгатьчә яктыртылышы.

32. Ф.Әмирхан иҗатында сатирик типлар.

33. Г.Коләхмәтовның әдәби мирасы. Пьесаларының татар драматургиясенә тематик һәм образлар яңалыгы алып килүе.

34. М.Гафуриның идея-эстетик эволюциясендә төп этаплар һәм аларга кыскача характеристика.

35. «Галиябану» драмасында М.Фәйзинең әхлакый идеалы.

36. М.Фәйзинең «Кызганыч» драмасы. Пьесаның сюжеты. Сюжет нигезенә салынган конфликт. Образлар бирелеше. Әсәрдә күтәрелгән проблемалар.

37.Ш.Бабичның тормыш юлы һәм иҗаты. Поэзиясенең төп үзенчәлекләре.

38. XX гасыр башы әдәбиятында сатира үрнәкләре (Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Г.Камал, Г.Исхакый әсәрләре мисалында).

## ФАЙДАЛАНУ ӨЧЕН ӘДӘБИЯТ

Төп әдәбият


1. Абдуллин Я. Җәдитчелек хәрәкәте һәм Ф.Кәрими // Татарстан.– 1996. – № 6 . – Б. 29-36.

2. Абдуллин Я. Милләт язмышы: уйланулар. – Казан; "Фән", 1999. – 317 б.

3. Абдуллин Я. Татарская просветительская мысль (социальная природа и основные проблемы). – Казань: Таткнигоиздат., 1976. – 318 с.

4. Алмаз Җ. XIX йөз шагыйрәсе Газизә Сәмитова: Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар.кит.нәшр.,1965. – Б. 6-22.

5. Әгъләмов М. Акмулла арбасы / Иман тәрәз шакый: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар, кит. нәщр., 1996. – Б.190-201

6. Әдәби мирас (өченче китап) –Казан: Татар.кит.нәшр., 1996. – 200 б.

7. Әйди Т. Муса Акъегет Төркиядә / / Казан утлары. – 1996. – №4. – Б. 169-172.

8. Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 384 б.

9. Әхмәтҗанов М. Фатих Кәрими мирасына яңа сәхифәләр //Казан утлары. – 1999. – № 6. – Б.177-182.

10. Әхмәтов Р. Давыллы чор җырчысы. (Ш.Мөхәммәдевнең 120 еллыгына карата) / Казан утлары. – 1985. – № 7. – Б.181.

11. Баһаутдинов Ф.К. Тинчуриннның соңгы көннәре// Казан утлары, 1990. – № 2. – Б. 24

12. Бәшир Ф. Сөйлә, каләм! Әдәби уйланулар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.

13. Валидов Дж. Очерк истории образованности татар. – Казань: Иман, 1998. – 159 с. (XIX йөздә иҗтимагый фикер үсеше, җәдитчелек хәрәкәте һәм Г. Курсави, К. Насыйри, И. Гаспралы, Акмулла, Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими, З.Һади һ.б. турында).

14. Выдающейся просветитель – демократ Каюм Насыйри //Сб. ст. – Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова, 1976. – 215 с.

15. Гайнетдин М. Гали Чокрый / / Иман нуры. –1998. – № 3. – Б. 25-26.

16. Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. – Казан: Татар, кит.нәшр., 2004. – 319 б.

17. Гайнетдинов М. Мәгърифәтче әдип / / Мирас. – 1995. № 8. – Б. 65-76 (Ф.Кәрими турында)

18. Гайнетдинов М. Бишенче ел әдибе / / Казан утлары. – 1983. –№ 11 - Б. 166-169. (З.Һади турында).

19. Гайнетдинов М. Мәдәниятебезнең бер терәге // Шәһри Казан. – 1999.–19 гыйнварь (Р.Фәхреддин).

20. Гайнуллин М. Татар хатын–кыз язучылары / / Казан утлары. – 1983. – № 8. – Б. 167-171.

21. Гайнуллин М. Татар хатын–кыз язучылары / / Казан утлары. – 1983. – № 8. – Б. 167-171.

22. Ганиева Р. Каюм бабабыз // Мәгариф. –1996. – №11.– Б.7-18.

23. Гомәров И.Г. Гали Чокрый һәм аның "Мәдхе Казан" әсәре //Мирас. – 1999. – № 10.– Б. 17-25.

24. Гыймадиева Л. Гаспралының күпкырлы эшчәнлегенә бер караш / / Фән һәм тел. – 2000. – №1. – Б. 23-24.

25. Закиржанов Ә. Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.– Б. 113-139 (Г.Сәмитова, Ш.Мәрҗани турында).

26. Кәримуллин Ә., Гайнетдинов М. Мәкәрҗә бәете //Татар теле һәм әдәбияты. Бишенче китап. – Казан: Г.Ибраһимов ис. ТӘТИ, 1976. – ББ. 221-230.

27. Ласкова Р. Мөдәррис Әгъләмовның шигъри дөньясы. – Казан: 2010. – Б. 165.

28. Магдеев М. "Стамбульские письма” Ф. Карими // Социальные корни таланта. – Изд-во Казанского универ-та, 1990. – С. 35-38.

29. Миңнегулов Х. Милли каһарманыбыз / / Ватаным Татарстан. 1999. – 20 январь (Р.Фәхреддин).

30. Миңнегулов Х. "Бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт" // Мәгариф.– 1996.–№3.– Б.17-19 (Ш.Мәрҗани).

31. Миңнегулов Х. "Милләт өчен зарлы" Акмулла / / Мәгариф.– 1998. – №10. – Б. 28-34.

32. Мусин Ф. Чор белән аваздаш. Әдәбият фәне һәм мәкаләләре: – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 240 б.

33. Ризаэтдин Фәхретдин. Фәнни-биографик җыентык. – Казан: Рухият, 1999. – 224 б.

34. Садретдинов Ш. Мәгърифәтчелек дәвере әдәбиятын өйрәнү юлында // Казан утлары. – 1977. – № 10. – Б. 172-176.

35. Салихов Р. Герой и эпоха (концепция героя в татарском литературоведении). – Казань: Изд–во "Мастер Лайн", 1999. – 352с.

36. Солтанбәков Б. Риза Фәхретдинов гаиләсе / / Казан утлары. – 1993. – № 5. – Б. 161-165.

37. Файзуллин Р. Гыйбрәтләр алырлык үткән юл: фәнни–публицистик язма. – Казан: "Идел-Пресс" нәшрияты, 2004.– 152б.

38. Хатипов Ф Мөлкәтебезне барлаганда: Иҗат портретлары, тәнкыйди–теоретик мәкаләләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988.– 272 б.

39. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары љчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б.199-225.

40. Хисмәтуллин Х. Фатих Кәрими / / Казан утлары. – 1970. – № 3. – Б, 180-181.

41. Шаһиәхмәтова Г. Язучы һәм аның әдәби мирасы / / Мәгариф. –1995.– № 11. – Б. 17-20 (З.Бигиев).

42. Юзеев А. Татарская философская мысль конца XVIII–XIX веков. Книга вторая. – Казань: Иман, 1998. – 123 с.

**Вакытлы матбугат**

*Казан утлары*

*Мирас*

*Сөембикә*

*Салават күпере*

*Ялкын*

*Фән һәм тел*

*Фән һәм мәктәп*

*Татарстан*

*Мәгариф*

**Интернет ресурсы**

http://www.kyrgyz.ru/?page=115

http://kitaphane.ru/ciki/partner.html

http://beznen–yul.narod.ru/terky–yaz/boryngy.htm

http://akmulla.ru/

http://tukai.ru/

http://gabdullatukay.ru/

http://kitap.net.ru/hisamov.php

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш ………………………………………………………………… 3
XX йөз башы татар әдәбиятының үсеш баскычлары. Проза.
XX гасыр башы татар әдәбиятының үзенчәлекле яклары.......... 5
Гаяз Исхакый иҗаты (1878-1954)............................................ 10
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр.................. 13
Гамәли биремнәр……………………………………………….. 14
Гаяз Исхакый иҗаты буенча тест ………………..................... 14
Әдәбият………………………………………………………… 17
Галимҗан Ибраһимов (1887-1938). Тормыш һәм иҗат
юлы…………………………………………………………….. 18
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр.................. 25
Гамәли биремнәр……………………………........................... 25
Әдәбият ……………………………………………………….. 27
Фатих Әмирхан (1886-1926)……………………………………… 28
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр.................. 32
Контроль эш темалары ………………………………………… 33
Гамәли биремнәр ............................................................... 34
Әдәбият ……………………………………………………….. 36
Шәриф Камал (1884-1942) …………………………………… 37
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр................. 42
Гамәли биремнәр ……………………………………………... 44
Әдәбият ……………………………………………………….. 44
XX йөз башында поэзия……………………………………….. 45
Г. Тукай. Тормыш юлы һәм иҗаты (1886-1913) ….................. 53
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр.................... 59
Гамәли биремнәр ……………………………………………… 59
Әдәбият ………………………………………………………… 60
Сәгыйть Рәмиев – таң вакыты җырчысы (1880-1926)................ 60
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр... 67
Гамәли биремнәр ............................................................... 68
Әдәбият ................................................................................. 68
Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) (1859-1921) ..................................... 68
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр.................... 71
Гамәли биремнәр.................................................................... 72
Әдәбият.................................................................................... 73
Шаехзада Бабич (1895-1919)…………………………………….. 75
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр.................... 78
Гамәли биремнәр ...................................................... 79

Әдәбият .................................................................................... 79
Сәгыйть Сүнчәләй 1889-1937) ………………………….. 79
Әдәбият..................................................................................... 82
Мәҗит Гафури. Тормыш һәм иҗат юлы (1880-1934)................ 82
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр .................. 87
Гамәли биремнәр ........................................................................ 87
Әдәбият .................................................................................... 87
XX йөз башында драматургия ………………………………… 88
Галиәсгар Камал (1879-1933) ………………………………….. 92
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр .................. 98
Гамәли биремнәр......................................................................... 99
Галиәсгар Камал иҗаты буенча тест……………………………. 100
Әдәбият..................................................................................... 101
Мирхәйдәр Фәйзи (1891-1928) ………………………………… 102
Белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм биремнәр.................... 108
Гамәли биремнәр ........................................................................ 108
Әдәбият...................................................................................... 109
XX йөз башы татар әдәбиятыннан йомгаклау тесты.................. 110
«XX гасыр башы татар әдәбияты» курсы буенча укылырга
тиешле әдәби әсәрләр исемлеге ................................................. 112
Реферат темалары. ...................................................................... 115
Имтихан сораулары. ................................................................... 116
Файдалану өчен әдәбият исемлеге............................................... 119

Учебное издание
**Даутов** Гумар Фильгизович
**Хайруллин**а Альфира Салихзяновна

“**История родной литературы (начало XX века)** ”

**Учебное пособие**
Редактор
***А.С.Хайруллина***

Компьютерная верстка

Дизаин обложка

Подписано в печать 26.02.2020
Бумага офсетная: Печать цифровая
Формат 60х84 1/16 Гарнитура «Times New Roman»
Усл. п.л. 7,25
Тираж 100 экз. Заказ № _____
Отпечатано в типографии
Издательства Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37